PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2020 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

әти кеше
КИҢӘШЛӘРЕ
хаталанудан
курыкма

АРТУР
ИСЛАМОВ
хатыныма
гашыйкмын

мин сине сагынып
ЯШӘДЕМ
бер ярату
тарихы

Алсу
СӘФӘРОВА:
«Барысы да беренче
адымнардан башлана».

75 ЖИҢҮ! 1945–2020

Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Бабакаем Исхаков Мәсгут Нурмөхәммәт улы 1918 елда Башкортстанның Иске Шах авылында туа. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, колхозда бухгалтер булып эшли. 1938 елда армиягә алына. 1941 елны хезмәт иткән җиреннән аны Ленинградка укырга җибәрәләр. Сугыш башлануы турындагы хәбәр поездда барганда килеп ирешә.

Сугышның беренче айларында бабам Көнбатыш хәрби округның генерал Павлов җитәкләгән 10 нчы армиясендә, пулеметчылар взводы сержанты буларак хезмәт итә. Фашистлар чолганышында калып, урманда партизан отрядына юлыга, Белоруссиянең Пинск партизаннар берләшмәсенә кушыла. Әлеге отряд дошманнарга каршы аяусыз көрәш алып бара.

1943 елда бабамны бүлек командиры итеп билгелиләр. Шушы вазыйфасында ул «Рельс сугышы» һәм аның дәвамы булган «Концерт», «Багратион» операцияләренә керә. 1944 елда взвод командиры итеп билгеләнә.

Белоруссия азат ителгәч, Мәсгут бабам Минск шәһәрендә узган партизаннар парадында катнаша. Командование приказы буенча, сугыш ахырына кадәр биредәге хуҗалыкларны аякка бастыру өчен калдырыла.

Бабакаем – Кызыл Йолдыз ордены, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, II дәрәҗә «Ватан сугышы партизанына» һәм «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медале, юбилей медальләре иясе.

Сугыштан соң Әлмәт шәһәренең бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы булып эшли. Озак еллар партизан отряды командиры белән хатлар язышып тора. 1996 елның ноябрендә вафат була.

Бабакаемның сугыш фотолары, медальләре, отряд командиры язган характеристикасы гаиләбездә кадерләп саклана. Еллар узган саен, аның үткән юлын күбрәк өйрәнәсе килә, яңа мәгълүматларны гел эзләп торабыз. Архивта табылган Бүләкләү бите Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан гаиләбезгә зур бүләк булды.

Мәликә МОТЫЙГУЛЛИНА.
Казан шәһәре.

107

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Исхаков Масгут Нур-Мухамедович
2. Звание сержант 3. Должность, часть боец п/отряда им. Баранникова
Представляется к Правительств. награде мед. «Парт. Отечеств. войны» 2 степени
4. Год рождения 1918 5. Национальность татарин 6. Партийность
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) В отечеств. войне с 22/VI с 130 КОП
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне ранен
9. С какого времени в Красной Армии 1938 г.
10. С какого времени в партизанском отряде 10/IX-42
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Значок отличник РККА
12. Адрес места рождения представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Командир п/отряда им. Баранникова

Комиссар отр.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Алсу Сәфәрова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр:
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 29.09.2020 ел.
Басмадан чыкты: 6.10.2020 ел.
Заказ А-2537
Тираж 7197

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA





Фото: Анна Арахамия

Факил ӘМӘК

Кайчан гына

Пәрәвезләр очкан сары көзнең
Толымына җаным урала.
Кайчан гына шундый рәхәт иде, –
Һәр уләндә чыклы җәй яна.

Бернәрсәгә исебез китми иде,
Сабый идек җәйләр йөзендә.
Кыр казлары күктә тирбәлешә,
Көз ишеген шакыйм үзем дә...

Ничек ташлап китим җәйләремне! –
Җаным җәйдән, ахры, яралган.
Сукмакларда пәрәвезләр очкан
Көзгә керсәм, анда калалмам...

Сары көзнең сары толымнары,
Алтын яфрак – җирнең мендәре.
Кыр казлары болытларга кунып,
Көтеп тора икән кемнәрне?..

Кайчан гына шундый рәхәт иде...
Җилләр килеп көзгә тезләнде.
Сары көзнең алтын балкышында
Таный алмыйм җәйнең эзләрен...

Кыр казлары очып китеп бара,
Язмыш чакыруын ишетеп.
Их, каласы җәйле көннәремдә!..
Каерып ача көзләр ишеген...

Безнең тышлыкта

«Һәр бала үз фикерен әйтергә лаеклы. Ул – шәхес. Ул – кабатланмас. Укытучы аңа ярдәм итүче, мәгълүмат кырында – маяк.»



6 Киләчәк кешесе мәктәбе
Чулпан Галиәхмәтова

Заман һәм без



12 Роза йолдызлыгы
Эльмира Закирова



16 «Миндә ике кеше яши...»
Чулпан Галиәхмәтова

18 Бәхетсезләр утравы
Чулпан Галиәхмәтова



22 Үзебезнең Тоскана!
Раилә Хәялиева



26 Санаусыз чакрымнар
Гөлнур Сафиуллина

Яшәеш



46 Мәхәббәттә ялгызлар
Гөлнур Сафиуллина

50 Вәгъдә йөзеге
Фәгыйлә Шакирова

Татар дөньясы



30 «Иртәдән кичкә кадәр чигә алам»
Зилә Нигъмәтуллина



52 Алман иле яки җавапсыз сораулар
Айгөл Әхмәтгалиева

Мәдәни тормыш



36 Тукталыш
Нәҗибә Сафина

Хуҗабикә



60 Чәшкедәге «торт»



КИЛӘЧӘК КЕШЕСЕ МӘКТӘБЕ

Фото: Анна Арахамия



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Шәймиев мәктәбе!» Казанда быелгы уку елында ачылган күп телле белем бирү мәктәпләр челтәренең беренчесе халык телендә әнә шулай йөри. Юкка гына түгел, бу белем йортларының моделе Татарстанның беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев күңелендә туган иң элек. 2017 елда тел белән бәйле низаглар чыгып, мәктәпләрдә татар теле сәгатьләре кыскартылып беткәч, алдан күрә белүче тәҗрибәле сәясәтче, милләт өчен җан атучы зирәк җитәкче, республикабыз аксакалы бу вазгыятьтән чыгу юлын табу өчен, Татарстанда күп телле белем бирү мәктәпләре булдыру идеясе белән яна башлый. Республика «Яңарыш» фонды яңа проектка старт бирә. Аны 165 нче мәктәп базасында гамәлләштерергә карар кылына. Ел ярым эчендә башкаланың Бондаренко урамында өр-яңа белем йорты калкып чыга, 165 нче мәктәп бинасы төзекләндерелә, аңа яңа янкорма төзелә. Шундый ук мәгариф комплексы Алабугада ачылды. 2022 елга алар санын алтыга җиткерүне планлаштыралар. Күп телле белем бирү комплексына балалар бакчалары да керә, ел әйләнәсендә эшли торган өстәмә белем бирү үзәге ачу да ниятләнә. Мәктәптә рус, татар, инглиз телләрен тигез дәрәҗәдә өйрәтәләр, фәннәр дә төрле телләрдә укытыла. Тел өйрәтүдән тыш, балалар милләтара татулык рухында тәрбияләнә. Шуңа да әлеге комплексларның барысын да, Минтимер Шәймиев тәкъдиме буенча, «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» дигән исемнәр берләштерә. Программасы гына түгел, бизәлеше дә башка мәктәпләргә охшамаган. Кәрәз рәвешендәге парталар, дивар урынына тәрәзә булган сыйныф бүлмәләре, коридорда – утыргычлар, тәрәз төпләрендә – мендәрчекләр... Ә икенче каттан беренче катка махсус торба аша гына шуып төшәргә мөмкин. Белем алу өчен барлык шартлар да тудырылган: фәнни лабораторияләр, остаханәләр, ике бассейн, хәтта үзләренең тавыш яздыру студияләре дә бар. Бу мәктәптә укыган балаларның фикерләү рәвеше дә башка булыр кебек: колачлырак, ирекләрәк, иҗадирак, кыюрак, мөстәкыйльрәк, яңарак... Шуны да әйтергә кирәк, мондый комплекс Россиядә бердәнбер һәм ул – Татарстанда!

«Кызым, укытучының авызына гына карап тор!» Мәймүнә әбисенең укытучыны Алла урынына күреп әйткән сүзләрен беренче сыйныфка барган Алсу туры мәгънәсендә кабул итә. Каршында басып торган апаның авызыннан күзен алмый һәр сүзен йотып бара. Җитмәсә, әнисенә ялынып-елап татар гимназиясенә укырга килде бит, сынатырга ярамый. Югыйсә Түбән Кама районындагы Кама Аланы эшчеләр бистәсендә татарлык күзгә бик ташланмый да: бар җирдә русча сөйләшәләр. Әнисе дә: «Үзем юньләп русча белмәдем, сез яхшылап өйрәнегез», – дип, кызларын рус балалар бакчасына йөртә. Балаларым дип яшәгән ана алар белемле, акыллы булып үссен өчен җаны-тәне белән тырыша. Бакчада узган татар милли бәйрәмнәре кечкенә кыз күңелендә туган телгә мәхәббәт оеткысы сала. Беренче сыйныфка барырга җыенган Алсуның фикере катгый була: мин татарча укыйм!.. Ул бистәдәге татар гимназиясенә укырга керә.

Бүген инде үзе балалар алдында дәрес биргән «Адымнар» күп телле белем бирү мәгариф комплексының татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алсу Сәфәрова әбисенең сүзләрен гомере буе исеннән чыгармый – остазларының «авызына гына карап тора». Беренче укытучысы Венера Иршатовна кебек балаларга карата олы йөрәкле булырга, укучыларында иң элек туган телләренә мәхәббәт уятырга тырыша. Укытучысының сөйләгән сүзләре әле һаман да исендә аның. Телне өйрәтеп кенә калмыйлар, татар булулары белән горурлану хисләре дә тәрбиялиләр. Ярыша-ярыша татар тарихын, тел үзенчәлекләрен өйрәнәләр мәктәптә. Милли бәйрәмнәр үткәрәләр. Кама Аланындагы бердәнбер татар утравы булган гимназиягә, кызганыч, оптимальләштерү җилләре тия – ябыла. Хәзер ул рәхмәтле укучыларының хәтерендә генә саклана.

Укытучысы Кәүсәрия Фәтхиевна ярдәме белән татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда республика дәрәҗәсендә беренче урыннар яулаган Алсу һич икеләнми Казан дәүләт университетының легендар татфагына укырга керә. Танылган тел галимнәрендә укыйсы килә аның. Әле дә хәтерли: профессор Флера Сафиуллинаның беренче лекциясенә кергәч, горурлыгыннан күзләреннән яшьләр чыга. Күпме китапларын укыган галимәнең лекция-





Раилә ХӨСНЕТДИНОВА, милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары

Элек татар әдәбиятын өйрәнгән татар балалары да, рус балалары да күп кенә шагыйрь язучыларның исемнәрен белә иде. Быел мәктәпкә укучыларны җыйганда шуңа игътибар иттем: татар төркемендә укыган укучылар да бөек шагыйрьләребезнең исемнәрен бик авырлык белән әйтә. Бу мине тетрәндерде. Моның сәбәбе бер генә: соңгы ике елда татар теленең дәрәҗәсе сизелерлек кимеде. Безнең мәктәпкә татар телен сагынып килгән балалар бик күп булды. Ә аларның әти-әниләре ничек сөенгәнен күрсәгез иде сез! Ике елга сузылган югалтуны табу бит бу! Әйе, матур мәктәп дип, тышына кызыгып кына килүчеләр дә булды. Утырып сөйләшеп аңлаштык: без монда балаларны татар теленә өйрәтәбез, милләтебез белән горурлану хисләре тәрбиялибез. Киләчәктә үз халкына хезмәт итәрдәй егет-кызлар булсын дип хыяллана-быз. Бу бит атнасына биш тапкыр татар теле дәресләре генә керә дигән сүз түгел. Мәктәп күләмендәге барлык чаралар, класстан тыш эшләр туган телебездә үтә. Түгәрәкләр алып бару өчен читтән килүчеләр дә эшләрен татарча алып бара. Мәсәлән, бездә микроклонлаштыру түгәрәге бар. Яшь буын өчен бик кызык тема бит инде ул. Җитәкчесе татар телендә алып бара аны. Шулай ук конферансье, театр түгәрәкләре эшли. Алар да телне камилләштерергә ярдәм итәчәк. Тарих, җәмгыять белеме фәннәре дә татар телендә укытыла. Ә татар теле һәм әдәбияты җиденче сыйныфка кадәр атнасына биш сәгать укытыла. Безнең өчен Казан федераль университеты «Адымнар» дәреслеген бастыра.

Тәрбия чаралары да туган телдә уздырыла. Ә ул татарча матур итеп исәнләшүдән башлана. Беренче көннәрдә мәктәпкә килеп кергән балалар исәнләшә белми иде. Хәзер матур итеп ана телендә сәлам бирәләр, чөнки телне өйрәнүгә кызыксыну зур. Ана телендә авырлык белән сөйләшкән ата-аналар өчен дә махсус түгәрәкләр оештырып җибәрергә уйлыйбыз. Хәтта баланы көтеп торган арада татар телен өйрәнергә була бездә. Холлда эленгән телевизорлардан видеодәресләр күрсәтелә. Моның өчен бары теләк кенә кирәк. Ә безнең мәктәпнең ишекләрен ачып кергәннәрдә ул бик зур булырга тиеш. Башкача була да алмый!

сендә утыра бит ул! Мәймүнә әбисе һәрвакыт укытучы бул дисә дә (Ул укытучыга булган хөрмәт хисен оныгында да тәрбияләгән. Алсу өчен укытучылар – иң хөрмәтле шәхесләр.), кызның татар теленә башкачарак хезмәт итәсе килә. Ул махсус әдәби редакторлык курсларына йөри. Диплом алгач, интернет газетага килә. Ярты ел эшләгәч аңлый: юк, текст тикшереп утырасы килми икән аның, балалар янында буласы, аудитория тотасы, аңлатасы, телгә булган мәхәббәтен яшь буын белән бүлешәсе килә икән Алсуның. Шулай итеп, ул башкаланың 165 нче мәктәбендә укыта башлый. Ә монда үзе бер дәүләт! Тел белән дә санлашалар, укытучыларның да милли үзаңын үстерү өстендә эшлиләр. Мәктәпкә килүенең икенче көнендә үк аны укытучылар өчен оештырылган «Яшел яр» театр түгәрәгенә чакыралар. «Дәфтәр тикшерәсе, программа төзисе, гаиләдә бар бит әле безнең», – дип әйтмиләр мөгаллимнәр, дәресләрдән соң репетицияләр ясап, укучылары, ата-аналары каршында спектакль куялар. «Укытучылар көче белән оештырылган чаралар коллективны тагын да дуслаштыра, үзеңә дә ачылырга ярдәм итә, ә иң мөһиме: укучыларыбызга үрнәк күрсәтәбез, – ди укытучы. – Аннан соң безгә психолог та, җырчы да, артист та булырга туры килә. Киң мәгълүмат кырында үскән баланың игътибарын үз фәнеңә җәлеп итәр өчен нинди генә алымнар кулланмыйсың. Тема белән бәйле кызыклы вакыйгалар да сөйлим, җырлап та җибәрәм. Башта укучылар бик сәерсенеп карый иде. Ничек инде укытучы җырлый?! Хәзер үзләре дә кушылырга гына тора. Әнә шулай калыплардан чыгарга да өйрәтәм. Укытучы такта, дәреслек, сыйныф бүлмәсе белән генә бәйләнеп каралырга тиеш түгел, бигрәк тә хәзерге заманда».

Яшь укытучының укыту методларын күреп, Алсуга узган ел «Ел укытучысы» бәйгесендә катнашырга тәкъдим итәләр. Икеләнеп тормый, әзерләнергә керешә, республика турына уза. «Күпме тәҗрибә тупладым, хөрмәтле укытучылар белән аралашырга туры килде», – ди Алсу бәйге



Минтимер ШӘЙМИЕВ: «Тел – ананың баласына иң кадерле бүләге».

Күп телле белем бирү комплексларының төп максаты – балаларыбызны дөнья күләмендә көндәшлеккә сәләтле итеп әзерләү. Бу – иң мөһиме. Кимендә өч тел – рус, татар һәм инглиз телләрен өйрәнү, шушы телләрдә белем алу баланың офыкларын киңәйтә, тормышта үз урынын табар өчен мөмкинлекләрне арттыра. Ул балалар үзебездә калырлар микән дип борчылу да аңлашыла. Әмма бүген дөнья ачык, бездән чит илләргә барып укыйлар, чит илләрдән безгә киләләр. Күп телдә белем бирү мәктәпләренә ихтыяҗ һәм аларның барлыкка килүе – шуның нәтиҗәсе. Мәгърифәтле булу – ул билгеле бер кысаларга гына кереп утыру дигән сүз түгел, киресенчә, заман белән бергә атлау дигәнне аңлата. Бу – табигый хәл дияр идем, шулай булырга тиеш тә, заманасы шундый. Хәзер беркемне дә чикләп булмый, күп телләр белгән сәләтле балаларны бигрәк тә. Безнең балалар кайда гына яшәсәләр дә, Татарстандамы, Россиянең башка төбәкләрендәме яки чит илләрдәме – алар көндәшлеккә сәләтле икән, димәк, кирәкле белгечләр сыйфатында, яхшы урыннарда эшләрләр дип ышанабыз. Башка илләр тәҗрибәсен карасак, шуны күрәбез: чит илләрдә укып-эшләп, лаеклы урынын тапкан балалар шул илләр белән үз илләре арасында икътисадый элемтәләр коруда бик яхшы арадашчылар була ала.

Балаларда патриотлык хисе тәрбияләү, һичшиксез, мөһим. Шунысы бар: ватанпәрвәр булу – ул, бердән, туган җиреңдә калып яшәү-эшләү булса, икенчедән, башка төбәкләрдә, чит илләрдә дә үз илеңне, үз республикаңны, милләтеңне лаеклы күрсәтү. Татар халкын бөтен дөньяга таныткан күренекле шәхесләр бик күп, без алар белән горурланабыз.

Тагын шунысы мөһим – без бу мәктәпләрдә һәр телгә тигез шартлар тудырабыз, димәк татар телен укытуга да тиешенчә игътибар бирелә, туган телебезне өйрәтүдә нәтиҗәле ысуллар кулланыла дигән сүз. Безнең мәктәпләр – телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу юнәлешендә җитди адым дип саныйм.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның киләсе елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итүе дә шушы максатка – бездә яшәүче милләтләрнең телләрен саклап калуга эшли.

Безнең халкыбызда бик тирән мәгънәле бер әйтем бар: «Тел – ананың теләге, тел – ананың баласына иң кадерле бүләге». Ана телен саклау, аны буыннан-буынга җиткерү – әниләребезне ярату-хөрмәт итү билгесе һәм аларның безгә васыяте! Бу васыятьне без сезнең белән ант итеп кабул итәргә һәм үтәргә тиешбез. Бу нисбәттән без «Сөембикә» журналын укучы сөекле хатын-кызларыбызга – аналарга зур өметләр баглыйбыз.

турында сөйләгәндә. «Адымнар» мәгариф комплексына чакыргач та, ике дә уйламый, канат куйган мәктәбеннән күчә. Монда бөтенләй башка мохит! Үзе укыган гимназиясен хәтерләтә. Балаларның күзләре янып тора, өйрәнү, белергә омтылу көчле. «Күз алдыгызга китерәсезме, татар телен өйрәнәсем килә, дип, бер бала янымда елап утырды. 3 яшькә кадәр татарча гына сөйләшкән. Аннан соң балалар бакчасы, мәктәп... Күпләр кебек «руслашкан татар»га әйләнгән. Татарча аңлый, әмма сөйләшә белми. Менә шушындый балаларны күргәч, күңел үсеп китә. Бушка эшләмәгәнеңне аңлыйсың. Һәрвакыт балаларга: «Сез бит килмешәкләр түгел, үз дәрәҗәгезне белергә кирәк. Ә моның өчен иң элек телне һәм тарихны белү сорала», – дим».

Мәктәптәге 21 бала өчен Алсу әле әни дә. Сыйныфы турында сөйләгәндә дөньясын оныта ул. Көндез алар белән аралашса, кичен мессенджер төркемендә ата-аналар белән сөйләшеп үткәрә. Баланы тәмам ачар өчен, әти-әни белән дә тыгыз элемтәдә торырга кирәк. 4 яшьлек сабыен йоклаткач, иртәгәсе көнгә программа төзергә утыра... Монысы инде укытучылар өчен – классика.

– Шулай да ник сайладым икән бу һөнәрне дигән уй килгәне бармы? – дип сорыйм. Югыйсә җавабын да беләм инде...

– Укытучы робот түгел. Ул да – кеше. Алҗыган, талчыккан чаклар да була. Әмма укучыларымның миңа төбәлгән эчкерсез күзләрен күргәч, мин өйрәткәннәрне матур итеп сөйләгәннәрен тыңлагач, бөтен ару-талулар юкка чыга. Безнең һөнәр эш кенә түгел, хобби да булырга тиеш. Хезмәтеңнән ләззәт аласың икән, димәк, син инде үз эшеңнең остасы. Укытучының күңелендә ни барын балалар бик тиз тоя. Гомумән, укучылар – безнең лакмус кәгазебез. Җаны-тәне белән эшенә бирелгән, балаларны яраткан укытучының дәресен сыйныфтагы иң шук малай да өзәргә җөрьәт итми, чөнки хөрмәт зур. Укытучы заманча – креатив булсын дияргә яраталар. Миңа калса, асылда барыбер дә балаларны ярату ята. Яратмый икән, могҗиза тумаячак...



Айдар ШӘМСЕТДИНОВ, «Адымнар» күп телле белем бирү комплексы директоры

Телләр өйрәнергә бервакытта да соң түгел. Мин – 80 нче елларда Казан мәктәбендә белем алган татар кешесе. Ул елларда ана теле җиденче дәрес булып кына керә иде. Билгеле, нигездә, русча аралашабыз. Укытучыларыбыз Наҗия Сәлаховна, Туйгөл Зиннәтовна йогынтысы зур булды безгә. Бигрәк тә рус теле укытучысыныкы. Ул гарәп теле курслары да алып бара иде. Без, үсмер малайлар, аңа тел өйрәнергә килдек. Ә ул безгә: «Балалар, сез башта туган телегезне яхшылап өйрәнегез, аннары минем дәресләргә килерсез», – диде. Бу минем өчен бик әһәмиятле сүзләр булды. Шул чордан башлап туган телемә игътибарлы булдым, ныклап өйрәндем. Аннан соң китапханәчебез Киев университетының чит телләр факультетын тәмамлаган Татьяна Александровна миндә испан теленә мәхәббәт уятты – аннан дәресләр алдым. Мәктәпне тәмамлагач, югары уку йортының чит телләр факультетына укырга кердем. Дипломым буенча гарәп һәм инглиз теле белгечемен. Хәзер дә инглиз әдәбиятыннан дәресләр алып барам. Ә менә төрек телен 36 яшемә җиткәч өйрәндем. Төркиягә ял итәргә баргач, бу ил халкының телен белмәү зур кимчелек булып тоелды. Соңгы биш елда төрек телен билгеле бер системага салып, камил дәрәҗәдә өйрәндем. Яраткан язучыларым да бар. Хәзер шәхси китапханәмдә төрек язучыларының берничә дистә китаплары тора.

Тел өйрәнүне көн саен дәвам итсәң генә аны камил итеп өйрәнергә мөмкин. Мин моны беләм инде. Күп тел белү – чикләрне җимерә, дөньяны өйрәнү, күзаллау колачы зурая. Полилингваль мәктәп ачу хыялым иде. Әле 2002 елда узган «Ел укытучысы» бәйгесендә аның концепциясен дә якладым. Моннан ундүрт ел элек, 165 нче мәктәпкә директор итеп билгеләнгәч, гап-гади микрорайон мәктәбен тирәнтен инглиз һәм татар теле өйрәнү үзәгенә әйләндерү процессын башлап җибәрдек. Һәм без үз максатыбызга ирештек. Бүген «Адымнар» ачылу – хыялым чынга ашу.

Әлбәттә, күзләрең никадәр янып торса да, бу зур эшне ялгызың гына башкарып чыга алмыйсың. Минем янәшәмдә – көчле коллективым. Кадрлар мәсьәләсе директордан тора. Шуңа да җитәкче – башкалар күңелен күрә белгән олы йөрәкле, мәрхәмәтле кеше булырга тиеш. Ә менә мотивация сүзен яратмыйм. Сез дә бит, әни кеше буларак, көн саен үзегезгә мотивация тудырып ятмыйсыз. Сезнең вөҗдан дигән сыйфатыгыз бар. Беләсез: балага яхшы тәрбия бирергә кирәк һәм моның өчен кулыгыздан килгәннең барысын да эшлисез. Без дә коллективыбызда гаилә принципларына нигезләнәбез. Һәр кеше үз бурычын белә. Мәктәпкә эшкә килгән укытучылар бездән бик сирәк китә. Коллективны булдырганда тирә-ягымда үз эшенең осталары күп иде. Аннан соң хәят юлымда очраган кеше күңелемә якын булса, аны инде җибәрмим – һәрвакыт тыгыз элемтәдә торам. Элек мәктәптә бергә укыган кешеләр хәзер минем коллегаларым. Укытучыларыбыз барысы да үзебезнең республика егет-кызлары. Алар өстәмә әзерләү курслары узды. Дәресләрне татар, рус, инглиз телендә алып барабыз. Татарстан Президенты ярдәме белән махсус безнең мәктәп өчен Россия стандартлары буенча язылган дәреслекләрне инглиз теленә тәрҗемә итә алдык.

Татарстан районнарыннан гына түгел, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә балаларын бездә укыту теләге белән, элемтәгә чыга. Интернатыбыз бар. Бүгенге көндә анда 50 бала яши. Мәскәү, Уфа, Ульяновск, Саратов өлкәләреннән балалар укый. Әлбәттә, бездә белем алган балалар татар телен белергә тиеш. Монысы – төп шартыбыз. Белем алырга мотивациясе булган, әти-әнисе безнең карашны бүлешкән һәр бала өчен ишекләребез ачык.

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ӘЛЕ КОМПЬЮТЕРЛАР ЮК ЧАКТА...



























Фото: Анна Арахамия

Резеда ШӘЙХЕТДИНОВА: «Компьютерлар нәшриятка узган гасырның 90 нчы елларында керә башлады. Безнең цехта беренче компьютер остасы Сергей Фёдорович Сержантов булды. Аңарчы да инде текстларны клавиатурага карамыйча җыя идек, шуңа да компьютерларда эшләргә өйрәнүе кыен булмады. Яңалык яратуым да ярдәм иткәндер».

Ак халатлы кызлар электрон таблолы машинага иелгән. Беренче карашка бар да җайлы – клавиатурага гына баскалап утырасың кебек. Әмма бик тә четерекле бу фотоҗыю цехындагы программистларның эше – машинкада җыелган текстларны «машина теле»нә күчереп, челтәрле тасмага әйләндерү. Бер генә төймәгә ялгыш бассаң да, әллә никадәр кешегә өстәмә эш ясыйсың.

Нәширлек эшендәге операцияләр компьютер ярдәмендә башкарылган бу заманда элегрәк эшләүчеләрнең хезмәте никадәр катлаулы булуын аңлыйсың. Макетка салу, верстка кебек үтә четерекле эшләр дә кулдан башкарыла. Фотоҗыючылар «машина теле»нә әйләндергән текст перфолентага яздырылып, рулонлы кәгазьгә чыгарыла. Корректорлар укыганнан соң, материаллар үтә күренмәле пленкага бастырыла. Монтаж цехында әзер пленкаларны монтаж өстәленә куеп, кайчы һәм скальпельләр ярдәмендә газета-журналларны макетка җыялар. Эш күп, цехлар гөрләп тора. Фотоҗыю цехында гына да егермедән артык кеше хезмәт куя. Газета-журналлар, миллионлы тираж белән басылучы китаплар, брошюралар – барысы да шушы цех аша уза. Язма герое Резеда Шәйхетдинова КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшриятының («ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең филиалы булган «Идел-Пресс» нәшрияты ул елларда шулай атала) – фотоҗыю цехы программисты. Нәшриятта эшләгән 34 елда гади сортировщик вазыйфасыннан башлап, печатька кадәр әзерлек цехының җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелә.

1989 елның май саны тышлыгын аның фотосы бизи. Бу фотодагы һәрнәрсә тарихи аның өчен. Өстендәге күлмәген дә бер төн эчендә үзе тегеп кигән әнә. «Элек барыбыз да тектек. Эштән кайтышлый кибеттән тукымасын аласың да, таңга кадәр тегү машинасы тынмый. Әнием Рәйсәнең мин тугач ук алынган «Зингер» машинасында шактый күлмәкләр тегелде, – дип искә ала ул фотога төшкән көнен. – «Азат хатын»ны кайларда гына алдырмыйлар иде. «Сине журналда чыгарганнар», – дип, СССРның төрле почмакларында яшәүче туганнарыбыз шалтыратып чыкты». Шушы фото басылганнан соң аны хәтта телевидениегә тапшыруга чакыралар.

Нәшрияттагы еллары матур хатирәләр белән саклана күңелендә. «Намуслы хезмәт, тырыш хезмәткәрләр бәяләнгән елларда эшләргә насыйп булды, – ди ул. – Үзешчән сәнгатьнең дә бик популяр чорлары иде. Качалов исемендәге рус драма театры актрисасы Элла Ригорина драма түгәрәге оештырды. Эштән соң репетицияләргә җыелабыз. Бәйрәмгә Островскийның «Женитьба Бальзаминова» спектаклен куярга әзерләндек. Үземә бирелгән купчиха роленә керү өчен, күлмәк астыннан мендәрләр бәйләргә туры килде. Мин – ябык, ә купчиха таза гәүдәле. Бүгенге «ТАТМЕДИА» бинасының 12 нче катында зур актлар залы бар иде. Яңа ел кичәләре, спектакльләр, концертлар шунда узды. Коллективыбыз да, җитәкчеләребез дә менә дигән кешеләр, үз эшләренең чын осталары иде бит. Владимир Александрович Гаврилов, Дилбәр Талиповна Хәйруллина, Ислам Галиәхмәтович Әхмәтҗанов, Фәрит Илдусович Шаһиәхмәтовларны зур хөрмәт белән искә алам. Алар бөтен җаннарын биреп, яратып эшләүчеләр иде. Тату һәм дус булдык, шуңа эшләве дә күңелле иде. Үтә җаваплы булса да, кайчак төн йокыларын качырса да, эшемне бик яраттым».

Лилия ГӘРӘЕВА

Төркиядә быел 8 Мартны «Гөлсем көне» дип игълан итәләр! Һәм барысы да Роза Туфитуллованың җиңел кулыннан башлана! Аның «Язмыш җиле» романы, үзебездә дөнья күргәнче үк, «Гөлсем» исеме белән төрек телендә нәшер ителә. Аны махсус 8 Мартка җитештерергә тырышалар. Чөнки Гөлсем – Төркия өчен үзенә бер кадер-хөрмәткә ия! XX гасыр башында Петербургның Бестужев курсларында укып йөргән зыялы татар кызы, шәфкать туташы булып, Балкан сугышында яраланган төрек сугышчыларын дәваларга китә, Төркиядә хатын-кызлар хәрәкәтен оештырып йөри. Тәрҗемәче Гүлшаһ Йылмаз култамгасы белән әсәр Әнкарада китап ярминкәсендә тәкъдим ителә. Киләчәктә хатын-кызлар бәйрәмен «Гөлсем көне» дип тә йөртәчәкләр. Ни гаҗәп, Роза апа нинди генә эшкә алынса да, ахыры әнә шулай тарихка кирәклек зур вакыйгага булып тәмамлана. Җанына тынгы бирми гел талпынып, менә-менә очып китәргә канатланган хыяллары исә бик күп аның!



РОЗА ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

(Роза Туфитуллова портретына штрихлар)



Эльмира ЗАКИРОВА

Менә хәзер уйлап утырам да... «Азат хатын» журналы аның үҗәтлеге белән исемен үзгәртә – укучыларына ул «Сөембикә» булып килә башлый. Ә милләтнең иң асыл кызларына, зур эшләрен бәяләп, көмеш «Сөембикә беләзеге» кидерү идеясе? Әлбәттә инде аныкы! Бөтен дөньяга сибелгән татар хатын-кызларын берләштерүче «Ак калфак» оешмасына да ул нигез сала. Кыз бала тәрбияләсәң, милләтне тәрбияләрсең, дип кабатлый-кабатлый, Казанда кызлар гимназиясен ачу хыялы белән янып йөреп, анысын да тормышка ашыра. «Миһербанлык белемәсе» – монысын инде халык депутаты булып, Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә балалар файдасына башкарган игелекле эш-гамәлләренең берсе дип карарга кирәктер... Россия Иҗтимагый палатасында мәдәни һәм рухи мирасны саклау комиссиясендәге

эшчәнлеген дә халкыбызга, милләткә хезмәт итүгә кайтып кала. Болары – без белгәннәр, без шаһит булганнар гына. Күрми калганнарыбыз тагын да күбрәк әле. Таныдыгызмы? Безнең Роза апа! Күренекле җәмәгать эшлеклесе, талантлы редактор, депутат, язучы һәм журналист Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллованы без үзара шулай Роза апа дип йөртәбез.

Бик күп журналистлар, газета-журнал редакторлары аның мәктәбен узды. Һәркайсының күңелендә әллә никадәр матур истәлекләр сакланадыр. Миндә дә байтак икән андый хатирәләр. Аның «Яшь ленинчы» газетасы редакторы булып эшләгән чагы, «Ялкын» журналына баш редактор итеп билгеләнгән көннәре... «Азат хатын»га баш редактор итеп озатулар... Алар күңелле эпизодлар булып искә төшә, Роза апаны яңа яклары белән ача.

Иң матур еллар

...Кызы Гөлназ тугач Роза апа декрет ялында утыра да алмады, аны обкомга чакыртып алып, үзе эшләгән газетаның баш редакторы итеп билгеләделәр. Яшь, чибәр, талантлы, әллә нинди кызыклы эшләр уйлап таба...

Әтнәгә командировкага баргач, очраклы гына Олы Мәңгәр авылындагы латыш балалары кабере турында ишетә ул. Кызыксынып, сораштыра башлый. Ә ул балалар 1941 елны сугыш башланганда Лиепаяда пионер лагеренда ял иткән булалар. Фашист самолетлары бомбага тота башлагач, аларны тиз арада Новосибирскига эвакуацияләр. 400 ләп бала, педагоглар. Ләкин поездда килгәндә үк тиф белән авырый башлыйлар, аларны Юдино станциясендә төшереп калдыралар. Аннары Олы Мәңгәргә, Балалар йортына алып китәләр. Тифтан терелгәннәре була, терелмәгәннәре... Менә ни сәбәпле ятып калган икән латыш балалары татар зиратында... Кабат Ригага кайтып киткәнче, дүрт ел буе татар авылында яши әле ул балалар. 1975 елда Роза Туфитуллова аларны эзләп Ригага килә. Олы Мәңгәр балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең берсе, танылган журналист Андрис Спрогис Роза апаны Ригада яшәүче «мәңгәрләр» белән күрештерә. Икәүләп «Олы Мәңгәр – гомер бишеге» дигән китап иҗат итәләр. Ул татарча да, латышча да басылып чыга. Ә латыш балалары инде үсеп җиткән, зур-зур урыннарда эшлиләр, гомерләренең Мәңгәр чорын елап искә төшерәләр... Берничә елдан соң, җыелып, Олы Мәңгәргә дә кайта әле алар. Ул кадерле кунакларны каршы алулар, зиратка җирләнгәннәр истәлеген пионер-комсомол өмәләрендә җыелган акчага обелиск куйдырулар, хәтер шәмнәре кабызулар... Роза апа, әлбәттә инде, шул эшләрнең башында кайный.

...«Яшь ленинчы»да нинди генә язучы-шагыйрьләр эшләми! Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Госман Садә, Нияз Акмал, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон... Сабакташы Клара Булатованың укучысы, редакциягә шагыйрь булып килеп кереп, яшьләр газетасы редакторы булып киткән Атлас Гафиятов тагын... Кыю фикерле, ошамаса турыдан ярып

Тынгысыз җаны үзенә эшләрен дә табып тора бит!

сала торган, баш бирмәс, талантлы шул егетләрне редактор Туфитуллова ничек кенә эшләтә әле! «Һәркайсының җаен табып эшен дә куша, үстерә дә белә, кирәк икән яклап та чыга үзләрен! Мишәр кызы шул!» – диләр аның турында.

Ә үзе «Яшь ленинчы» газетасында эшләгән елларын ул һәрчак сагынып, иң матур эш елларым, дип искә төшерергә ярата.

Аксөякләр нәселеннән

...«Мишәр кызы»ның дуслары күп. Университетта бер группада укыган егет-кызларны саный китсәң дә, җыенысы атаклы кешеләр икән бит. Клара Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов, Роза Мулланурова, Харрас Әюп, Ләлә Сабирова, Флүс Латыйпов, Фирая Шиһапова-Зыятдинова, Рәшит Җәгъфәров, Сәгыйть Хафизов (Лашманчы)... Зәйнуллина Роза – Аксубайның Үзи авылы кызы безнең Роза апа була инде. Акыллы, белемле, тырыш, зәвык белән киенә, җайлап сөйләшә, тәвәккәл, ярдәмчел, диләр аның турында. «Аның күлмәге дә, яулыгы да, туфлиләре дә матур. Бар киеме килешле. Ул барыбыздан да аерылып тора иде. Югыйсә авыл кызы бит инде. Каян килгән шундый зәвык, затлылык? Аристократлар нәселеннән диярсең, билләһи!.. Розага группаның бөтен егете гашыйк иде бугай. Аңа багышлап шигырьләр язалар, озатып куярга теләүчеләр дә күп. Ул итагатьле, елмаеп сөйләшер, берсенә дә каты бәрелмәс. Бизмән йолдызлыгыннан булуы үзенекен иткәндер: дипломатия саклап, дәрәҗәсен белеп, сүзләрен үлчәп, җайлап сөйләшә. Серле елмаюы белән тәмам сихерле үзе», – ди әнә адашы Роза Мулланурова.

...Аксөякләр нәселеннән дигәннән... Роза апа – укымышлы муллалар нәселе баласы. Иске Карматтә яшәгән дәү әнисенең әтисе Хәсәнша мөәзин Хәсән Туфанны укыткан, Гаяз Исхакый белән аралашкан. Дәү әнисе Фәсыйгелбәян дә, әнисе Фигаль апа да – укытучылар. Әтисе Рәхмәтулла абый кохоз рәисе булган. Икенче дәү



Сулдан-уңга: Венера Ихсанова, Роза Камалетдинова, Роза Туфитуллова, Ләбибә Ихсанова. «Сөембикә» журналы редакциясе. 1993 ел, июнь.

Күпме кеше язмышын уңайга борды ул!

әнисе Мәликә им-томга оста, бөтен авыл халкын дәвалый. Оныгы Розаның кендек әбисе дә ул.

...Студент елларында ук Клара Булатова Роза апаның сабакташы-сердәше була. Бергә Язучыларның Тукай клубына кичәләргә йөриләр, олпат язучылар белән якыннан аралашалар. Шундый кызык, күңелле чор була ул! Клара тулай торакта Роза Зәйнуллиналар бүлмәсендә бишенче кеше булып яши.

...Шагыйрь Хәсән Туфан Роза апаның якташы, кардәше дә икән әле. Ә Клара белән Туфан – икесе дә күккә ашкан хыялый җаннар. Алар шигырь телендә сөйләшәләр. Туфанның мәхәббәт лирикасындагы Тәнәкә – Клара Булатова була! Клара-Тәнәкәгә гашыйк булып, шигъри хатларын яшел кара белән язган шагыйрь – Хәсән Туфан үзе бит инде! Еллар узгач, Роза Туфитуллова шагыйрь Хәсән Туфан турында «Бәйлисе бар йөрәкне» дигән китабын яза. Китапның язмышы да кызыклы. Шулай ук зур вакыйга белән тәмамлана. Автор шактый тырышып, артыннан йөреп, дөньякүләм танылган галим – астрономия һәм космик геодезия кафедрасы мөдире, профессор Наил Сәхибуллин янына бара. Галим бу ниятне хуплап ала. Тик шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында текст инглиз телендә булып, унбер юлдан артмаска тиеш икән! Туфан тикле Туфан турында бит ул! Америкадагы Халыкара кече планеталар үзәгенә материаллар әзерләп җибәрәләр. Озак та көттерми, куанычлы хәбәр килә – дөньяның йолдызлар картасында «Хәсән Туфан» йолдызы калка!

...1986 елда Роза Туфитуллованы «Ялкын» журналына баш редактор итеп куйдылар. Без читтән сокланып йөргән Роза апа сигезенче каттан – «Яшь ленинчы»дан тугызынчы катка менеп утырды. Үзе дә тик тормый, безне дә эшләтә. Ул безне бөтенләй башка журналистикага алып кереп китте. Польшадан, Чехиядән журналистлар килә редакциягә. Мәскәүләрдән киләләр... Үзе дә командировкаларга еш йөри. Күбесенчә Мәскәүгә. Әле ВЛКСМ Үзәк Комитетына, әле Бөтенсоюз пионер оешмасы үзәк советына... Роза апа башкаладан гел яңача булып кайта. Муенына ал ефәк шарфын матурлап салган, тулышкан чия төсендәге костюмы шулкадәр килешле... Өстәлдә – Мәскәү конфетлары... Без – ул чакта әле яшь ханымнар – Роза апаның зәвыклы киемнәрен, килешле хәрәкәтләрен энә күзеннән үткәреп утырабыз. Күр, өстәлендәге кечкенә вазадагы гап-гади тукранбашлар да киеменә төстәш ләбаса. Матур! Ошый!

...Журналга кулдан язып әзерләгән язмаларыбызны машинкада җыярга тапшырганчы, иң элек үзенә укытабыз. (Кульязмаларны ничек таныгандыр!) Үтемле фикерен, киңәшен әйтергә тиешле сүзләрен сайлап, кулы белән мәрҗән йә зөбәрҗәт муенсаларына кагылып ала, уйлап кына, хәтер калдырмаслык итеп кенә төзәтмәләр кертә. Юк, башта мактый әле!

...Роза Туфитуллованы Татарстаннан ВЛКСМның XX съездына делегат итеп сайладылар. Шундый зур форумда безнең редактор катнашсын әле! Ә инде делегатлар кайтасы көнне чәчәкләр алып (никтер, сатуда канәфер чәчәкләре генә була иде ул елларда) вокзалга чаптык. Роза апаны каршыларга. Салкынча апрель иртәсе. Газетага төрелгән чәчәкләребезне кочаклап, «Татарстан» поездын көтәбез. Яныбыздан гына ашыгып Роза апаның ире Миргалим абый узып китте. Поезд күренүгә, чәчәкләрен тиз генә төргән кәгазьдән арындырды. Розалар! Аннан күреп, без дә ал канәферләребезне кулга тоттык. Роза апа, елмаеп, вагон тәрәзәсеннән безне күзәтә иде...

...Яшьләрнең һәм студентларның Мәскәүдә узган XII Бөтендөнья фестивалендә дә катнашты ул. «Без – Татарстан делегациясе Кызыл мәйданда гармуннар белән татарча җырлап йөрдек. Чит ил яшьләре дә безнең төркемгә килеп кушылды», – дип сөйләгәннәре хәтердә калган.

Кайсыгызның кулы җылы...

...Аны әле «Вожатый» журналына, әле Бөтенсоюз пионер оешмасының Үзәк Советы аппаратына эшкә чакыра башладылар. «Юк, кызлар, сезне ташлап беркая да китмим!» – дисә дә, озак та үтми үзен «Азат хатын» журналы баш редакторы итеп билгеләп тә куйдылар.



Олы Мәңгәр авылы зиратында латыш балаларына обелиск ачу. 1980 ел.



«Яшь ленинчы» редакциясендә газетаның чираттагы санын планлаштыру. 1984 ел.

Ай күрде, кояш алды апабызны. Күршегә генә кереп утырса да, безнең бер дә җибәрәсе килми. Ноябрь санын аннан башка гына әзерләдек. Ә журнал тышлыгына рәссам Зифа Мөхәммәтҗанова кыш килүен әкияти Кар кызы аша тасвирлады. Ул образ Роза Туфитуллованы күздә тотып һәм аңа охшатып сурәтләнде. Ярату да, юлына ак юллар теләү дә, бераз сагыш та сизелә иде анда.

...Көннәрдән бер көнне редакциягә Мамадыштан бер хат килеп төште. Динар исемле малайдан. «Әгәр дә берәрсе Динар «Ялкын»ны яратмый дисә, ул дөньядагы иң зур ялганчы булыр. Велосипедка дип җыйган акчама «Ялкын»га язылдым», – дип язган. Әбисе белән генә яши икән. Күрше авылга җәяү йөреп укый. Җәй буена көтү көтеп йөрүе дә юкка гына түгел – велосипед кирәк! Без Динарга сюрприз ясарга булдык. Тик менә акча каян табарга? Менә шул чакта инде халык депутаты Роза Туфитуллова, безне хуплап, велосипед өчен акчаны үзе бирде. Велосипедны машинага салып, Динар укыган мәктәпкә баруларыбыз... Баланың сөенүләре... Ул аның өчен самолет булып күренде бугай инде!..

...Күршеләргә – «Сөембикә»нең баш редакторы кабинетына йомыш белән тиз генә кереп чыгарга әллә ничә талпындым – һаман кеше Роза апада. Ерак авыллардан да киләләр хәтта. Таяныч һәм яклау эзләп, булышуын сорап, күңелләрен бушатырга теләп...

...Караңгы тиз төшә торган ноябрь көнендә шулай Актанышка бергә командировкага чыгып киттек. «Сөембикә» редакторы булып эшләгән елларында республиканың ярлыкау комиссиясе әгъзасы да иде ул. Юл буе бер хатын, аның балалары өчен борчылып барды. Гаепсезгә төрмәгә утыртканнар. Аклап, ireккә чыгару кадәресенә ирешә менә. Ә бит әле кайткач яшисе дә бар. Төрле гайбәт сүзләрдән өстен булып калырга... Өй тулы кечкенә балаларга әни җылысын кайтарырга... Эшкә урнашырга... Роза апа хакимият башлыгына керергә, аңлатырга әзерләнеп барды... Шундый кырыс сынаулар үтәргә туры килгән хатынның өенә дә кердек. «И апа, миңа Ходай булышты дип уйлаган идем. Коткаручым сез икән бит!» – дип, Роза апаны кочаклап, үксеп-үксеп елады ул...

Кайсыгызның кулы җылы? –
Бәйлисе бар йөрәкне...

Хәсән Туфанның бик тә мәгънәле шул шигыренә Роза апа бөтен игелекле, мәрхәмәтле эшләре, җылылыгы белән җавап биргәндер, мөгаен.

...Германиянең Эрфурт шәһәре урамнарында йөрибез. Кибетләргә, кечерәк бутикларга сугылабыз. «Монисы Алсуга, ә бу – Ларисага... Мәдинәгә, Филисәгә...» – дия-дия, Роза апа магнитлар, брошкалар, шәмдәлләр, төрле сувенирлар җыя. «Син дә эшендәгеләрне онытма», – ди. Карале, янәшәңдәгеләргә кечкенә генә игътибар күрсәтү турында нинди шәп дәрес!

...Гомере буе җаваплы хезмәттә булып, башкалар өчен кылган бөтен-бөтен гамәлләрен, халык, милләт язмышын, гаилә, хатын-кызлар, балалар дөньясын кайгыртып зур эшләр башкаруын, иҗатын күз алдыннан үткәрергә, тырышып карыйм да... Юк, ул колачлаган чиксезлекне әйтеп, сөйләп бетереп кенә булмый икән. Туфан Миңнуллинның Роза Туфитуллловага багышлаган «Татар кызы» язмасы, шундагы кайбер юллар искә төшә. «Инсафлы, чибәр, акыллы, пөхтә, чая, сабыр, өзелеп ярата һәм яраттыра белгән асыл зат...» «Син һәр чорда татар гаиләсендә әхлак нигезләрен саклаучы хуҗа булдың. Ирне ир итә белү серләрен Син тумыштан белә идең... » Һәм Роза апа йолдызлыгындагы бик кадерле кешеләр аның дөньясын түгәрәкләп-тулыландырып җибәрә... Ире Миргалим абый... Үзе дә абруйлы җитәкче булган, ил-көндә танылган мөхтәрәм зат. Мең мәшәкатьле тормышында да хатынын аңлап, аның гамьнәре белән яши белә ул. Уллары Айдар... Икътисад фәннәре докторы, профессор. Кызлары Гөлназ... Сәнгать белгече, Санкт-Петербургта Репин исемендәге сәнгать академиясендә чит ил студентларына инглиз телендә лекцияләр укый. Оныклар... Алар бишәү. Ә Ал таң урамындагы йортлары Роза йолдызлыгының чып-чын җәннәт почмагы кебек. Анда – кояш, чәчәкләр, роза гөлләре, анда – гамьле уйлар, илһамлы иҗат, йокысыз төннәр... Тукайлар чорын җентекләп өйрәнеп язган, милләтебезнең Гөлсем, Зәйтүнә кебек асыл кызларын яратып тасвирлаган «Язмыш җиле» романының (Ә Гөлсем Камалованы мин, никтер, язучының үзенә охшаттым!), «Гөлсем көне» кебек бәйрәмнәрнең, шагыйрь турындагы нәфис-нәзберек әсәрнең, бик күп проектларның чишмә башы да биредә. Ә алда язылаасылары инде тагын ымсындырып тора...



■ Беренче рәттә *(сулдан-уңга)*: Роза Туфитуллова, Флора Әхмәтова-Урманче, Диләрә Тумашева, Финляндия кунагы Айнур Низаметдин. Басканнар: Әлмира Әдиатуллина, Марат Әмирханов. «Сөембикә» редакциясе. 1992 ел.

«МИНДӘ ИКЕ КЕШЕ ЯШИ...»

Мәһабәт гәүдәле, баритон тавышы белән күпләрне әсир иткән, көнчыгыш ир-атларына тартым Артур Исламовны татарча рокның атасы дип әйтергә була. Ул – татар альтернатив музыкасының чишмә башында торучы, беренче рок төркемнәрдән булган «Alqanat» оештыручыларының берсе һәм солисты. Ун ел барган әлеге уңышлы проектка нокта куеп, Артур опера жанрына кереп китә. Хәзер ул Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты. Әмма рок җырчысы карьерасына нокта түгел, өтер генә куелган булган... Бер үк вакытта опера да, рок та җырлаучылар бик сирәк. Аларның берсе – татар җырчысы! Универсаль җырчы белән сөйләшәбез.



– Артур, опера сәхнәсендә иҗат итсәң дә, күңелеңнән рок җырчысы рухы чыгып бетмәгән бугай... Аларның кайсысы якынрак синә?

– Юк, чыгып бетмәде. Әле чыгасы, бирәсе энергияләр күп. Җырланмаган җырлар бар. Миндә рок җырчысы үлмәгән әле. Сыйфатлы музыка яратам. Шуңа күрә дә кайсын күбрәк үз итүемне аерып кына әйтә алмыйм. Аннан соң опера белән рокны берләштерә торган бер нәрсә бар: икесендә дә җанлы музыка. Ә җанлы музыка рухландыра: иҗат итәргә этәрә.

– Күпләр хәзер сәнгатьне шоу итеп тәкъдим итә. Синең өчен ул нәрсә?

– Шоу-бизнес юнәлеше күптән бар инде. Әмма кемнәрдер үзенең «иҗатын» акча эшләү инструменты итеп кенә күрә. Концерт программасын да теләсә нинди җырлар белән тутыра. Сәнгатькә бик җитди карыйм, минем өчен ул иң элек – иҗат. Бер көнлек җырлар гына язасым килми.

Төптән уйлап иҗат иткәннән соң гына халыкка тәкъдим итү турында уйланам. Кызганыч, җырчылар арасында икенче сортлылар күп җыелды. Алар җыр сәнгатен чүпли. Тагын да кызганычы: шулар арасында үзеңнең иҗатыңның өстенлеген расларга туры килә. Әмма яхшы җырчылар бар, һәм алар әллә кайдан ук аерылып тора.

– Бер әңгәмәңдә син яңа рок-проект башлау нияте барлыгын әйткәнсең. Бер-ике ай элек социаль челтәрләргә чыккан «Татар, алга» җыры тиз арада популярлык яулап, татар яшьләренең гимнына әйләнде дә куйды. Бу шул проектның башымы?

– Әйе! Бу дүрт ел буе әзерләнгән проект. «Alqanat» таралуга ук яңа проект булдырачагымны беләм идем. Халыкка тәкъдим итәр вакыт җитте. «Артур Исламов» проектындагы җырларга көйләрне бары тик үзем генә язам. Үземчә итеп! Күңелем кушканча! Ә менә шагыйрьләрне байтак вакыт эзләдем. Бик күп укыдым. «Безнең җыр» проектында Гөлүсә Батталны ачтым. Узган ел Рүзәл Мөхәммәтшин иҗатына юлыктым. Ул ун ел элек үк миңа шигырьләрен җибәргән булган икән инде. Булат Ибраһим белән менә «Татар, алга» җырын иҗат иттек. Ни өчен шул җыр белән башладыммы? Миндә татарлык хисе бик көчле. Татарның көчле һәм дәрт бирә торган җырлары булырга һәм ул үзенең бөек икәнлеген онытмаска тиеш. Альбом да яздырырга җыенам. Алла бирса, шушы айда концерт уздырырга исәп. Ул татарча рок-концерт булачак.

– Артур Исламов кире рокка әйләнеп кайта алайса. Ни өчен?

– Татарда мондый жанр яшәргә тиеш. Мин шулай телим. Минем шундый концерт бирәсем, шул юнәлештә эшлисем килә!

– Ә опера?

– Опера үз урынында. Анда да җырлаячакмын. Ул тавышны формада тотарга ярдәм итә. Җырчылар да бит спортчылар кебек. Тавыш белән даими шөгыльләнергә кирәк. Алайса ул бозыла. Баритон партияләре – драматик партияләр – Вердиның төп репертуарлары 30 яшьләрдән соң башкарыла. Димәк, операда минем чор башлана гына әле. Вакытны дөрес бүлә белсәң, барысына да җитешергә була. Бер ай опера белән генә шөгыльләнәсең, аннан соң бөтен дөньяңны, тавышыңны үзгәртеп, икенче төрле музыкага кереп китәсең.

– Димәк, синдә ике төрле кеше яши?

– Әйе, миндә ике кеше яши. Алар – һәрберсе аерым дөнья.

– Гадәттә, рок җырчыларны бунтарь дип атыйлар...

– Юк, мине бунтарь дип әйтеп булмый. Бунтарьлар алар сәясәткә кагыла, каршы күтәрелә. Ә мин иҗатчы. Рок – драйв. Бик тыныч кешемен. Ә рок миңа энергия бирә.

– Син хатының Эльза белән – икегез ике Галәм. Икегез дә иҗат кешесе. Опера сәнгатендә эшләү бит инде ул турлар, Европаның бер иленнән икенче иленә гастрольләр дигән сүз. Ә гаилә? Кызыгыз үсеп килә. Гаиләдә син нинди ир һәм нинди әти? Сәхнәдәге затлы Артур Исламов тормышта нинди икән?

– Мин гашыйк. Беренче чиратта, Эльзаның үзенә, аннары – тавышына, иҗатына. Мине иң сокландырган тавыш – аныкы. Ул – минем музам! Кызыбыз Иделия – минем җанатарым. Гаиләдә гап-гади ир һәм гап-гади әти мин. Тормышны матур итеп алып барырга тырышам. Бездә хатын гына өстәл җыештырырга, хатын гына өйне тәртипкә китерергә тиеш дигән кагыйдәләр юк. Гаиләдә икең бер карашта булса гына матур яшәп була.

Егерме елдан соң Артур Исламовның тормышына күз салсак... Нинди хыяллар белән янып яшисең?

Артур Муллаянович булырмын дип уйлыйм... *(Көлә.)* Чынлап әйткәндә, бу хакта уйлаганым да юк. Әле минем иҗат ялкынланып янарга гына тора. Барысы да алда!

Фото: Анна АРАХАМИЯ

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.

QR-кодны ничек кулланырга:
1. Смартфоныгызга kiozk приложениесен урнаштырыгыз.
2. QR-сканерны ачыгыз.
3. Смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.





БӘХЕТСЕЗЛӘР УТРАВЫ

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Казан базарларының берсе янында урнашкан бу вагоннар һәр төнне сукбайлар белән тула. Тормыш төбенә төшкәннәрне беркайчан да кочак җәеп каршы алмыйлар. Ә менә монда аларны ашаталар, төн кунып чыгар өчен урын бирәләр. Әлбәттә, бу – ата йорты түгел. Үзеңне табу, нормаль тормышка кайтыр өчен нишләргә кирәген аңларга булышучы вакытлыча яшәү урыны – Кеше приюты бу. Аның үз кануннары, үз көнкүреше. Монда һәркемнең үз фаҗигасе, әмма бөтенесен бер нәрсә берләштерә: аларның җаннары яралы. Бүген приютта кырыкка якын җан яши, дөресрәге, көн уздыра. Курку чагылган күзләр, төссез караш, тормыш төбендә булуы турында сөйләүче йөз чалымы, түбән иелгән баш, бөкрәйгән гәүдә...



















Беркая да китмибез!

– Синнән аракы исе килә. Ашарга бирмибез! Эчәргә акча тапкансың икән, димәк, ипигә дә табачаксың…

Сәләмә генә киенгән ир, башын иеп, борылып китеп барды. Сумкасын иңсәсенә аскан. Артык карт та түгел үзе. Фотограф Аня белән бер-беребезгә карашып куйганны күрде булса кирәк, ашарга биреп торучы аңлатырга кереште:

– Монда төп кагыйдә шул: аракы исе килергә тиеш түгел. Андыйларга ярдәм итмибез…

Өч вагонны бергә кушып ашханә ясаганнар. Анда озын өстәл куелган. Ризык өләшә торган тәрәзә янына килеп, үз өлешләренә тигәнне алалар да, өстәлгә барып утыралар һәм тиз-тиз ашый башлыйлар. Ә битараф карашлар бер ноктага төбәлгән. Бер-берсе белән сөйләшмиләр. Гомумән, монда нәрсәдер кирәксә генә авыз ачалар кебек. Ашханә янында киемнәр эленеп тора. «Кием күп, – ди биредә эшләүчеләр. – Һәрвакыт китереп торалар. Юылган гына булсын, барысын да кабул итәбез». Төн кунып чыгар өчен сигез вагон тезелеп тора. Икесендә – хатын-кызлар, калганында – ир-атлар. Йөри алмаганнар гына көндез приютта кала. Сәламәтрәкләр эшкә урнашып эшләп йөри, төн кунарга гына кайта. Вагоннарда тактадан ясалган икешәр катлы караватлар. Кечкенә өстәлләрендә – ризыклар. Һәр вагонда шулай. Күрәсең, кайчандыр үзәккә үткән ачлыкны оныта алмыйлар – һәрберсе запас белән яши. Карават асларында пакет-пакет кием. Монысы да – запас. Алда бит кыш… Хатын-кызлар вагонында бик күп йомшак уенчыклар, көзге, сирәк кенә булса да бизәнү әйберләре күренгәли… Идәннәре чип-чиста. Урын өстендә ятучылар булса да, бернинди авыр ис сизелми.

Бер як кырыйдагы вагонга йозак эленгән. Мунчалары икән. Чишенү, юыну, парлану өлешләреннән торган мунчаны буржуйка миче ягып җылыталар. Ә суны шушында яшәүчеләр иске бала коляскасында пластик шешәләргә салып ташый. Казан уртасында бу! Үзәктән су белән тәэмин итү юк монда. Бәдрәф янында юынгыч тора. Димәк, юыну мөмкинлекләре дә чамалы. Ярый әле урамда җәй, ә кышын…



«Тоткынлыктан азат ителүчеләр өчен тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» автономияле коммерциясез оешма генераль директоры, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата әгъзасы Азат ГАЙНЕТДИНОВ:

«Социаль проектны йортсызлар белән генә эшләрбез дип башлаган идек, әмма андыйлар барлык мөрәҗәгать итүчеләрнең 20 проценты гына. Калганнары – хәерчеләр...»

Безнең янга Гөлшат Татова – приютның администраторы килеп басты.

– Әйе, уңайлыклар юк. Шулай да моннан китәргә теләми алар. Әле йортсызлар өчен дәүләт социаль приютыннан, безгә җибәрегез, дип шалтыраттылар. Барысын җыйдым да әйттем. Җиңемнән тоттылар да, беркая да бармыйбыз, диләр. Бала кебек, елашалар.

Приютта яшәүчеләр өчен Гөлшат – әни. Сукбай кеше турында кайнар линиягә кемдер шалтыратуга, эзләп чыгып китә ул аларны. Тапкач, машинасына утыртып приютка алып кайта. Кайберләрен хәтта үгетләргә дә туры килә! Башта мунчага алып кереп, юындырып кеше кыяфәтенә кертәләр. Гөлшатка табыналар монда. Үзеннән күпкә өлкәннәр дә, «Гөлшат апа», дип эндәшә. Үзе дә күп авырлыклар күргән хатын өчен сукбайларга ярдәм итү тормыш мәгънәсенә әйләнгән.

Кеше приюты оештыру йортсызларны ашатудан башланган. Үзәк базар тирәсенә вагон китереп куйгач, беренче көнне дүрт кешене ашатсалар, икенче көнне 37 сукбайдан чират тезелә. Һәм аларның саны көннән-көн арта. Ашарга килүчеләрнең кайберләре яшәү урыннары юклыгын да әйтә. Тагын бер вагон алып кайталар. Анда киемнәр җыя башлыйлар… Хәзер инде монда сигез вагон һәм тәүлек дәвамында ашаталар. Торыр урыннары булмаганнар шушында яши, ә баш өстендә түбәсе булып та хәерчелектә яшәүчеләр ашарга гына йөри. «Араларында төрлесе бар, – ди Гөлшат. – Безгә КАИның элеккеге профессорлары да, 40 еллык хезмәт стажы булган укытучылар да, медицина хезмәткәрләре дә килеп җылы ризык ашап китә. Күбесенең балалары йә төрмәдә, йә наркоман. Кредит алганда кемгәдер поручитель булып, хәзер бөтен пенсияләре шул кредитны капларга киткәннәр дә бар. Дару сатып алгач һәм коммуналь хезмәт өчен түләгәч, пенсиясе ашарга җитмәгәннәр дә килә. Берсен дә кире бормыйбыз. Без булмасак, кем карар аларны?!

– Ә монда яшәүче сукбайлар?..

– Юк, алар сукбай түгел. Күбесенең документлары бар. Булмаганнарыныкын киредән ясату артыннан йөрибез. Һәрберсенең үз тарихы. Монда тормыш төбенә төшеп йөзен югалтканнар да, кеше булып калганнар да бар. Бер ел элек йөри алмаган бер әбине китереп ташладылар. Аны үземә алып кайттым. Оныклары, алдалап, йорт-җирен саткан да, әби урамда калган. Ышанасызмы, быел шуның оныгын китерделәр. Йөри алмый.

Фото: Анна Арахамия

Җылы ризык ашарга килүчеләр арасында КАИ профессорлары да, 40 еллык стажы булган укытучылар да бар.

Вагонда урын өстендә ята әнә. Аңа нибары 30 яшь.

– Приютка килүчеләр арасында кичә бай тормышта яшәп, бүген хәерчелеккә чыкканнар очрыймы?

– Бер абзый яшәде монда. Заманында көчле финансист булган. Комарлы уен башына җиткән. Чир бит инде ул. Бар булганын оттырып бетергәч, балалары аны урамга чыгарып җибәргән. Хәзер ул бер бай гаиләдә кочегар булып эшли. Тагын бер кешене алып килгәннәр иде. Аның сыра ясый торган заводы булган. Бер технологиясе дөрес эшләми башлаган да, санаулы сәгатьләр эчендә банкротлыкка чыккан. Аның сүзләре әле дә исемдә: «Кешеләрне күрми дә идем, бөтен дөньяны сатып алдым дип уйлап яшәдем...»

Мәхәббәт үләме?

Каршымда үз яшеннән күпкә олы күренгән Гена утыра. Йөзен сакал-мыек баскан. Кулында ялтыравык ташлар белән бизәлгән хатын-кызлар сәгате. Бармагында – перстень. Яшьтән үк әнисез кала ул. «Әнидән башка бала кемгә кирәк инде?» – ди. Урта һөнәри белем бирү йортын тәмамлаганнан соң, илнең төрле төбәкләрендә шабашкада эшли. Төрмәгә эләгә. Алты ел утырып чыга, Казанга кайта. Эшкә урнаша. Хезмәт хакы алган көнне зур карбыз сатып ала, трамвайга утыра. Шунда әнисе белән барган бер кечкенә кызның: «Әни, минем дә карбыз ашыйсым килә», – дигәнен ишетә. Ярты карбызын бүлеп бирер өчен Гена аларга ияреп кайта һәм шунда кала. Өч көн эчендә өйләнешеп, 30 елга якын бергә яшиләр. Әмма теге кечкенә кыз, үсеп җиткәннән соң, фатирны үзләренә калдыру нияте белән, Генаның колагына кислота сала. Хастаханәгә документлар күтәреп килгән хатынына ирнең шундый ачуы чыга ки, уйлап та тормыйча имзасын куя һәм урамда кала. «Ә бит Юля кечкенә чагында мине бик ярата иде, рәсемнәр ясарга өйрәттем», – дип, күз яшьләре белән елый ул. Приютка килгәч, Гөлшат аның хатыныннан бөтен документларын алып кайта.



■ Гөлшат Татова: «Мин көне буе алар белән. Туры юлга бастыру өчен вәгазь сөйләүче дә, әрләп алучы да, күргәннәрен тыңлап, жәлләп елап алучы да, өс-башларын караучы да... Монда су булмагач, кием-салымнарын өйгә алып кайтып – юып-үтүкләп алып киләм».

Беренче тапкыр пенсиясен Гена үзе ала.

– Монда яшәргә шартлар начар, Картлар йортына урнашырга теләмисезме? – дип сорыйм.

– Юк, бармыйм. Анда пенсиямне алачаклар. Ә приютта үземә бирәләр. Минә монда саклана, – дип йөрәк турына төртеп күрсәтә. – Тик минә хатын гына килеп пенсиямне сорап йөри. Күп таладың, җитәр, дим. Ул үзе дә хәзер минем кебек хәлдә. Бомж кебек капчыкларын асып урамда йөри. Юля без яшәгән фатирда үзенә офис ясаган. Кәрт ача... Ә мин анда шундый шәп ремонт ясаган идем. Ишекләре президент кабинетындагы кебек иде... Хатынымны күралмыйм, әмма никтер аңа тартылам... Киредән бергә яшәү турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Үзен хөрмәт иткән бер хатын да монда килми... Шуның аркасында тәмәке тарта башладым... – Сүзеннән туктап, ул миңа карап ала. – Тартырга мөмкинме?..

Үзен хөрмәт иткән хатын... Ә авыр тормыш хәлендә калсаң? Әйтик, Галяныкы кебек урамнан башка яшәр урының булмаса? Зәп-зәңгәр күзләре барысын да сөйли кебек. Кайчандыр бик нәфис булгандыр ул. Ире белән 25 ел яшәгәннәр, әмма никахларын рәсми рәвештә теркәмәгәннәр. Паспорттагы штамп кемгә кирәк дип уйлаган Галя. Ире яман шештән үлеп киткәннән соң «Мин әтинең улы!» – дип, Калининградтан бер ир кайтып төшә. Баксаң, иренең беренче гаиләсе булган... Ә хатын бу хакта бөтенләй белмәгән. Иренең улы Галяны урамга куып чыгара да фатирны сатып, кире китеп бара. Беренче өч көнне иренең каберенә башын салып төн куна Галя. Аннан – көндез эштә, төнне подъездларда үткәрә. Эштән китәргә мәҗбүр була. Көннәрдән бер көнне йокыдан уянгач, аяклары тыңламаганын аңлый. Тора алмыйча подъездда көннәр уздыра. Тизрәк үлсәм иде, дип тели. Бәхеткә, күршеләре приютның кайнар линиясенә хәбәр итә. Аның артыннан Гөлшат килә.

«Бармыйм, үз районымда үләм», – дип карыша ул. Әмма Гөлшат үгетли торгач, ризалаша. Приютка килгәч, чәчен кыркалар. Шулкадәр авыр кичерә моны Галя! Җәй буе башлыгын салмый. Берни ашамый. Алай да әкренләп яшәү теләге туа башлый. Ул аякка баскан көнне бөтен приют аның өчен куана. «Сезнең өчен тормышның фаҗигасе нәрсәдә?» – дим аңа.

– Бертуган сеңлем Наташага ышандым… Әти белән әни үлгәндә миңа – 15, сеңлемә 10 яшь иде. Безнең белән урын өстендә яткан әби яшәде. Мин эшкә кердем. Сеңлемне карар өчен алны-ялны белми эшләдем. Бар тәмле ризык, матур кием аңа иде. «Ул кечкенә, ашасын», – дидем. Үзем белән эшләгән бер егет белән таныштырып, кияүгә бирдем. Алар безнең фатирда яшәде, булачак ирем белән танышкач, аңа күчтем. Сеңлемнең ире Лениногорск районыннан иде. Шунда күчәргә булдылар. Берсүзсез фатирны сатарга ризалык бирдем. Кияүгә чыкканда Наташаның бирнәсе юк иде бит, бирнә булсын, дидем. Алар районга күченде. Ике кызлары бар. Ә минем балам булмады. Шушы хәлгә төшкәч, Наташага шалтыраттым. «Безнең урын юк», – диде. «Ярар, алайса синең өчен мин үлдем», – дидем. Ул минутта йөрәккә пычак кадагандай булды. Сеңлем минем… Наташам… Мине ташлады… Җаным үлде минем. Монда яшәүчеләрнең барысының да җаннары үлгәндер ул. Аякка баскач, бер иргә димләгәннәр иде. Юк, дидем, чит ир кирәкми. Минем ирем бар иде, бар һәм булачак. Үзенә дә исән вакытта шулай дидем. Баш очымда түбә булсын өчен генә чит ир белән яшәмәячәкмен. Монда ялгызым этләрем-песиләрем белән яшим мин… Терелеп беткәч эшкә урнашып, берәр почмак табармын дип хыялланам. Җаным үлсә дә, үзем исән калдым бит әле…

«Эшче йорт»лардагы йортсызлар

Тоткынлыктан азат ителүчеләр өчен тернәкләндерү һәм адаптация үзәге «Кеше приюты»н ике ел элек оештыра. Аның җитәкчесе Азат Гайнетдинов әйтүенчә, әлеге проект кысаларында ике ел эчендә 60 мең кешегә ярдәм иткәннәр. Җиде меңгә якын кеше төн кунып чыккан. Приютта көн саен 300 порция ризык өләшәләр. Ачылган көннән бирле яшәүчеләр дә бар. Күпме телиләр, шуның кадәр яшиләр. Приют урнашу урыны да үзгә. Базарның бу өлешендә гомер-гомергә куллану вакыты чыккан азык-төлек, иске киемсалымнар сатканнар. Монда шәһәрнең төрле почмагыннан социаль хәле начар булган кешеләр сатып алырга йөргән. Йортсызларның төп урыны булган тимер юл вокзалы да ерак түгел. Монда хәтта күрше төбәкләрдә хәерчелектә яшәгән күп балалы гаиләләр дә килеп киенеп китә икән.

– Торыр урыны булмаган кешеләр күпме Казанда?

– Төгәл санын беркем белми. Әмма пандемия вакытында алар бермә-бер күбәйде. Ике ай эчендә 6 мең кешегә ярдәм иттек. Безнең приютта төн кундырырга урын җитми иде, идәндә йокладылар. Казанда «Эшче йорт»лар күп. Чит төбәкләрдән йортсызларны ташыйлар. Йә эчүдән, наркотиклардан дәвалыйбыз дип җыеп алып киләләр. Имеш, хезмәт белән дәвалыйлар. Аларда якынча бер мең ярым кеше яши. Чынлыкта алар – эш бирүчеләрнең коллары. Коммуналар булып бик начар шартларда яшиләр. Шәһәрдә эш бар, шуңа күрә әлеге бизнес бик таралган. Ә пандемия башланып эш тукталгач, аларны урамнарга куып чыгардылар. Кайтырга акчалары юк. Безгә килделәр. Башка вакытта да «Эшче йорт»лардан качып килүчеләр бар. Бу проектны йортсызлар белән генә эшләрбез дип башлаган идек, әмма андыйлар барлык мөрәҗәгать итүчеләрнең 20 проценты гына. Калганнары – хәерчеләр.

– Пандемиядән соң вазгыять ничегрәк?

– «Эшче йорт»лар ишекләрен кабат ачкач, азайдылар азаюын. Әмма хәерчеләр кимеми. Әле менә тагын бер вагон алып кайттык. Бөтенесе 18 булды. Урамнарда тәгәрәп яткан йортсызлар беркемгә кирәк түгел. Аларны алып кайтып юындыргач кына хастаханәгә озатабыз. Без үзебезне санитарлар дип атыйбыз.

– Аңлавымча, автономияле коммерциясез оешма булганлыктан, меценатлар хисабына гына яшисез бит. Ә дәүләт-шәхси партнерлыгы турында уйламыйсызмы?

– Әйе, меценатлар ярдәме белән эшлибез. Зур грантлар да отканыбыз юк. Әллә яза белмибез шунда… Әлбәттә, дәүләт-шәхси партнерлыгы белән җиңелрәк булыр иде. Бина төзер идек. Приют бит су белән дә тәэмин ителмәгән.

Уйлап карасаң, әлеге социаль проект җәмгыятьтә җинаятьчелекне профилактикалау буенча да эш алып бара. Бүген йортсыз калган кеше иртәгә җинаять кылырга мөмкин, чөнки ул – чарасыз. Ә монда, ничек кенә булмасын, баш өстендә – түбә, өстәлдә кайнар ризык бар. Эшкә урнашып, кабат дөрес юлга кереп китәргә мөмкинлек зур. Тормыш упкынына тәгәрәргә бер адым калган кешеләр өчен приют – җылылык, тукլану һәм кешечә мөнәсәбәт чыганагы. Яшәү өчен иң кирәкле шартлар болар. Димәк, адашканнар өчен ул маяк булып тора. Йә ул югарыга менәргә тырмаша, йә түбәнгә тәгәрәвен дәвам итә…

Тормыш төбендә яшәүчеләргә ярдәм итү дә, аларга карата билгеле бер мөнәсәбәттә булу да – һәр кешенең шәхси эше. Әмма уйлап карагыз әле, сезнең өчен алар – кем? Бу юлны үзе сайлаган сәрхушләр, ялкаулармы? Язмыш җәзасыннан интегүчеләрме? Җиде юл чатында адашучылармы? Бәхетсез җаннармы? Бу җавапларның һәркайсы дөрес булыр. Һәм ул җавап безнең хакта да сөйләр. Бу кешеләр – безнең күңел көзгесе, җәмгыятьнең хәл-халәте.



ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТОСКАНА!






Фото: Анна Арахамия



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Греция, Италия, Испания, Франция йә булмаса Грузиягә виноград плантацияләрен күрергә барам дисәм, күпләр, шиксез, ышаныр иде, әйеме?! Ә үзебездә, Казаннан ике сәгать тирәсе генә ераклыкта япан кырны виноград башкаласына әйләндергәннәр, дисәм?!

Чынга ашкан хыял – нигезенә үҗәтлек салынган төпле максат ул.

– Виноградлар август уртасында өлгерә башлый, әйдәгез, шул вакытта очрашыйк, – диде Татарстанда иң күп виноград җирләрен биләүче фермер Айрат Ялалетдинов телефон аша сөйләшкәндә.

Үзебезнең якларда күпләп виноград үскән җирне күзалларга тырышып, август ахырын көтеп җиткердек тә юлга кузгалдык.

Безнең республикада тырыш халык яши. Җирнең кадерен белеп эш оештыручы уңган фермерлар елдан-ел арта бара. Бәрәңге, кыяр-помидор, җиләктән мул уңыш алучылар күп икәнен беләбез. Әмма виноград үстерергә алынучылар сирәктер. Шул сирәкләрнең берсе Кама Тамагында яши.

Юл буе безне агачлар арасыннан күренеп калган яшел кыялы Иделнең гүзәл манзаралары озатып бара. Район үзәге Кама Тамагына килеп җиткәч, Уразлы (Татар Каратае) авылы ягына таба – уңга борылабыз. Уңыш җыеп алынган саргылт кырларны узабыз, тезелеп киткән зур-зур теплицаларны, ә аннан соң... Аннан соң тигез рәтләр булып сузылган, күз күреме белән генә иңләп булмаслык виноград кыры янына туктыйбыз. Чып-чын виноград плантациясе! Җете яфраклар арасыннан төшкән кояш нурларыннан гына түгел, эре-эре виноград тәлгәшләренә карап та күзләр камаша...

Безне үзен Катя дип таныштырган яшь кенә ханым каршы ала. Рөхсәт алып, фотографыбыз Аня белән виноградлар арасына «чумдык». Шундый гаҗәеп хис! Үнда-сулда яшел, кызгылт, куе зәңгәр, шәмәхә мул виноград чуклары, безелдәп, каяндыр умарта кортлары очып чыга... Астан – дымлы һава белән Идел култыгыннан килгән үзгә җил биткә бәрелә. Тулышып пешкән үтә күренмәле тәлгәштән хуш исле виноград өзеп кабам да ләззәттән күзләремне йомам...

Сицилия дә түгел бу, Тоскана да... Грузиядәге Ртвели – нәсел-нәсәп, җыелышып, шау-гөр килеп виноград җыю бәйрәменә дә эләкмәдем. Әбием хикәятләрендәге җәннәт бакчасыннан күчереп утыртылган йөзем агачлары чынлыкта үзебездә дә тамыр җибәрә ала икән! Бездә дә коньяк илләрендәгедән ким булмаган виноградлар үсә! Ә тәме-е-е!

Ул арада теплицалы кырдан Айрат үзе дә килеп җитте. Танышуга, беренче соравымны бирергә ашыгам:

– Ни өчен виноград? Тәвәккәллек, фантазияң ничек җитте?

– 2015 елның ноябрь ахыры иде бугай ул. Чуашстан белән Татарстан чиген узганда, зур мәйданда җир сатыла дигән бер белдерүгә күзем төште. Менә шул мизгелдә, минем дә шуның кадәр җирем булса, нәрсә эшләр идем икән дигән бер наян уй керде генә бит башка! Кайчандыр ниндидер зур эшләр башкарырга хыялланып йөргән чакларым искә төште... Шушы уй зур хыялга җирлек бирде. Янып, кабынып киттем, үземне зур җирләр хуҗасы итеп тоя башладым. Тик нәрсә утыртырга? Әти-әнием белән Ульяновскида яшәсәм дә, һәр җәем авылда уза иде. Юк, бәрәңге эшкәртергә, җирдә эшләргә яратканга кайтмый идем инде мин анда, әти-әни эштә булганга кайтаралар иде. Шуңа күрә үз җиремә бәрәңге утыртмасымны башта ук яхшы аңладым. Җиләк? Яшелчә? Юк, мин башкалар утыртмаганны утыртырга тиеш идем! Ульяновск шәһәрендә танышларымның виноград үстереп сатулары искә төште. Аларга кунакка киттем. Шул баруда сөйләшеп, киңәшеп, бизнес-план да төзеп кайттым. Дәфтәргә язылган план буенча бар да шундый кызык, мавыктыргыч кебек тоелды. Сатып алырга җир, акча табасы һәм эшне оештырасы гына калган иде... Әле бит мин җир кешесе дә түгел. Алты ел бармен тәҗрибәсе булган, юрист белеме алган шәһәр малае!


Ел башыннан ук сатып алырга җир эзли башладым. Һәм менә бу якларга килеп, үземә җир алдым. Май аенда инде 648 төп виноград үсентесе утыртып чыктык шунда. Аннан үзебезнең үсентеләрне үрчетә башладык...

– Айрат бер әйтсә, үз дигәнен итми калмый инде ул, – дип сүзгә кушыла хатыны Катя. – Нәселләрендә, бәлки, авылларында да рус кызына өйләнгән бердәнбер кешедер ул! Айратның әби-бабасы Батыр районы Шыгырдан авылыннан. Ул яклардагы халыкның дингә, гореф-гадәтләргә ни дәрәҗәдә тугры икәнен үзегез беләсез! Ульяновскида Айратлардан бер йорт аша гына яши идек. Очрашып йөрүләребезгә җитди карамадылар әле башта. Өйләнешәбез дигәч, төрле фикерләр булды, әлбәттә. Безнең язмышны Айратның Камәрия әбисе хәл итте. Ул нәселне тотып торучы, ахыргы сүзне әйтүче иде. Танышырга кайткач, Камәрия әби, ничектер, мине якын итте, яратты, безгә үзенең хәер-фатихасын бирде. Никахыбыз виноград утырткан вакытка, эш кайнаган чорга туры килде. Айрат никахка ике-өч көнгә генә килде дә, яңадан үсентеләре янына кайтып китте. Безнең бал ае да, тормыш башлап җибәрү чоры да шушы виноград кырлары белән бәйле. Җаны-тәне, бар күңеле белән Айрат бу җирнеке хәзер. Виноград үстерергә дип, шәһәрне авылга алмаштырган кеше.

...Эшнең башында Айратка Катя исемле нәфис кыз гына ышана, һәр гамәлен хуплап тора. Бу кырларда виноград үстерәчәкләр икән дигәнне ишеткән җирле халык тел шартлата. Безнең җирлектә?! Виноград?! Бармагын чигәсенә төртеп күрсәтүчеләр дә табыла хәтта. Япан кырда плантация үсеп чыгасына кем ышансын ул чакта! (Кеше эшеннән көлеп, чигәсенә бармак төртүчеләр – бер урында таптанган, ә хыялына ышанучылар алга киткән заманда яшәвебезне онытмаска кирәк тә бит!) Айрат белән Катяның да әле ут, су үткәрелмәгән кырдагы сарайда яшәп, бөтен кыр эшләрен

– Ничек үстерә алдыгыз? – дим.
– Яратып! – ди ул.









үзләре генә алып барган чаклары да, Ульяновск–Кама Тамагы–Казан юлын бер итеп чапкан вакытлары да күп була. Эшен башлап җибәрүче фермер буларак, грант алырга гариза биргәч тә, кире боралар Айратны. Булдырасын тир түгеп исбатлагач, икенче елны гына бирәләр миллион ярым акчаны.

Ә Айрат һәрвакыт ышана. Булдырасына, уңыш аласына, үсентеләрнең бу җирләргә ныклы тамыр җибәрәсенә ышана. Һәм сабыр итә. Чөнки виноград үсентесеннән уңышны бары өченче елны гына алып буласын әйбәт белә ул. Утырткannan соң, куакның көче тамырга китсен өчен, икенче елны чыгарган тәлгәшләрен кисеп ташлыйлар. Ә ныклап торып уңышны виноград куагы биш-алты елдан соң гына бирә башлый икән. «Бер төптән 15 килограмм уңыш алу – әйбәт санала. Көньякта үскән куаклар 50–60 килограмм виноград та бирә ала дип укыдым, тик бездә түгел инде… Шунысы яхшы: виноград агачы ел саен яшәреп бара, аны кабат-кабат утыртасы юк. Грециядә 150 еллык куаклар да үсә дип укыдым. Алардан инде бер елга тонналап уңыш алалар», – ди Айрат. Күрше кырдагы теплицаларында да виноградлар үсә икән. Андагы үсентеләргә кырау, кинәт килгән салкыннар инде куркыныч түгел. Кул хезмәте дә аз китә – барысы да автоматлаштырылган. Теплицада виноград үстерү инде сыналган ысул.

Бүгенге көндә Ялалетдиновлар алты гектар мәйданда җиде мең төп виноград үстерә. «Преображение», «Рада», «Чарли», «Гарольд», «Эфиоп», «Орион»… Сиксәннән артык сорт! «Ел саен яңа сортларны сынап карыйбыз. Әле Кырымнан көньяк коллекциясенә кергән сортларны да алып кайтып утыртасы килә. Виноград культурасы гел үсә: нинди генә экспериментлар ясамый белгечләр! Менә сезнең ландыш чәчәге исе килеп торган виноград авыз итеп караганыгыз бармы? Ә акация исе килеп торганын?! Ул сортларны да теплицабызга алып кайтып утыртып карарга булдык, ничек уңыш бирүен күзәтәбез», – ди үз эшләре белән мавыккан Ялалетдиновлар.

Менә шулай ялан кыр әкренләп хуш исле плантациягә әверелә. Виноград сатып алучылар гына түгел, туристлар да килә монда! Россиянең төрле шәһәрләреннән, күрше төбәкләрдән, республика районнарыннан…

– 2016 елда ук җимеш бирә торган агачлар утырткан булсак, бүген инде ниндидер өстәмә керем турында да сөйли алыр идек, – ди фермер. – Ә без һәр елны яңа үсентеләр утырта бардык. Утырткан берсе, әйткәнемчә, шундук җимеш бирә дигән сүз түгел, сабырлык белән килә торган уңыш бу. Татарстанда мондый ук зур күләмдә булмаса да, виноград үстерү белән мавыгучылар бар. Кемдер шәраб ясый торган техник сортларын, ә кемдер аш-су өлкәсендә кулланыла торган эреләрен генә үстерә. Ә бездә тегеләре дә, болары да үсә, барысына да аерым игътибар, вакыт кына кирәк!

– Ул гел шулай, – дип елмая Катя. – Вакыт юк дип зарланып йөри-йөри дә, эшен тагын бер гектарга арттырып куя. Бервакыт машинада барабыз. Айрат, бернәрсәгә дә өлгермибез, дип зарланган арада: «Ә бәлки безгә җиләк тә утыртыргадыр?» – дип куймасынмы! Шаярта дип кенә уйладым. Ә ике көннән кырга килсәм кап-кара булып торган җиләк урыннары казып куйган! Менә хәзер безнең җиләк һәм бөрлегәннәребез дә бар инде… Күңеле үсеп эшләвен күреп исакылларым китә кайчак! Өйгә вакытында кайтырга гына җае юк әлегә. Кичке ашны ашаганда гына күрешеп-сөйләшеп калырга өлгерәбез. Күп эшне икәү генә башкара идек, соңгы ике елда ярдәмчеләр дә ала башладык. Быел җәй безгә мәктәп укучылары булышып, үзләренә акча да эшләп алдылар. Әлегә сезонлы эш белән генә тәэмин итә алабыз, әмма киләчәккә зуррак планнарыбыз да бар.

Айратның иртәсе итальян фермерыныкы белән охшаш. Беренче кояш нурлары белән бергә кырларына ашыга ул. Виноград рәтләрен йөреп чыга, өлгергән тәлгәшләрне бәяли, иминлекне тикшерә, көнлек эшләрне барлый. Бите кояшта каралган, үҗәтлеге, эшлеклелеге йөзенә чыккан хуҗа үзе дә кайнар йөрәкле итальян фермерларыннан ким түгел! 35 яшьлек дуамал егет йөрәге генә япан кырны курыкмыйча виноград бакчасына әйләндерә ала торгандыр!

– Виноград үстерүнең үзенчәлеге шунда – эшеңнең уңышы үзеңнән генә тормаганын, һава торышы белән дә бәйле икәнен аңларга кирәк. Бер елны җәй бик яңгырлы булды. Виноградларның күбесе шартлап ярылды ул чакта. Көзнең ничек килүенә карап, октябрь ахыры – ноябрь башларында өске куакларны кисеп ташлап, виноградны җиргә күмеп, кышка әзерли башлыйбыз. Төрле ысуллар кулланып карадык, әмма иң ышанычлысы – саламлы туфрак белән күмү. Тычканнар да ияләшми, туфракның җылысын да саклый. Көз ахырында кышка әзерлекне тәмамлыйбыз да, яз башыннан яңадан эшне башлыйбыз. Виноград җылыны ярата, температура +10 булганда уяна, яңа үсентеләр чыгара, яфрак яра. Җәй буе тартылып үссен өчен, ул чорда инде аны махсус сузылган җепләргә үреп куябыз. Аш-су өчен кулланыла торган сортлар су ярата, «Изабелла», «Одесский» кебек техник сортларга су сипмәсәң дә ярый. Җәй буе гөмбәчекләрдән, кортлардан, төрле авырулардан саклау җаен да табарга кирәк. Безнең җирлектә ничек виноград үстерәсез дигән сорауны еш бирәләр миңа. Бакчаларда үскәнне, нишләп кырда үсмәсен ди ул! Безнең якта бит иртә өлгерә торган сортларны утырталар, шуңа алар салкыннарга кадәр уңыш биреп калырга да өлгерәләр.

Быел август аенда Президент Рөстәм Миңнеханов та күреп китә виноград плантацияләрен. Аның бу җирләргә икенче тапкыр килүе икән инде. Һәр килүендә, үзебездә дә мул уңыш алып булганда нишләп чит җирләрдән виноград алабыз, дип гаҗәпләнә икән республика җитәкчесе.

Баштагы елларда базарга алып чыккач, сатып алучыларга бу эре виноградларның үзебездә үсүен телефоннан күрсәтеп исбатларга туры килгән. Ә узган ел сораучыларга виноград җитми дә калган.

– Кайвакыт, виноградны кабып карыйлар да, әче дип йөз сыталар. Виноград – баллы җиләк (әйе, ул җиләк! – *Р. Х.*), әче икән – димәк, өлгереп кенә җитмәгән!

– Хыялмы? – ди Айрат уйланып. – Бик гади ул минем: һәр куактан 15 шәр килограмм виноград алу! Кайберәүләр әле дә ышанмый миңа, көчеңне юкка әрәм итәсең, диләр. Алар миңа ышанмаган саен, үҗәтлегем арта гына бара. Тырышканда бар нәрсәне дә башкарып булганын исбатлап күрсәтәсем килә!

Хуҗабикә буларак, Катя виноградтан тәмле компот, джем ясау серләре белән бүлешә. Ә 3 яшен тутырып килгән уллары Әмир бу җирдә күптән хуҗа булып йөри, беренче виноградларны да ул татып карый. Айрат, канәгать калып, кырда хуҗа булып йөргән улын күзәтә. «Утыртылганнары исән-сау үссә, минем гомергә дә, балаларыма да җитәчәк», – ди хуҗа кеше.

Кире юлга кузгалабыз. Күз алдында мөлдерәп торган виноград тәлгәшләре. Колакчында – Булат Окуджава җыры:

Виноградную косточку
в теплую землю зарою,
И лозу поцелую,
и спелые гроздья сорву,
И друзей созову,
на любовь свое сердце настрою.
А иначе зачем
на земле этой вечной живу?

СҮЗ УҢАЕННАН

Виноградның төше һәм яфраклары бигрәк тә файдалы. Шуңа күрә виноградның төшен дә чәйнәп йотарга киңәш итәләр. Депрессия, стресска каршы торучанлыкны арттыра торган тонофелол, кальций, калий, Е витамины, аксым һәм төрле витаминнарга бай. Виноград төше организмның картаю процессын тоткарлый, бит тиресен яшәртү, дымландыру үзлегенә дә ия.
Ә менә безнең өчен виноград нәрсә ул? Табын түренә куела торган татлы җиләк-җимеш, тәмле күчтәнәч?! Без әле бу культураны бәяләп бетермибез сыман. Виноград – борынгы грек мифларында ук искә алына. Ул – гаилә, гаиләдәге тормышның матурлыгы һәм ныклыгы, уңыш, байлык, тырыш хезмәт символы. Виноград куагына гына күз салыгыз. Көчле тамырлары белән җиргә тоташып үскән ботакның нык кәүсәләре вак җепселләр булып тирә-якка сузылган. Яшел яфраклар югарыга үрмәләгән. Беренче карашка ук аның ниндидер бер шәҗәрә агачын, тормыш символын хәтерләтүе юкка гына түгелдер. Кешелек тарихын озата барган, мәдәниятькә, грекларның мифларына, рәсем сәнгатенә, халык һөнәрчелегенә тәэсире булган, изге китапларда искә алынган... Тулышып пешкән сусыл виноград кәүсәсе – уңдырышлылык һәм муллык билгесе. Ә виноград белән бәйле йолалар, бәйрәмнәр?! Шифа-дәвасы?! Яңа гына өзелгән виноградның яки киптерелгәне – йөзем җимешенең йөз төрле сырхаудан шифа булуын Әбугалисина үзенең дәва китабында ук язып калдырган. Ә үзебезнең йөземле бәлешләр, гөбәдияләребез?!
Борынгы заманнарда виноградның көченә ышанганнар, байлык билгесе итеп күреп, аның рәсемен тәңкәләргә төшергәннәр. Патшалар яу белән килгәч, беренче чиратта башка дәүләтләрнең виноград бакчаларын юк итәргә тырышкан...
Йөзем җимеше бакчаларының безнең җирлектә баш калкытуын – җиребезгә килгән уңыш, дәүләт билгесе дип кабул итик.

САНАУСЫЗ ЧАКРЫМНАР

– Аларның һәрберсенең үз холкы... Аның әйткән сүзләренә башта ышанмыйча карыйсың. «Менә шушы тау кадәр тимер-томырның нинди холкы булсын инде?! Җаны юк лабаса!» – дип аптырап уйлыйсың. Әлфиянең ничекләр итеп яратып, бирелеп, онытылып сөйләвен тыңлавыңны дәвам итәсең дә, аннан... килешәсең! Бар! Һәр скважинаның, чынлап та, үз холкы бар!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Фото: Анна Арахамия

Нефть сәнәгате тармагында хатын-кызларныкы дип кенә санарлык һөнәрләр, гомумән, бик аз.

– Сез көлмәгез генә, яме... Килеп туктауга мин алар белән сөйләшә башлыйм. Әйе, сөйләшәм! Кемдер гөлләре белән сөйләшә, ә мин менә – скважиналарым белән... «Хәлләрегез ничек?» – дип сорыйм. Барысы да тәртиптә икән, «матурым», дип мактап алам. Кайсысын яратып кына шелтәлим дә: «Тагын пычрандыңмы?» – дим. Каушап, ашыгып эшләп, ташып түгелүчеләре дә булгалый шул...

...Лениногорск нефть техникумын тәмамлаган кызның: «Диплом алуга Себергә китәм!» – дигән хыялы тормышка ашмый кала. «Анда ир-атларны гына алабыз», – дип кире боралар. «Үзең япь-яшь, буең да кечкенә...» Монысын кычкырып әйтмәсәләр дә, шулай уйлауларын яшермиләр. «Азнакайнефть» идарәсенә нефть һәм газ чыгару буенча оператор итеп җибәрәләр аны. (Бик җырлыйсы, сәхнәгә чыгасы килсә дә, тирә-юньдәге бөтен кеше: «Син әтиеңә охшаган! Аның кебек булырсың!» – дип кабатлап торгач, гомер буе «Азнакайнефть» идарәсендә баш инженер булып эшләгән нефтьче әтисе юлын сайлый шул. Химия фәненә тартылу да үзенекен итә бугай. Югары белем алу теләге дә хыял гына булып кала. «Кызым, андый мөмкинлегебез юк», – ди, инде чирле әнисе.) Хәер, монысын да «хатын-кыз эше» дип әйтү авыр. Әмма Әлфия үҗәтләнеп тотына: «Әллә аны булдыра алмас дисезме?!»

Беренче эш көне? Аны ничек онытасың?!

1984 елның апрель ае була. Яз кояшы әле киптерергә өлгермәгән басуга кереп кара син бу вакытта! Саз ерып... Иңеңдәге биштәреңнең авырлыгына итегеңә ияргән балчыкның авырлыгын да кушып... Юк, кереп кенә карама, көненә 15–20, хәтта 25 чакрым уз!

– Әйе, апрель ае иде. Ташу вакыты... Мине Газинур Габдрашитовка «напарник» итеп куйдылар. Ул миннән ике яшькә генә зуррак булса да, инде күпкә тәҗрибәлерәк. Россия Федерациясенең почетлы нефтьчесе ул хәзер... Бер скважинага бардык, икенчесенә... Саз итегемнән менә керә, менә керә... Күңел тулды – үземне жәлләп еламакчы да булам... Газинур хәлемне аңлады бугай. «Ярар, Әлфия, син шушында, юлда гына басып тор, мин хәзер скважинага үзем кереп чыгам», – ди...

Бәлки кемдер: «Түзмәс, борылып китәр», – дип тә уйлагандыр. Ә ул кала. Менә инде 36 ел бер үк идарәдә, алай гына да түгел – бер үк бригадада эшли. Беренче тапкыр декрет ялыннан бик борчылып чыга ул: «Яшь бала белән мине кире үз урыныма алмаслар инде...» – ди. Өлкәннәр исә читтән карап, сынап йөргән икән! Мөнирә исемле бер хезмәттәше: «Ничек шундый тырыш кызны алмыйк инде?! Көчең җитмәгәндә, сальникларны елый-елый сала идең – барыбер булдыра идең бит», – ди.

Дүрт дистәгә якын ел эчендә ул узган чакрымнар?

Моны санап, исәпләп чыгарып буламы икән? Һәм шуның бик күбесе җәяү бит әле! Күз алдына китерү дә авыр – кояш яндырырлык булып кыздырганда да, яңгыр астында да, кар ерып та, буранда да... Көн саен!

– Ә миңа басу түреннән атлап бару ошый иде! Мәктәптә укыганда безнең бөтен җәйләр әнинең туган ягында – Алабугада, Тойма елгасы ярында узды. Әнинең апасы безне – бала-чагаларны җыя да басуга алып чыгып китә иде. Иркендә чабышып уйныйбыз, ә ул җыр суза... Әни ягы бик музыкаль безнең. Бабай үзе скрипкада уйнаган, шушы кызына – Гамилә апага да баян алып биргән. Апа баянда уйнаса, биемәс җиреңнән бии башлыйсың... Әнинең дә тавышы бик матур иде. Кечкенә чакта гел Галимә апа кебек кырга чыгып җырларга хыяллана идем. Гомер буе җырладым менә... Басу түре буйлап яки урман эчендә кычкырып җырлый-җырлый атлыйсың. Тирә-юньдә беркем юк. Аяк астыннан пырхылдап урман тавыклары гына очып чыга...

Җыр аруны да онытдырган, куркуны да. Кыргый этләр чорнап алган чаклар да булган, котырган төлкеләр ташланган вакытлар да.

– Шактый читтә урнашкан бер скважинабыз гел ватыла башлады. Кызлар белән: «Моңа җен урнашты бугай», – дип көләбез... Берсендә барып җитеп, эшли генә башладым, этләр өрергә кереште. Башта аңламадым да әле – этләрме, бүреләрме? Соңгы вакыт бүреләр дә күренә дип сөйләгәннәр иде. Тезелешеп утырдылар – карап торалар, китмиләр... Бәхетемә, кыргый этләр генә булды бугай. Кайдан ярдәм көтәсең андый чакта – тирә-юньдә ялгыш та бер кеше юк.

Котырган төлкеләр дә шактый очрады. Бер очрак гел истә. Һәрвакыттагыча җырлый-җырлый кырдан барам шулай. Күз кыриеем белән күрәм – миңа таба төлке килә. Начар гына, йолкыш кына... Гадәттә, кычкыргач, качалар, ә моның исе дә китми. Яныма килеп җитеп туктады да, ырлый башлады. Кулымда скважинага элеп куярга дип алган пластмасс плакаттан кала берни юк. Биштәремдә авыр тимер ачкыч бар да соң, тик аны ничек аласың?! Кулыма сикерә дә, китеп карап тора. Плакатымның яртысын сындырды сикерә торгач. Чабып качарга уйладым. Һаман артымнан килә. Бер чокырга җиткәч кенә калды, артымнан менмәде... Эштә тә төрле вакытлар булды. Куркыныч булган чакларны әйтәм. Элек бригада йортларында ял көннәрендә берәр генә кеше эшли идек. Берсендә минем дежур вакытымда басым күтәрелде. Шундук мастерга хәбәр иттем. Әмма алар килгәнче беренче чараларны күрергә кирәк. Андый чакта «аварияне бетерү планы» буенча эшлибез. Иң беренче эш

«Оператор булып эшләү өчен, беренче чиратта, сәламәтлегең яхшы булу кирәк», – ди ул.

итеп краннардагы эшерелмәләрне тикшерергә кирәк: шулай тиеш дип табасың икән – ябарга…

Әңгәмәдәшемне тыңлый-тыңлый, операторның вазыйфаларын күңелемә сеңдереп, санап барам. Кем әйтмешли, тавык та чүпләп бетермәслек бугай аның эшен.

Скважина янына килеп баскач, иң элек ул аның тышкы гомум күренешенә бер кат күз салырга тиеш: барысы да тәртиптәме? Һәр җиһаз урынындамы? Стандарт буенчамы? (Бүген нефтьчеләрнең иң үзәгенә үткән нәрсә – төсле металл караклары бугай. Алар үзләренең кара ниятләрен чынга ашыру өчен вата да, җимерә дә, сафтан да чыгара.) Аннан – скважинаның тавышын тыңларга: үзгәрмәгәнме, бер көйгә эшлиме, көчәнмиме? Әйе, оператор, беренче чиратта, бик игътибарлы булырга тиеш.

Шушыннан соң гына иртән алган заданиеләрне үтәү башлана: пробалар алу, сальникны тикшерү… Куркынычсызлык кагыйдәләре таләп иткәнчә, скважинаның тирәюнен тәртипкә салу, җәен өч метр арадагы үләнне гел чабып тору, скважинаны буяу – боларын да оператор эшли. Буяу дигәннән, нефть чыга торган районнарда кырдагы «качалка»ларның төрле төскә буялганына игътибар иткәнегез бармы? Исегездә калдырыгыз: скважина яшелгә буялган икән, димәк, ул девон нефтен, ә сары төскә буялганнар – сероводородлы, ягъни күкерте күп булган нефтьне суырта.

Элек һәм хәзер. Әлфия белән безнең сүз гел шул тирәдә әйләнә. (Бер урында озак еллар эшләгән кешенең чагыштыру мөмкинлеге зур бит аның!)

Элек бер скважинадан икенчесенә гел җәяү йөргәннәр. (Кышын чаңгыда йөрүләрне санамаганда.) Көн аралаш – 15–20 чакрым! Ул аяклар ничекләр түзде икән?! Хәер, квадроциклга, снегоходка күчеп утырганнарына әле дүрт кенә ел. «Шундый яңалык булырга тора. Правага укыйсызмы? Йөртергә өйрәнергә телисезме?» – дигәч, бригададагы хатын-кызларның күбесе башка эшкә күчкән. Ә Әлфия: «Мин өйрәнәм!» – дигән.

– Квадроциклда элеккечә җырлап йөреп булмый инде, әлбәттә… Әмма рәхәт! Эш күпкә җиңеләйде. Кичә менә көн буена 40 чакрым узганмын. Җәяү моның кадәр атлый алмас идем… Аркаңа биштәр асып йөрү дә түгел инде бу: нәрсә кирәк – барысын да төяп китәсең җилдертеп. Дөрес, без тизлекне сәгатенә 30 километрдан арттырырга тиеш түгел. Бу кагыйдәне ялгышып та бозарга ярамый. Әйе, көн матурында йөрү рәхәт кенә. Яңгыр астында сазга батып калган чаклар да була бит әле. Кемдер килеп ярдәм итәр дип көтеп яки елап утыра алмыйсың – квадроциклыңны алга-артка селкетә-селкетә барыбер чыгарасың. Ир-атлар анысына да өйрәтте… Снегоход белән берсендә бик каты буранга эләктем. Бер скважинага барганда чокыр аша узарга кирәк. Шул чокырның икенче ягына ике метр биеклектә кар өелгән икән: «Буран»ым үрә торып басты. Курыктым инде… Әмма снегоходка утырып чыгып китүнең сөенечен бернәрсә белән дә чагыштыра алмыйм. «Мин бит моны йөртәм! Булдырам!» – дип куанасың…

Элек эш киемнәре шактый авыр, хәрәкәтләнү өчен җайсыз булган, ә бүген – җиңел, һәр элементы уйланган. «Буран»да йөрү өчен тегелгән костюмнарыбыз бик җылы, туңдырмый, – ди Әлфия. – Кышын шундый җилле көннәр була бит. Үзәккә үтә иде…»

Элек көн дәвамында оператор башкарырга тиеш эшләрне аларга һәр иртәне мастерлар җыелыш вакытында җиткергән. Ә бүген һәркайсының кулында – смартфон. Компьютер дисәк тә була. Кулыңа алуга мастер, технолог йөкләнгән заданиеләр исемлеген күрәсең. Үтәлгән берсе шунда ук яшел төскә буялып бара.

Элек анализ өчен проба алгач, озак кына кәгазьләр тутырганнар,



ә хәзер проба алган савытка беркетелгән электрон чипны кулдагы телефонга якын китерү дә җитә: анализ кайчан, кайда алынган – шундук диспетчер экранында пәйда була.

Бүген инде скважиналар да автоматлаштырылган. Аларга бәйле бөтен мәгълүмат идарәгә тапшырылып тора – скважиналарның бөтен эш параметрлары күренә. Нииндидер тайпылышлар килеп чыккан икән, шунда ук операторга хәбәр килә: барып сәбәбен ачыклыйсы гына кала. Туктаган икән – скважинаны оператор эшләтеп җибәрә яки киресенчә – туктата. Әйе, төрле чак була... Әмма торбалардан нефтьнең килү күләме тик торганнан гына үзгәрми. Дөрес, хәзер кайбер скважиналар цикл белән эшли: пласт артык көчле булмаганда, бер атна җир маен суырта, бер атна ял итә – аның кабат җыелганын көтә. Скважина ялга туктый икән – Әлфиянең эше кими дигән сүз түгел бу. Ул барыбер көн дә аның янына килергә, һәр җиһазның урынындамы икәнен карап торырга тиеш. Оператор – һәрвакыт барысына да күз-колак!

«Азнакайнефть» идарәсенең Әлфия эшли торган дүртенче номерлы нефть-газ чыгару цехы биләмәләре буенча барабыз. Машина тәрәзәсе артында – кыр буйлап скважиналар тезелгән. Безгә алар бөтенесе дә бертөсле булып күренә. Юлдашыбызга – юк!

– Монысы – минеке! Күптән түгел азрак ташып чыгып, пычранган иде. Юдым... Буярга вакыт җиткән үзен. Элек пирамидасын да үзебез буйый идек. Берәр көн кирәк була иде. Хәзер махсус бригада бар... Монысы да минеке... Җир астында насослар басым белән эшләгәндә торба читеннән нефть-газ ташып чыкмасын өчен, аларга сальниклар – махсус резин боҗралар киертелә. Менә монысы шул сальникны бик тиз ашый. Тагын да холыксызлары бар – сальникны бөкләп бетерә. Алыштыра алмый аптырыйсың. Үпкәләп елыйсы килә кайчак үзләренә... Болар барысы да нефтьне девон катламыннан ала – тирәннән... Көйле генә эшләсәләр сөенәсең инде шуларга... Арада аерым яратканнары бар. Андыйларның кайчак сине нефтькә коендырганын да кичерәсең. Бу тармакта эшләп, җир маенда коенмаган кеше юк инде бездә... Хәтта анализ өчен проба алганда да ташып чыгарга мөмкин ул. Барысы да сәгать механизмы кебек эшләсен өчен кирәк тә без. Ялгышыбыз зур экологик һәлакәтләргә китерергә мөмкин. Ә табигать ялгышуны яратмый... Менә монысы да минеке! Егерме алтау алар минем...

Көне буе бер скважинадан икенчесенә йөргән Әлфиянең эштән соң үзешчән сәнгатьтә катнашырга вакыт тапканына да шаккатам. Сәхнәне гомер буе яраткан ул. Әлбәттә, җырлаган! Эшли башлаганнан бирле чаңгы ярышларында идарә данын яклаган. Җиңеп алган медальләренең саны юк... «Чаңгыда йөрергә ярату – нәселдән килә, – дип көлә ул. – Бабай да гел ярышларда катнашкан. Гел җиңгән. Әмма бер тапкыр икенче урынны гына алган ул. Һәм шуннан соң башка ярышларга якын да килмәгән. Горур булган... Башта – мәктәп, аннан техникум данын яклап йөгердем. «Буран»га күчеп утырганчы оператор кешегә чаңгыда йөри белү бик мөһим иде. Иремә рәхмәт – һәр ярышка чаңгыларымны алдан әзерләп ул озатты. Хәер, концертларга җырларны да без гел икәү сайладык аның белән».

Әлфиянең тагын... «Ворошиловский стрелок» дигән даны да бар. Әйе, атарга ярата! «Минеке!» – ди. Идарә данын яклап әллә никадәр спартакиадаларда катнашкан.

Өч бала тәрбияләп үстергән, аларның һәркайсына югары белем биргән әни кешегә, ир хатынына болар аз түгел, минемчә.

Ике ел элек күпьеллык фидакарь хезмәте, һөнәргә тугрылыгы һәм республика нефть сәнәгате үсешенә керткән лаеклы өлеше өчен «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең мактаулы нефтьчесе» дигән исемгә лаек булган.

Ә быел Әлфия Гыйльметдин кызы Байкина «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә катнашып, «Минем язмышым – минем һөнәрем» номинациясендә җиңү яулады. «Минем һәр скважинамның – үз холкы», – диде ул сәхнәдән. Жюри әгъзалары: «Болай дип үз һөнәрен бик яраткан кеше генә әйтә ала», – дигән нәтиҗәгә килде.

Алар ялгышмаган!



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА















Фото: Анна Арахамия

«ИРТӘДӘН КИЧКӘ КАДӘР ЧИГӘ АЛАМ»

Чигәргә ул укымаган, барысына да үзлегеннән өйрәнгән: татар тамбур чигешенә дә, укалы, шома чигүгә дә, люневиль чигешкә дә... Менә инде бишенче сәгатькә киткән әңгәмәбез барышында ул кул эшендәге техник үзенчәлекләр белән таныштыра, һәм мин үземнең тиздән «чигү буенча профессор»га әйләнәчәгемне сизәм... Мин дә тапкырлап чигәм. Ләкин ул бу хакта ишетергә дә теләми. Чөнки татар чигү гамәли сәнгатендә тапкырлап чигү юк, ди. Алдымда осталардан да оста чигүче утыра. Гадәттә без аны хатын-кыз итеп күреп ияләнгән. Ир-ат һәм чигү... Үтә дә сирәк очракларда гына бу ике сүз янәшә булырга мөмкин. Ни өчен болай дип язаммы? Чөнки аның төркемендә дә ара-тирә: «Ышанмыйм, үзең чикмисеңдер әле. Әйт дөресен», – дип язган хатын-кызлар очрый. Әйе, бар да дөрес, Нурислам СИРАҖИЕВ – татар халкының борынгы һөнәр иясе. Ул – чигүче.



Нурислам, син бүген татар чигү сәнгатен яшәтүчеләрнең берсе. Чигүгә тартылуың кайдан килә?

– Үзем теләп килдем. Әнием дә, сеңлем дә һичкайчан чикмәде. Әбиләрем – Казан арты районнарыннан, аларда да чигү күрмәдем. Әнием һәрвакыт «Сөембикә» журналын алдырта килде. Анда кайчак чигү үрнәкләре басыла иде, мин аларны бик ошатып, җыеп куя идем. Тик ул вакытта чигүле кул эшләнмәләре иҗат итә башлармын дигән уй башыма да килмәде. Бервакыт шәхси татар күчмә театрында уйнарга туры килде, гастрольләр белән авылларга да барып чыктык. Без тукталган Балтач, Арча якларында чигешле әйберләр аеруча күп иде, аларга озаклап сокланып утырганымны хәтерлим әле. Ә менә Чиләбе өлкәсендә иске имляга, гарәп хәрефләре белән татарча укырга-язарга өйрәтеп йөргәндә миңа чигешле сөлге-тастымаллар бүләк иттеләр. Мәскәүдә яшәгәндә исә чын-чынлап чигә башлау теләге туды. Хәзер күп чигәм. Менә яңа гына XIX гасыр татар хатын-кызларының «Алтын каурый каләм» калфагын ука белән чигеп, кулдан тегеп бетердем.

Син – тел белгече, озак еллар буе шуңа укыгансың...

– Рус мәктәбен тәмамладым. Аттестат алганнан соң ук үз мәктәбебездә бер ел татар телен укыттым. Югары классларда укыганда ук мәчеткә бара, гарәп теле курсларына йөри идем. Гарәп телен, дин кануннарын тагын да яхшырак өйрәнер өчен Урта Азиягә чыгып киттем, Фирганә үзәнендә, үзбәк-кыргыз чигендә үк урнашкан Әндиҗанга... Шунда яшәгәндә үзбәк ир-атлары арасында тегү һәм чигү белән шөгыльләнүчеләрне беренче тапкыр күрдем, аларның остаханәләре базар янында ук иде... Алар минем һәрчак киеп йөри торган татар бизәкле, хәтфәсе инде кыршылып беткән түбәтәемне мактый: «Менә бу, ичмасам, татар түбәтәе!» – диләр... Казанга кайткач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамладым, аннары Казан дәүләт гуманитар институтының татар теле, әдәбияты һәм шәрык телләре факультетына укырга кердем. Студент вакытымда Иранда практика үттем. Гарәп теленә мәхәббәтем – балачактан. Кәшифә әбием гарәпчә генә укый-яза белә иде, ул миңа гарәп хәрефләре белән басылган күп китапларны укыды. Институтта укыганда бүрек тегү остасыннан ир-ат каләпүше тегәргә өйрәндем. Кулым остарып беткәч, аларны бизәкләп тә эшли башладым, алучылар да табылды. Кем – туган көнгә, кем – туйга... Кешеләрнең Төркиядән кием-салым ташыган вакытлары иде бу, мин дә елына берничә барып, килолап сәйлән җыеп кайта идем...

Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрының «Кәҗүл читек» спектакле өчен кирәкле бихисап каләпүшләрне дә миңа тегәргә насыйп булды әле.

Диплом алгач, тәрҗемәче буларак, Төркия телевидениесенә чакырдылар, андагы шоу-программа төркемендәге рус цирк артистларына тәрҗемәче булдым, ул тапшыру тәмамлангач, гид булып эшләдем, йөрмәгән җир калмады, тик туган як сагындыра башлады. Чиста диңгездән, эссе көннәрдән туеп, Иделне сагынып кайткан идем, ә ул – тоныклык, көннәр – тоташ яңгырлы... Миңа һәрвакыт яңалык кирәк. Мәскәүгә чыгып киттем, кайта-китә йөреп, анда тугыз ел төрле эшләрдә эшләдем. Вакыт булганда Татар үзәгендә оештырылган хорда да җырладым, теләге булганнарга татар теле дә өйрәттем. Тик барыбер Казанны сагындым, буш вакытларда күңелемне чигү чигеп тынычландыра идем. Башта тамбур чигүе белән мендәр тышы чиктем. Татар ашъяулыгы өчен яшел бәз сатып алдым, шуннан бирле чигүдән туктаганым юк.

Нурислам, синең «ВКонтакте»дагы «Татар (каю, укалап) чигүе» сәхифәңне гел карап барам. Аны ачу теләге синдә кайчан, ничек туды?

– Чигү белән кызыксынып китүем бары тик татар чигүе белән бәйле булгач, интернет аша да шушы темага караган мәгълүматларны эзли башладым, ләкин тапмадым. Шуннан соң «ВКонтакте»да үз төркемемне булдырдым. «Татар (каю, укалап) чигүе» төркеме 2017 елны ачылды, бүген аны меңгә якын кеше укый. Мин бит аны татар телендә генә алып барам! Нигездә, хатын-кызлар яза, сораулар бирәләр, киңәшләр, схемалар сорыйлар. Видеодәресләр урнаштыруымны үтенәләр. Күбесе осталык дәресләре оештыруымны сорый. Мин бу төркемне күңел кушуы буенча, татар чигешләрен бар илләрдә яшәүче татарларга күрсәтү максатыннан оештырдым. Эшләнмәләремне АКШ, Германия, башка чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә сорап, сатып ала.

Дөньяда төрле ысулда чигүче ир-ат бар. Мәсәлән, Кәгъбәтулла бинасы өчен Кисвә чигүне ир-атлар башкара. Оста Мөхәммәд Маһир Хадри да сигез ел буе бәрхет тукымаларга алтын җепләр белән Коръән текстын чикте, китапның тышлыгы гына да тагын ике ел дәвамында ясалды. Бу төр кул эше тиз генә башкарылмаска да мөмкин... Ардырмыймы?

– Киресенчә! Төннәр буе чигәм, рухи ләззәт хисе кичерәм. Эш барышында төрле көйләр, татар җырлары да тыңлыйм. Чигүнең кайбер төрләре бик тиз башкарыла. Мәсәлән, гади

тамбур белән чигү. Тик шулай да бу түземлелек, сабырлык сорый торган хезмәт. Чигү ул тынычландыра, үз уйларыңа бирелеп, чигәсең дә чигәсең. Моны медитациягә тиңләргә була.

Шома, тутырып чигү, сәйлән, Сваровски кристалларын кушып, каеп, укалап, ягъни канитель белән чигү ысулларындагы кул эшләнмәләре иҗат итәсең, һәм алар бик күп тә инде. Аларга ихтыяҗ зурмы?

– Бүген аларны бирнә өчен сораучылар бар. Татар милли бизәкле түбәтәйләр, калфаклар, яулыклар, янчыклар, сөлгеләр, эскәтерләр, кечерәк һәм зур ашъяулыклар, намазлыклар... барысы да кулдан, бик пөхтә итеп чигелергә тиеш. Әзер челтәр ябыштырып, өстенә берәнсәрән сәйләннәр тегеп кенә ясалган калфаклар – ул чын калфак түгел. Әйе, андыйларны ясаучы күп, әмма, миңа калса, алар – замана таләбе. Ә миңа борынгы традицияләре сакланган татар калфакларын иҗат итү күбрәк ошый. Бездә борынгы милли кием сәнгате традицияләре дә сакланырга тиеш.

Бу хезмәткә биниһая вакыт, энергия, кирәк-ярак сарыф ителә. Шуңа күрә күбесе үзе өчен генә чигә. Кайбер хатын-кызларга: «Әйдәгез, өйрәтәм. Үзегез чигеп киегез!» – дим, ә алар: «Ул кадәр түземлелегебез юк, үзең чигеп бир инде!» – диләр. Дөрес, чигү товарлары индустриясе үсештә, хәзер махсус кибетләрдә нинди генә чигү тупланмаларын тапмассың...

Ә ни өчен бер мәртәбә дә тапкырлап чигеп карамадың? Синең кебек оста чигүче иратларның күбесе кул эшләнмәләрен тапкырлап чигә бит.

– Ул җан халәтемә берничек тә туры килми. Мине нәкъ менә татар чигүе кызыксындыра. Хәзер инде кул эшләремә үз тамгамны, туграмны да салам. Сатып алучыларның берсе бик үтенеп сорагач кына кул эшләремә чигеп куя башладым. Чигүчеләр бар, әмма минем кебек ука белән чигүчеләр берничә генәдер, чөнки бу бик катлаулы эш.

Атаклы чигү осталарыннан кайсыларының иҗаты сине илһамландыра?

– Һиндстан чигүчеләре! Анда күбесенчә ир-егетләр чигә. Аларның ничек итеп бик катлаулы, затлы, зәвыклы итеп чигүен күрсәткән видеоларны үз төркемемә дә куям.

Гарәп хәрефле язмалар чигү өчен нинди җөмләләр сайлаганың булды?

– Гарәпчә язмалы футболкаларым бар. Бервакыт җиләк сурәтен сайлап алдым, яфраклары да, җиләкләре дә берничә төсмерле җепләр белән чигелде. «Җәй көннәре ямьле була, / Җиләк вакытларында. / Йөзләреңдә нурлар уйный, / Сөйләшкән чакларыңда» дигән дүртьюллыкны гарәп хәрефләре белән чигеп куйдым.

Программалы чигү машинасы сиңа беркайчан да кирәк булмас, ахрысы.

– Дөрес әйтәсез. Минем һәрчак кул җылысын саклаган эшләнмәләрем генә булачак, иншаллаһ! Берникадәр тәҗрибә туплагач, кем дә программалы чигү машинасы белән чигә ала ул. Миңа даими заказ бирүче бер ханым татар бизәкле алъяпкыч тегеп, чигеп бирүемне үтенде. Ә минем, ничектер, ул чак вакытым тар булды, озак көтмәсен дип: «Казанда чигү машинасы белән чигелгән татар алъяпкычлары күп, шулар арасыннан сайлап алмыйсыңмы соң?!» – дигән идем, үпкәләтә яздым. Аңа нәкъ менә кулдан чигелгән татар алъяпкычы кирәк иде.

Эшләнмәләреңнең төсләре җете. Төсләр сайлаганда махсус игътибар итәсеңме?

– Эш башлар алдыннан нинди төсмерле җепләр белән чигәргә икән дип уйланып утырган чакларым бар. Кайчак чигелгән берәр өлешне төсе туры килмәде дип сүтеп тә аласың... «Энә белән кое казыгандай утырасың...» – ди иде Кәшифә әбием.

Татар чигешләрендә гасырлар буена күп төсләр кулланылган. Бу безнең халыкның милли үзенчәлеге, дөньяга булган карашы... Мин һәрчак җете төстәге җепләрне үз итәм. Хәтта кара тукымага чиккәндә дә якты хисләр тудырырлык бизәкләр килеп чыга. Аннары бер өслеккә өч яисә дүрт төрле ысул кулланып чигәргә яратам. Әйтик, яссы һәм күпертмәле тамбур чигешен, шома чигүне, француз төеннәрен (французский узел), рококо чигешен, Бразилия җөйләрен...

Мондый кул хезмәте төре буенча энциклопедияләрең, әсбапларың бармы?

– Юк дисәм дә була. Барысына да үзлегемнән өйрәнәм. Чигү остасы Светлана Королева эшләрен ошатам. Татар сәнгате белеменә нигез салучы галим Фуат Вәлиевнең татар бизәкләре буенча «Татарский народный орнамент» электрон китабын укыйм. Чигү төрләре буенча чит ил китапларының тәрҗемәләре дә еш нәшер ителә. Тик мин татарча чигү белән генә мәшгуль.

Этник кием модасы популяр хәзер. Бәлкем, сине кайчан да булса Югары мода мәктәбе курсларына укырга да чакырырлар. Андый мәктәпләр берничә дәрестән соң филне дә чигәргә өйрәтә алабыз, диләр. Синең эшләрең белән кайда танышырга мөмкин?

– Эшләремнең бер өлеше – шул төркем диварында. Югары мода мәктәбенә бик теләп барыр идем, анда, чыннан да, югары зәвыклы чигешләр иҗат итәргә өйрәтәләр. Андый бер чигеш төрен үзем дә өйрәнеп карадым. Чит илдән туй күлмәген чигеп бирмәссезме, дип үтенгәннәр иде. Тәвәккәлләп алындым, бизәмнәрне люневиль ыргагы белән люневиль чигү ысулында юка челтәрдә башкардым.

Кулларына энә-җеп алырга теләгән хатын-кызларга нинди киңәшләр бирер идең?

– Чигү киергесе, чигү кысасы, җепләр, чигү энәләре, ыргаклар, тукымалар алынып беткәч, бераздан, менә иртәгә чигә башлыйм дия-дия, чигүләрне алдагы көннәргә күчермәскә кирәк. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләр. Иң элек көчле теләк булу зарур. Башта бик зур эшләргә алынмаска, гадирәк әйберләр чигеп карарга кирәк. Ә инде остарып беткәч, эксклюзив әйберләргә дә тотынырга мөмкин.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА

Реклама 12+

Яр Чаллы
90.2 FM

Казан
93.1 FM



ТАТАРСТАНГА «ТӘРТИП» КАЙТА!



Илмира ГЫЙМАЕВА – Саба якларыннан: Шекше авылында туган, Казан педагогика көллиятеннән соң, Сәрдәдә ясле-бакча мөдире, Саба гимназиясендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләгән. Читтән торып Казан педагогика институтын, Киров өлкәсенең Савали политехник техникумын тәмамлаган. Мәктәп, «Сабагаз» идарәсе, авария-диспетчырлык хезмәте... Һәммәсе Илмираның офыкларын киңәйткән, күңел дөньясын баеткан. Ә хис-кичерешләре – якты, ихлас шигырьләрендә аныңъ.

Көзге халәт

Яңгыр ява...
Шыбыр-шыбыр җырлап,
Тәрәзәмә кага.
Яңгыр үпкән сары яфрак
Яна-яна...

Яфрак ява...
Күбәләкләр кебек уйнап,
Чәчләремне сара.
Җилләрдән калышмый гомер
Ага-ага...

Еллар ява...
Әллә җырлый, әллә елый дөнья,
Йөрәк яна.
Керфекне чылатып,
Яңгырлы яшь тама...

Көз ул шундый

Көз – сихерче! Көз ул шундый!
Күңелне саташтыра.
Адашып йөргән сөюне
Йолдызлар итеп сибә дә,
Җаннарны тоташтыра.

Көз ул – шагыйрь! Көз ул – җырчы!
Җир-күкне кавыштыра.
Моңга тулган күңелләрне
Җылы назына төрә дә
Җырдай шигырь яздыра.

Көз – тылсымчы! Көз ул – яшьлек!
Яздардан да уздыра.
Татлы сабырлыгы белән
Йөрәкне яулап ала да,
Яндыра, һай, яндыра...
Көз ул шундый...

Әбиләр чуагы

Әбиләр чуагы –
Көзнең көтеп алган
Кадерле кунагы.
Күңелләрдә кабат
Җылы җәй сулавы –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Тылсымлы пәрәвез
Яктырта юлларны.
Кабат әрсезләнә
Йөрәкнең дулавы –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Мәхәббәттән шашып
Күңелнең җырлавы.
Ялгыз җаннарның
Илереп елавы –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Көзләрнең асылы,
Уйларның чуары.
Пәрәвездәй нечкә
Йөрәкнең кыллары –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Бигрәкләр дә җылы
Кояшның нурлары.
Гүя чәчтән сыйпый
Әбием куллары –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Күкнең зәңгәрлеге,
Җирнең еш сулавы.
Онытылып тора
Йөрәкнең сызлавы –
Әбиләр чуагы.

Әбиләр чуагы –
Җәйнең чал көзкәйне
Хөрмәтләп зурлавы.
Яктылыкка бәйле
Өмет һәм уйларны –
Әбиләр чуагы.

Әни суган үрә

Яңгыр ява — шыбыр-шыбыр –
Көзме әллә.
Табигатем иңке-миңке
Серле мәлдә.

Үзе салкын, үзе җылы
Тамчылары.
Яшьлек белән күрештерә
Безнең җанны.

Әнине күр! Тыныч яңгыр
Сердәш аңа.
Һәр тамчыдан йөрәгенә
Хәтер тама.

Үткәннәрдән килгән яңгыр
Шыбыр-шыбыр.
Суган үрә җитез куллар
Кыштыр-кыштыр.

Суган үрә әни, гүя
Килен чагы.
Әйтерсең лә карап тора
Сөйгән яры...

Берәү, икәү, ун, егерме
Толымнары.
Шундый тигез, шундый матур
Уемнары.

Җилкенепләр суган үрә
Әниебез.
Безне күрми, хыялында –
Әтиебез...

Яңгыр ява – җәйме, көзме,
Яусын әйдә!
Суган үрә әниебез
Әни – җәйдә...

Алинә Хисамиева – Азнакай кызы. Татар-төрек гимназиясе, Әлмәт нефть институты, «Татнефть» компаниясе... Инженер булып эшләү, икътисад фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешү, иҗат, шигырь китабын чыгару, ике кызын үстерү... Алинәнең биографиясе менә шундый. Ә шигырьләрендә без горур, ярата һәм яратыла белгән, дөньяга фәлсәфи карарга өйрәнгән Алинәне ачабыз.

* * *

Сагынуым сине сап-сарыдан
Кояш төсле җылы бер келәм.
Аяк очларына басам да мин
Келәмемне эзләп йөгерәм!

Ә кайчандыр куе кызыллыкка
Төренгән хис иде йөрәктә.
Кызыл яфрак, агачыннан өзелеп,
И очынды, йөзде үзәндә.

Төссез болытларга тыпырчынып,
Үзгәрергә теләп карады.
Йолдызлы төн күрсә ярсуыннан,
Йокысыннан качып арыды.

Сагынуым сине сап-сарыдан –
Ромашканың сары үзәге.
Ак таҗлары югалганнар күптән
Тик сагыну әйтә – түз әле!
Тик сагыну дәшә – сөй әле!

Шәм

Шәмнән яшь төсле балавыз
Ага да ага,
Сиртмәле юлларны урап,
Күңелгә сала.

Юлдан төшкән күләгәләр,
Уйный җилләрдә.
Канатлы хис-уйлар белән
Очам бүлмәмдә.

Сөю-сөелүләр илен,
Кабаттан гизәм.
Мең богаулы ишекләрнең
Тупсасын сөрәм.

Яшәү-үлем серләренә
Төшенә язам,
Җилнең итәгенә яб(е)шеп
Сызланам, сызам.

Яңгыр тамчылары тып-тып
Тама үзәккә.
Бу тынлыктан тулып-тулып,
Ташый йөрәк тә.

Вакытлыча булды тулу
Ут янды тиздән,
Дөньябыз да зыр-зыр килеп,
Чапты бер эздән.

...Әллә нишләтте бу халәт,
Шәм юкса сүнде.
Җылы уты күңелемә
Яктылык элде!

* * *

Син яшьлектә калган бер күләгәм,
Җырланмаган җырым күптәнге.
Бүген очрап яшькелт-
коңгырт күзләр,
Бер моң булып өзде үзәкне.

Көтеп-көтеп һич яумаган карым,
Карсыз тәүге кышым син минем.
Язлар булып буран дулый күңел,
Тынсыз җимерелгән үз чигем.

Сусыл җиләк эзләгәндә тапкан
Аллы-гөлле чәчәк болыным.
Онытылып шул болында калган
Иярләнгән җитез колыным.

Һич кенә дә буем җитмәс үрем,
Кургаш болытымның дәвамы.
Син бер төшем бүген,
көткән төшем –
Яшьлек хисе бигрәк дәвамлы.

Сайлап алдым

Чуарлыктан туеп. Күңелемә
Сайлап алдым яфрак. Яшелне!
Әй күп алар юкса – сары, кызыл...
Каплаганнар бүген галәмне.

Сынаулардан туеп. Йөрәгемә
Сайлап алдым сине. Тынычлык
Талпынудан димим, яралардан
Азат булсын минем куышлык.

Корылыктан туеп. Бүгенгемә
Сайлап алдым шыбыр яңгырны.
Язда карлар ишеп яусын, әйдә,
Сискәндереп гомер юлымны...

Сәерлектән туеп. Төннәремә
Сайлап алдым сине, шигърият!
Иярт әле мине күкләреңә!
Йолдызларны җыйыйк бергәләп!

Мин

Минем төннәр һич тә соры түгел,
Йокыны үз итми йөрәгем...
Җилфердәп бииләр йолдызлар
Күңелдә.
Мин тоям дөньяга кирәгем!

Минем кышлар бер дә
гамьсез түгел!
Яфраклар эзлим дә кышлардан,
Өзелгән шул алар. Коелган!
Мин көтәм!
Шытканын бөренең яңадан!

Минем төшләр ак-карадан түгел,
Мең төсле төннәрем! Мин очам!
Галәмдә булмаган хисләрдән
Җанымда
Бер үксеп, бер көлеп җил кочам.

Мин кышларда өшерлек тә түгел,
Кап-кайнар йөрәгем! Ник өшим?!
Сүз буар дөньясын яңадан яратам,
Ә җирдә...
Мин куркак! Атлаудан да шөллим...





Нәҗибә САФИНА

ТУКТАЛЫШ

(Хикәя)

Безнең шәһәрне нинди җиргә төзергә белгәннәр. Ничек кенә белгәннәр әле. Таш йортларга ук сыенып торган шәм наратларның тамырларына зыян китергән булсалар, шулай күкрәп, күккә үрелеп үсәр идемени алар. Шәһәребезгә читтән килгән кеше мондагы гүзәллеккә сокланып туя алмый. Ә без күнеккән инде. Агачтан агачка сикереп йөргән тиеннәр дә, атлаган саен очрап торган гөмбәләр, аз гына иелсәң дә, авызыңа керәм дип торган кып-кызыл җиләкләр дә, бихисап чәчәкләр дә безнең өчен гадәти күренешкә әйләнгән. Менә шушы җәен дә, кышын да ямь-яшел урманның бер уемына шәһәрнең автобус тукталышы урнашкан. Аны автопарк эшчеләре телендә «конечная» дип кенә йөртәләр. Бирегә автобуслар шәһәрнең иң зур урамы буйлап киләләр дә, борылып, тукталыш тугаена чумалар. Болын чәчәкләредәй ал, сары, яшел, кызыл автобуслардан төшүчеләрнең кайберләре тукталыш каршында гына урнашкан хастаханәгә кереп кала. Күпләре Парк урамы, Кувыкин аралыклары буйлап тагын кайларгадыр китеп бара. Ә менә инде шау-шулы шәһәрне калдырып, урманга, бакчаларга, Камага балыкка барырга ниятләгәннәре салмак хәрәкәтләр белән Сәламәтлек сукмагы буйлап урман эченә кереп югала.

Тукталышка тагын халык җыела. Яңа пассажирларын алып, автобуслар тагын урам буйлап китә. Көннәр буе шулай.

Бүген мин дә шул автобусларның автовокзалга бара торганын – беренче санлысын көтеп торам. Авылга кайтып, әткәемнең хәлен белеп килергә дип чыккан идем. Тик автобус кына никтер озак көттерде. Хәер, минем бүген ашыгыч сәфәр түгел. Авылга илтәсе автобус та уникеләр тирәсендә генә була. Урман һавасын сулый торыйм дип, иртәрәк тә чыккан идем. Тыныч кына автобус тугаендагы ыгы-зыгыны күзәтәм: килүчеләр, китүчеләр, озатып калучылар...

Менә бер мәлгә тукталыш тугае тынып калды. Мотор тавышлары ераклаша төшкәч, әлегәчә бөтенләй өнсез тоелган нарат урманы талгын җилдә әкрен генә шаулады. Ә инде бер-ике минуттан бу уйсулык кошлар сайравыннан могҗизаи музыка коралыдай уйнап тора башлады.

Нарат энәләре очына эленгән таң чыклары – гүя шул моңнан күңелләре тулган җан ияләренең яшь тамчылары. Алар, кояш нурларында энҗедәй ялтырап, йә тып итеп җиргә тамалар, йә ботаклар буйлап әкрен генә агып төшәләр дә җирне үбеп алалар.

Чынлап та, шәһәребез оҗмах эченә урнашкан икән бит! Өстәвенә, җәй башының тылсымлы кояшы иртәнге нурлары белән дөньяны әкияти төсләргә манган да куйган. Күңел әллә кайларга оча.

Әлеге оҗмах эченнән килеп чыккан ап-ак чәчле, бөкрәя төшкән озын буйлы картны мин тукталыш мәйданына җәелгән ташка таягы белән тык-тык төртеп килә башлагач кына абайладым. «Сәламәтлек сукмагында саф һава сулап йөрүедер», дигән уй йөгереп узды. Тик бу картка карата алай уйлап ялгыштым, ахры. Бабай көч-хәл белән генә килеп җитте дә, мин утырган эскәмиягә чүмәште.
Тын алуы ук аңа авыр икәнен сиздерә. Сөякчел куллары хәлсез генә калтырый. Күзләре... күзләре зәпзәңгәр икән. Шуңа чигәләре буйлап агып төшкән яшьләре дә зәңгәр сыман тоела. Хәле хәл икән дип уйлап куйдым. Мөгаен, хастаханәгә барышыдыр.

Бабай, кесәсеннән кулъяулыгын алып, әкрен генә яшьле күзләрен сөртте. Ак эшләпәсе астыннан чыгып торган сирәк чәчләрен төзәткәндәй итте. Болай да пөхтә киеменә тагын бер кат күз төшерде бугай, соры костюмының җиңеннән күренеп торган зәңгәр күлмәгенең җиң очларын эчкәрәк кертеп куйды. Аннары, шушылай да ярый дигән кыяфәттә автобус киләсе якка күзләрен төбәде. Тәүге автобус күренгәнче ун минутлап вакыт узгандыр, гел бер ноктага төбәлеп торудан бабайның күз кабаклары еш-еш ачылып-йомыла башлады. Мин аңа янә бер сынаулы караш ташладым. Мәһабәт гәүдәле кеше булгандыр яшьлегендә. Ә бармаклары музыкант бармакларымыни – озыннар. Гаять зур үлчәмле туфлиләре ничектер үзенеке түгел сыман тоелды. Тәрәз буын юып төшергәндәй генә итеп зәңгәр күзләренә сарган томан пәрдәсен сөртеп аласым, картларча горур карашын күрәсем килә иде.
Ә пәрдә артында андый караш бар. Шундый караш, картларның мәгънәле елмаюы, үз бәһасен белеп кенә сүз сөйли белүе егет халкының җанын били инде. Менә шул караш-елмаюны ниндидер пәрдә каплаган да, карт үзен кешеләрдән ерактарак хис итә кебек. Әллә ул аларны махсус үз янына җибәрмиме?
Аның үз-үзен тотышы бераз сәеррәк тоелды миңа.

Бабай, түземен җуеп, автобус киләсе якны берничә тапкыр урап килде, тик һаман бер сүз әйтмәде. Аның сөйләшәсе килү теләге зур, үзен никтер тыеп кына тора кебек тоелды миңа.

– Автобус көтәсеңме, бабай? – дип эндәштем мин, сүз югында сүз булсынга гына.

– Көтәм, – диде ул, бер сүз белән генә кистереп. Күзләрендәге томан пәрдәсе ачылып ябылгандай булды, хәтта ниндидер горурлык очкыннары да ялтырап китте кебек.

– Ничәнчене? – дим, сүзне дәвам итәргә тырышып. Бабай исә бер дә сөйләшеп торырга исәбе юк кыяфәттә читкәрәк карап:

– Хәзер килә, хәзер, – дип, авыз эченнән генә сөйләнеп алды. Мин башка сүз кушарга кирәкмәгәнлеген аңлап, тынып калдым.

Урман тугаеның тын шавын изеп, тукталышка автобус борылды. Ул күренүгә, карт кискен хәрәкәт ясап урыныннан сикереп диярлек торды да шактый кызу адымнар белән автобус ишегенә каршына ук килеп басты. Килүчеләрнең төшеп бетүен көтепме, бераз гына читтәрәк торды, тик автобуска утырмады, әкрен генә кире борылып кәнәфигә таба юнәлде. Утырып та өлгермәде, борылышта тагын автобус күренде. Серле карт бу автобус янына да шундый ук адымнар белән килеп басты, төшеп бетүләрен көтеп торды да тагын кәнәфигә килеп утырды.

Тугайга автобус борылуга: «Бабай, әллә дүртенче кирәкме?» – дип авызымны ачкан идем, күзләрендә кырыс караш тотып, тынып калдым. Борылышта тагын автобус күренде. Бабай җил-җил атлап тагын автобус ишеге янына килеп басты. Чыгасы кеше чыгып бетте. Күләгәдә үскән үсемлеккә охшаган карт тагын ялгызы басып калды.

Беренче... өченче... дүртенче маршрутлар...
Инде ничәне каршылады томанлы күзләр. Инде ничәнчедер (мин исәбен дә югалттым бугай) автобус яныннан борылып килгәннән соң, бабай эскәмиянең читенә генә утырды. Моңсу карашын тамчы да болыт кисәге булмаган төпсез зәңгәр күккә юнәлтте. Тукта! Бер мизгел эчендә шундый манзараны күздән кичердем: Лев Толстойның «Война и мир» романындагы Бородино кыры. Бу аның яшәвенең соңгы мизгелләре...

Монысы... Икенче Ватан сугышыннан. Зәп-зәңгәр күзле адъютант, генералын үзенең гәүдәсе белән каплап, кылганнар эченә ауды... Ә күзләре...
Ул чакта мин аларны күз тамчылары дип хәтерләп калганмын.

Чү! Ни өчен бу күзләр минем хәтеремә үлеп барган карашларны кайтарды соң әле? Үлеп баручы... Тик ул сугыш кырында ауганнарның күзләрендә ташып торган тормыш иде. Әнә шундый тормышны өзәр өчен бер тамчы ядрә җиткән. Ә шушы бабайның күк тамчысыдай күзләрендә тормыш сакланып калсын өчен ашыгыч рәвештә нидер эшләргә кирәген тойдым мин! Тамчы кадәр генә...

Уйларымнан айнып киттем. Таягы белән таш юлга тык-тык төртә-төртә, ул әле дә автобус яныннан эскәмиягә таба килә иде.

Нидер эшләргә кирәк! Тик карт үзенең эчке дөньясына бер генә кешене дә кертергә теләми. Сүзгә саран, үзе горур. Җир йөзендә үз вазыйфаларын үтәгәнлекләренә ныклы ышанган ир-атлар гына шундыйрак була. Тик ни өчен кешеләрдән кача соң ул? Әллә бер-бер чире аркасында автобуска менә алмыйча, берәрсе кул сузармы дип көтәме?



Бездә бит күпләр кул сузарга да атлыгып тормый. Әле өлкәннәргә, гарип-горабага сикереп торып урын бирүчесе дә сирәк. Аптыравым соң чиккә житте.

– Бабай! – дим, бераз тавышымны күтәрә төшеп, – син соң кая барасың?

Булышырга әзер икәнемне күрсәтергә теләп, янына ук килеп утырдым. Ә ул соравымны ишетмәгән дә кыяфәт белән карашын каядыр еракка төбәгән. Как яңаклары буйлап күз яшьләре агып төшүен дә тоймаганлыгы әллә каян күренеп тора. Кинәт һич уйламаганда, аяз күктә яшен уйнагандай, бабайның йөзендә елмаю пәйда булды. Эчке дулкынлануын чак җиңеп, калтыранган аксыл иреннәрен хәрәкәткә китерде һәм:

– Минем дә синең кебек зәңгәр күзле кызым... һәм улым бар... – диде. Нигә шулай диде, ни әйтергә теләде – аңламадым. Билгесезлек, әлеге картка ярдәм итә алмау минем өчен тагын да авыррак иде.

– Бабай, – дим, гаепле кеше тавышы белән, – балаларың янына барырга чыктыңмы әллә?

– Юк... – ди ул, тагын өзек сүзләр белән генә, – алар килә...

– Ә-ә, алайса көтәсең...

Бу сүзләрем дә һавада җавапсыз эленеп калды. Мин инде аның автобуска утырмаячагын, ә балаларын көткәнен аңладым. Ник өендә генә көтми икән соң ул аларны? Ник шул гомер көттерәләр? Бабай никләр шулкадәр дә өзелеп көтә? Бик ерактан кайтасылар микәнни? Әмма бу сорауларның берсен генә дә биреп булмый. Ялгыш кагылып, бабайның тулган күңелен түгеп җибәрүдән куркам. Көткән кешесе килеп кенә бу күзләрне каплаган томанны таратачак, яшәү уты кабызачак!

Бабай инде бик нык арыган. Баягы җитез хәрәкәтләре юкка чыккан. Кулбашлары салынып төшкән. Аркасы бөкрәйгән. Таяк тоткан кулы калтыр-колтыр килә. Таш юлга бәрелеп, таягы өзек-өзек авазлар бирә. Әйтерсең тукталышка килүчеләргә морзе әлифбасы белән кемдер дәшеп тора. Тик ни дип дәшә? Ни әйтергә тели ул? Әмма аны ишетүче дә, туктап тыңлаучы да, хәтта картка игьтибар итүче дә юк. Ашыгалар... Киләләр... Китәләр... Каян, кая?.. Уйларымны янибызга ук килеп баскан кызыл төенчекле әби бүлдерде:

– Кызым, роддум дигәннәре кайсысы икән? Бу бүлничный шәһәре дә бик зур икән шул, – дип, күзләремә текәлде.

Үзем дә сизмәстән, әбинең кыяфәтен күздән кичердем. 85 тирәләре булыр. Сөяк кенә куллары нәни төенчекне дә чак-чак кына тота. Туктап сораган булуы да, мөгаен, хәл алып китәргә бер сәбәп кенәдер. Һәрхәлдә, бабайдан күпкә өлкәнрәк дип уйлап алдым. Ләкин хәрәкәтләре, яулык читен төзәтеп куйганда күренеп калган затлы беләзеге, чулпылы нәзек чәч толымнары да, карашыннан бөркелгән мөлаем җылылык та яшәешенең бабайныкыннан үзгә булуын әйтеп тора иде.

– Киленем кыз бала тапты. Янына кертмиләр икән. Коймагым белән чәй генә булса да эчсен дигән идем. Өйдә чакта бигрәкләр яратып ашый иде, – дип, үзалдына канәгать елмаеп куйды һәм бик тә әһәмиятле сүз әйтәсен белдереп, төенчеген ике куллап күкрәгенә якынрак китерде дә бәхетле елмаю аша әйтеп куйды:

– Аллаһы боерса, бу оныгымны да тупырдатып сөям әле...

Әби сүзен әйтеп тә бетермичә туктап калды һәм... шушы яшьтәге кешедән һич көтелмәгән җитез адымнар белән бабай каршысына килеп басты да кулларын сузып кычкырып ук җибәрде:

– Әхәтулла... Әхәтуллагынам! Син түгелме соң?! Менә бит, хәрәкәттә – бәрәкәт, дип, юкка гына әйтмиләр шул аны. Өйдә генә яткан булсам, кайчаннар очраткан булыр идем әле... Нинди җилләр белән?

Әхәт бабай әбигә каршы бер генә адым да ясамады. Тик хәл-әхвәл сорашуына гына: «Шөкер, шөкер, Камәрбану, картаеп буламы?» – дип, көн дә очраш-кан танышына дәшкәндәй сәлам бирде. Әби исә, әгәр шушы очрашу өенә якындарак булган булса, җилтерәтеп табынга алып кертеп утыртасы кеше сыман, бабайның күрешергә сузылган ике кулын беравык җибәрмичә торды. Аннары буш кулын күкрәгенә куеп, аның күзләренә карап сүзен дәвам итте:

– Әхәтулла, бар гомеремне син салып биргән өйдә уздырдым. Җылы, ямьле булды. Инде балаларым олыгаеп килә. Шөкер, өебезнең кыйгаерга уйлаганы да юк. Онproblemsкларымның балаларын да шул өйгә алып кайтырга җыенам. Бар авыл халкы мең рәхмәтле сиңа. Әхәтулла! Үзең соң, үзең ничекләр яшисең? – дип тезеп китте карчык.

Ә бабай исә гел шулай тыныч, тигез генә итеп:

– Шөкер, Алага шөкер, – дип, сүзен тәмамларга ашыкты.

Әби хушлашып китеп баруга, тукталышка тагын автобуслар килеп туктады. Әхәт бабай тагын автобус ишеге алдына килеп басты. Ишектән кулына бала күтәргән хатын белән зур гына сумка тоткан ир-ат күренүгә, йөзе балкып китте. Ике кулын күтәреп, хатын кочагындагы балага сузылды. Шатлыгымнан янына ук йөгереп килдем, тик балалы хатын белән ир кеше картка сәер караш ташлап, артларына борылып карый-карый китеп баргач кына, Әхәт бабай күтәрелгән кулларын төшерде, йөзендә уңайсызлану чагылып китте. Башын кагып куйды.

Ялгышканлыгын төшенгән идем инде, берни булмагандай:

– Килмәделәрмени әле? – дип куйдым.

– Килеп җитмәделәр, юл бит ул. Юлда төрлесе була. Оланнарны да алганнардыр, мөгаен, – диде дә сүзен өзде. Күзләренә тулган моңны ул инде теләсә дә яшерә алмас иде.

– Минем өч онygым бар бит... Күрсәтербез, тыныч кына яшә дигәннәр иде. Инде йөгерешеп йөриләрдер, – диде.

Аннары, кулына чәчәкләр тоткан яшь ананы, биләүдәге баласын күтәргән бәхетле әти кешене автобуска кереп киткәнче тын да алмый карашы белән озатып калды да:

– Менә шулай, биләүдә генә күреп калдым, – дип сүзен дәвам итте. Ә бераздан инде без бабай белән бик якын кешеләр шикелле сөйләшеп утыра идек. Читтән караганда безне аталы-кызлы дип уйларга да булгандыр.

Ярты көн диярлек вакыт узып китте. Күпме автобусларны каршы алып, озатып калдык без. Тукталыш тагын бер мәлгә тынып калды. Кемнәрдер: «Хәзер ярты сәгатьлек тәнәфес», – дип сөйләнә-сөйләнә узып китте. Ә бабай һаман утыра. Миннән кая баруым, ник шул гомерләр тукталышта утыруым турында да сорамый. Миңа карап дустанә елмайган күзләреннән томан пәрдәсе дә югалгандай була. Таягы өстенә аякларын салып утырды да, улы Гамир, кызы Галия, туып кына калган оныклары турында сөйли башлады. Үзе сөйли, үзе рәхәтләнеп елмая, елмайган йөзе буйлап әледән-әле күз яшьләре агып төшә. Бабай аларны җиң очлары белән генә сөртеп ала.

Рәхәт минутларны бүлеп, тукталышка тагын автобуслар якынлашты. Бабайның хәрәкәтләре күптән инде җитез түгел. Адымнары әкрен. Ә тагын ярты сәгатьтән ул инде ярым бөгелеп үк атлый башлады, тик бер генә автобусны да каршы алмый үткәрмәде. Ә алар, автобуслар шулкадәрле күп... Шулардан төшүчеләр арасында көткән кешеләре генә юк та юк.

Картны тукталыштан берничек тә алып китеп булмасына төшенгәч, әткәемә дип пешергән өрек бөккәне белән баллы тортны чыгарып куйдым.


– Минем каты-коты ашарлык тешләрем юк шул. Гамир, куйдыртырбыз, дигәч, монда ризалашмый гына торган идем, – ди.

«Монда» сүзен ул әлеге оҗмах-урман эченә ымлап, вакытлы гына, бер дә әһәмияте булмаган нәрсәне атагандай гына әйтеп куйды.

«Монда?» Кайда? Йөрәгем жу итеп китте. Әллә... Әллә? Булмас, шундый да мөлаем бабайны... Тик йөрәк дөрес сизенгән икән: Әхәт бабай моннан йөз генә метрлап урман эченә урнашкан Картлар йортыннан иде.

– Оҗмахтагы – тәмугтан, – диде ул, әйтелгән һәрбер сүзен тавышы белән үк кискәләп һәм бая «монда» сүзен әйткәндәгедәй итеп, урман ягына ымлады.

...Икенче көнне мин авылдан кайтканда да, өченче, дүртенче көнне эштән кайтканда да, йөзләгән йортлар салган, улы-кызына әкият сарайлары бүләк иткән балта остасы тукталышта балаларын көтә иде.



Рәсем: Наталья Васильева

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Һәркемнең тормышында якты маяк булырлык кешеләре була. Шундыйларның берсе – беренче укытучым Галия Ибраһим кызы Рамазанова-Галимова. Әлмәт районы Мәмәт авылында туып-үскән, Минзәлә педагогика училищесын тәмамлаган кызны безгә – Чуаштанның Кармыш урта мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Өлкән пионервожатый булып җиң сызганып эшкә тотына яшь кыз. 1968 елны укытучыбыз Минҗан Дәүләтбаев армигә алынгач, Галия апаны Әлмән башлангыч мәктәбенә билгелиләр. «К» хәрефен инде без яңа укытучыбыз Галия Рамазанова белән өйрәндек.

Укытучы апабыз бездә иҗади шәхесләр күреп, сәләтебезне үстерергә тырышты. Мине класста староста итеп сайлап куйдылар. Бергәләп стена газеталары чыгардык, музей почмагы да булдырдык. Кызыл галстукка Ленинга багышланган значоклар туплавыбыз истә. Укытучы апабыз безне тантаналы итеп – октябрятка, аннан пионерга алды.

Бәчек тавына менеп, авылыбыз табигатенә соклandык, төрле үләннәр исемен өйрәндек. Чашлама чишмәсе – кыйбладан ургып чыккан изге суны алганда җиде төрле үлән җыя идек. Укытучы апабыз мандолинада уйнап, безне җырларга өйрәтте. «Нәни Чапай», «Уракчы кыз», «Ямьле безнең Минзәләбез» җырларын гомере буе онытылмаслык итеп сеңдереп калдырдык. Әниләребезгә багышлап җырлы-шигъри кичә оештыруыбыз да истә әле. Ул чакта Кармышта фатирда яшәгән килеш Галия апа бәйрәмгә кабартмалар пешереп һәм барлык әниләргә җитәрлек итеп пилмәннәр дә ясап килгән иде! Әниләргә бүләккә кулъяулык чигәргә дә ул өйрәтте. Бәйрәмдә һәрберебез шигырь сөйләде. Ул вакытта дулкынланып сөйләгән шигырем әле дә күңелдә саклана.

Концертлар оештырып та авыл клубында еш чыгыш ясый идек. Укытучыбыз күңелләргә гомер буена җитәрлек көчле рух, илһам салып калдырды.

Галия апа белән аның ире Әнәс абый үрнәк гаилә булып матур гына гомер кичерәләр. Әллә ничә төр сортлы виноград үстерәләр. Бакчалары гел чәчәккә күмелгән Галимовларның! Күңел матурлыклары бакчаларында чагыла. Кызлары Эльмира һәм Гөлназ Мәскәүдә яшиләр. Алар тормышына, оныкларына куанып гомер итә укытучыларым. Мең рәхмәт аларга!

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Чуаштан.

Сезгә бу хатымны күптән язасым килгән иде инде, тик тормыш без уйлаганча гына бармый шул. Хатирәләрне барлап, гаиләбез турында язма әзерләп йөргәндә олы кайгы килде: әтиебез кинәт кенә якты дөньядан китеп барды... Алданрак язган булсам, әтием дә укып шатланыр иде дигән үкенечле уйлар белән, күз яшьләре аша язам сезгә...

Әтием Гыйффәт армия сафларында Свердловск өлкәсендә, ракета гаскәрләрендә сержант булып хезмәт итә. Кечкенәдән үк укуга хирыс егетнең югары белем алу теләге бик көчле була, армиядән туры Казан авыл хуҗалыгы институтына имтиханнар тапшырып, укырга керәп кайта. Ул елларда авылда югары белем алучылар бармак белән генә санарлык була. Төнлә тимер юл станциясендә күмер бушатып, акча эшләп, көндез укый ул. 1969 елда укуын тәмамлаган яшь белгеч Петровка совхозына агроном итеп билгеләнә. Шул ук елны әниебез Лира Чукмарлы урта мәктәбенә тәрбияче булып урнаша, ялгыз яшәүче Зәйтүнә әбидә фатирда тора. Әтием белән әнием шунда танышып, 1969 елның 5 ноябрендә никахларын теркиләр. Әлбәттә, бик кырыс, «усал» дигән аты чыккан әбиебез янында 19 яшьлек яшь киленгә башта бик җиңел булмый,

Фото: Анна Арахамия



әмма алар уртак телне тиз таба. Фәхрисламовлар гаиләсендә бер-бер артлы өч кыз туа. Әтиебез Гыйффәт Чукмарлыда агроном, бригадир, авыл Советы рәисе вазыйфаларын башкара, һәр елны Сабантуй бәйрәмен оештыра. Профком җитәкчесе эшен башкарганда үзе Кыш бабай булып киенеп, балаларга Яңа ел бүләкләре өләшә, авылыбызда туйлар, юбилейлар алып бара. «Иртәгә көтү чираты диясе көннәрдә дә таңга кадәр туй алып барып, шуннан көтү алып чыгып киткән чаклар булды», – дип искә ала әниебез. Әти бик матур җырлый иде. Әле безне – кызларын да үзе белән ияртеп, сәхнәләрдә гаилә белән чыгыш ясый идек. Әниебез Лира бик матур җырласа да, оялчан булды.

«Авылда Гыйффәт абый кебек кызлары өчен үлә язып торган кеше юк», – диләр әти турында. Без үскәндә капка төбендә һәрвакыт ком өелеп торды, анда без – бала-чага «өйле» уйный идек, ә күрше-тирәдә яшәүче әбиләр чәйнек-кәстрүл чистартырга килер иде. Әти түбән оч балаларын мотоциклына төяп урманга алып бара, басулар буйлап йөртә, табигатьне яратырга, аны сакларга өйрәтә, бик күп үсемлекләрнең исемнәрен русча да, латинча да хәтерли иде. Кайда җиләк-чикләвек күп үскәнен дә яхшы белә. Мотоцикл арбасына кузаклы яшел борчак салып алып кайтып, күрше-тирә әбиләрне дә сыйлый иде.

Һәр елны иртәгә Сабантуй дигән көнне бездә сарык суялар, мунча ягалар, кичкә Әлмәттән гаиләсе белән әтинең Әүхәт абыйсы кайта иде. Ул капка төбенә чыгып гармун уйный, әти җырлый, күрше-тирә, кайткан кунаклар җыелыша, авылга бәйрәм яме өстәлә. Икенче көнне гаиләләре белән әнинең абыйлары, сеңлесе Земфира киләләр, барыбыз да түбән очка – Сабантуй мәйданына төшәбез. Ә якшәмбе Сарман Сабан туена китәбез.

Лаеклы ялга чыккач, әти авылыбызда имам-хатыйб вазыйфасын башкарды. Мәккәгә барып, хаҗ сәфәрен кылды, авылда бердәнбер хаҗи булды. Кызганыч, 2016 елда инсульт булып сәламәтлеге нык какшады.

Әниебез Лира турында, аның сабырлыгы, игелекле, изге җанлы кеше булуы хакында бер китап язарлык. Хезмәт кенәгәсендә бер генә эш урыны – Чукмарлы урта мәктәбе язылган. 37 ел буена биредә башта тәрбияче, аннары хуҗалык эшләре мөдире вазыйфасын башкара ул. Бик чиста-пөхтә, төгәл, барлык эшләрне җиренә җиткереп башкарганы өчен лаеклы ялга чыккач та җибәрмәделәр үзен, тагын ике ел эшләттеләр. Бик матур итеп гөлләр-чәчәкләр үстерергә, без кайтуга тәмле ризыклар пешерергә дә, күрше-тирәдәге ялгыз әбиләрнең хәлләрен белергә дә өлгерә иде ул. Бик күпләрнең киңәшчесе, сер сандыгы булды...

2019 елда әти-әниебезнең өйләнешүенә 50 ел тулды.

Без, Фәхрисламовларның өч кызы да, бүгенге көндә тормышта үз юлыбызны таптык. Мин – олысы Гөлнара Чаллы дәүләт педагогика институтын тәмамлагач, хезмәт юлымны Сарман районы Нарат Асты авылында башлангыч мәктәп директоры һәм укытучысы булып башлап җибәрдем. Аннары – Чаллыда Балалар һәм яшьләр иҗат Сараенда методист, «Күңел» радиосында, Чаллы телерадиокомпаниясендә, «Шәһри Чаллы» газетасында журналист булып эшләдем. Бүгенге көндә Әлмәт районы Кичүчат авылында ирем Тавис белән гомер итәбез. Кичүчат авыл Советы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып эшлим. Уртанчыбыз Гөлназ эшмәкәрлек юлын сайлады. Бүгенге көндә Петровка һәм Чыршылы халкын азык-төлек, көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итәләр, ике кыз үстерәләр. Төпчегебез Айгөл Чукмарлы урта мәктәбен тәмамлап, Әлмәт медицина училищесында укыды. Бүгенге көндә ул – даруханә мөдире.

Бәйрәм, ял көннәрендә бергәләшеп туган нигезебезгә җыелышабыз. Туган нигезебездә яшәү көче, дәрт алабыз, тынычланабыз. Эшләгәндә дә, киңәш-табыш иткәндә дә – без бергә, Аллага шөкер. Әле бик күп еллар барыбыз да исән-сау булып, туган авылыбызга, туган нигезебезгә эзне суытмыйча, шатлык-куанычта гына туган йортыбызда җыелышырга язсын иде. Чөнки безнең гаилә – җылы оябыз, байлыгыбыз, горурлыгыбыз ул!

Кызганыч, гаиләм турында горурланып язган бу язмамны әтиебез генә укый алмый инде. Биредә язылган кадерле сүзләр аның изге рухына дога булып ирешсә иде!

Гөлнара ФӘХРИСЛАМОВА-ГУДАЕВА.
Сарман районы.
Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

75 ҖИҢҮ! 1945–2020

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

САБЫРЛЫК – ҖӘННӘТ КАПКАСЫ



Язмыш кемне ничек кенә сынамый. Кемнәрдер сынала, ә кемнәрнедер бу сынаулар, киресенчә, тагын да көчлерәк итә, рухларын ныгыта сыман. Яшел Үзән районы Түбән Урысбага авылында гомер итүче Заһир кызы Зөлхияне дә язмыш төрлечә сынаган. Әмма рухын сындыра алмаган. Ул өенә аяк баскан һәр кешене елмаеп каршы ала, берәүне дә чәй эчерми чыгармый. Маңгаена буразнабуразна булып сызылган тирән җыерчыклар гына тормышында булган авыр вакыйгаларның шаһиты. Тормышы турында артык сөйләргә яратмый. «Күп кенә хатирәләр онытыла да икән шул. 94 яшемне тутырдым бит инде. Аллаһның биргәненә шөкер. Сабырлыктан Ходай ташламасын. Сабырлык – җәннәт капкасы», – ди ул күрешкән саен. Ә искә төшерерлек, сөйләрлек истәлекләр исә шактый. Әтисез үткән балачак, сугыш елларына туры килгән яшьлек... Тормышы турында гади генә итеп: «Гомер буе тир түгеп, хезмәттә үтте», – ди. Авылыбызның ихтирамлы кешесе булган Зөлхия Хәкимова – иремнең әбисе, безнең Ак әбиебез ул.

Ул елларда барысын да өмет яшәтә. Шул өмет ачлыкны оныттыра, салкында җылыта, көнне төнгә ялгап эшләрлек көч бирә.

«Туйганчы сөя алмадым»

Түбән Урысбага авылында Заһир белән Хәеркамал гаиләсендә бер кыз бала дөньяга аваз сала. 1926 елның 26 марты була бу. Аңа Зөлхия дип исем кушалар. Авылның исеме Урысбага булса да, монда гомер-гомергә татарлар яшәгән. Элеккеге исеме Рәсбуга булган аның. Бөек мәгърифәтче, якташыбыз Каюм Насыйри язмалары буенча, бу авылга Рәсбуга яки Росбай дигән кеше килеп утырган. Риваятьләрдә аны бер балалы хатын-кыз булган дип тә сөйлиләр. Кемдер аны чуаш милләтеннән дип тә әйтә.

Кечкенә Зөлхиягә әти-әнисенең мәхәббәтен тоеп, назга күмелеп үсәсе иде дә бит. Юк шул... Салкын бер кышта Зөя күперен төзегәндә әтисе Заһир үпкәсенә салкын тидерә. Күпмедер вакыт урын өстендә авырып ятканнан соң, күзләрен мәңгегә йома япь-яшь ир. Зөлхиягә ул чакта нибары яшь тә җиде ай гына була әле. Әтисен хәтерләп калырга да өлгермәгән кыз газизенең аңа дип әйтеп калдырган сүзләрен генә йөрәк түрендә саклый. Әнисе әйтүе буенча, авырып ятканда, чирем кызыма йокмасын дип куркып, Зөлхияне рәхәтләнеп коча да алмый ул. «Туйганчы сөймәдем, туйганчы үпмәдем», – дип, авыр сулап куя торган була. Иренең вафатыннан соң, Хәеркамал кызы белән туган йортына кайта. Анда да җиңел булмый, билгеле. Әтисе белән әнисеннән кала, абыйсының гаиләсе дә шунда яши. Ничек кенә кысан булса да, кызы белән кайтып сыенган Хәеркамалны да читкә какмыйлар. «Әни сөйләвенә караганда, тату торганнар. Җизнәләре Әшраф авылның тегермәнчесе була. Ул безне ач итмәгән, мөмкин булган саен онын биреп торган. Туганнар ярдәмен тоеп яшәдек», – ди әбием.

Афәтле еллар авазы

Күңел капкаларын сак кына ачып, әбиемнән сугыш чоры хатирәләрен сөйләтәм. Җан тетрәткеч ул авырлыкларны искә төшерүе аңа җиңелләрдән түгел. Сугыш башланган елны җиденче сыйныфны тәмамлый ул.

«Безнең гаиләдә сугышка алырлык ирләр юк иде... Әмма яшәп тә өлгермәгән ир-атлар дөньяның тәмен дә тоймаган егетләр авылдан бер-бер артлы китә барды. Тормыш йөген тарту карт-корыга, хатын-кызга, бала-чагага калды. Безнең балачак сугыш башланган иртәдә өзелде. Хезмәт тәрбияләде, кеше итте», – дип искә ала әби балачак елларын.

Югары һәм Түбән Урысбагадан Бөек Ватан сугышына 300 гә якын ир-ат китә. Шуларның 118 е ватан өчен җаннарын фида кылып, яу кырларында ятып кала.

Сугыш елларында авылдагылар кичергән авырлыклар, алар өлешенә төшкән михнәт-газаплар, адәм баласы түзә алмаслык шартларда эшләү-яшәүләр турында инде никадәр язылды, сөйләнде... Әйе, Җиңү өчен көрәш фронтта гына түгел, тылда да бара. 12–13 яшьлек ач-ялангач балаларның ат җигеп сука сукалавы, сәке тулы ач баласының салкын өйдә туңып утыруларын уйламаска тырышып, аналарның төннәр буе ындырда ашлык сугулары, чабата белән тездән язгы пычрак ерып симәнә орлыгы ташулары, терлек абзарларында куна-төнә эшләүләре, яшүсмер кызларның урманнарда кул пычкысы белән агач кисүләре, зәмһәрир суыкларда кәйлә белән окоп казулары – барысы да Җиңү хакына. Ул авыр эшләрдә әбием дә катнаша. «Бервакыт Кайбыч урманында окоп казырга һәр йорттан кеше җыя башладылар. Әнкәй белән безне дә чакырдылар. Аякта чабата, өскә кигән киеме дә шулкадәр генә инде. Ашарына ризыгы да җитәрлек булмагандыр. Бу кызыгыз бик яшь күренә, дип, мине окоп казырга алмадылар.



Зөлхия әнисе Хәеркамал белән *(уңда)*. 1946 ел.

Кире авылга кайтарып җибәрделәр. Әни шунда окоп казырга калды. Тик миңа да авылга кадәр кайтып җитәргә насыйп булмады – Албаба тимер юл станциясенә арбалар белән ком ташырга җибәрделәр. Яшь кызлар өчен бик авыр эш иде ул. Ком төягән арбаны көне буе этеп йөреп, беләкләр сызлый, кул-аякларның егәре калмый. Ун кешене бер фатирга керттеләр. Юыну, киемнәрне киптерү үзе бер җәфа. Аннары Лаешка урман кисәргә җибәрделәр. Анда да күп көч түктек», – дип сөйли ул.

Авыр эштән тәмам йончып авылга кайтса – яңа хәбәр: колхоз председателе аны күрше Норлат авылына тракторга укырга җибәрмәкче. Авылда да хәрби закон – әйтелгән икән, үтисең! Булдыра аласыңмы дип сорап торыш юк! Нурания исемле бер кыз белән Норлатта алты ай укыйлар. Укулар бетүгә үк, бернинди тәҗрибәсе булмаган кыз тракторга утырып басуга эшкә чыга... Биш елга якын Зөлхия әбием тракторда эшли. Күрше Бәчек, Кече һәм Олы Ачасыр кырлары да аны көтеп ята. «Яздан тотына идек, – ди. – Кара көзгә кадәр кырдан кайт-

Тракторга утырганда аңа нибары 15 яшь була. Япь-яшь кыз балага җиңел бирелмәгәндер бу эш.

мыйбыз: ашлык та ташыдык, сукаладык та, чәчтек тә. Кыш көне исә трактор ремонтлыйбыз. Бер елны күрше Олы Ачасырга ремонтка йөрдек. Авылның бер мәчетен гараж иттеләр. Шунда тракторны язгы эшләргә әзерләдек. Ә җәен кызу эш вакытында өйгә бөтенләй кайтып кергән булмады. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләдек. Бүгенге тракторлар түгел бит ул без эшләгән техника. Аларның хәтта фаралары да юк. Ягулык салучылар фонарь кабызып яктыртып торыр иде. Сменалап эшләдек. Тракторны сүндереп торырга ярамый. Яшь булгач, жәлләп, мине төнге сменага сирәк куялар иде».

Ул вакытта күрше авылларда да тракторчы кызлар күп булган. Тракторда эшләү хатын-кыз шөгыле түгел дә бит... Нишлисең, ир-егетләр бар да сугышта. Ә илгә ашлык кирәк.

Бу якларда бер иңкүлекне халык «Зәкия чокыры» дип атый. Олы Ачасыр кызы була Зәкия. Төнге якта тракторы белән Норлаттан кайтканда ялгыш чокырга каплана. Бәхеткә, исән кала.

Әбиемнән тракторда эшләгәндә күпмерәк хезмәт хакы алуларын сорашам. Әбием өлешенә эшнең бик тә авыры, җаваплысы эләккән. Кыз кешегә салкын яңгырлар, үтәли искән карлы җилләр астында ачык кабиналы тимер тракторда эшләве бер дә җиңел булмагандыр. «Юк инде, нинди хезмәт хакы... Бөтен колхозчылар кебек үк таякка эшләдек. Бер тапкыр арыш оны бирделәр анысы... Ул вакытта без җаныбыз-тәнебез белән ил, Ватан язмышы өчен ут йоттык, хезмәт хакы турында уйлаган да булмады. Нәрсә ашап, нәрсә киеп яшәгәнбездер инде, үзем дә гаҗәпкә калам», – ди әбием.

Аның иң яратып сөйли торган истәлеге – Җиңү көне.

Җиңү көнен ул Шырдан авылы кырында каршылый. «Шырдан егетләре, безнекеләр җиңде, дип килеп әйткәч, ышанмадым... Күңел ышанмады...» – әбиемнең бите буйлап ирексездән күз яшьләре тәгәри. Менә ул Җиңү! Тыннары белән тартып китерердәй булып көткән татлы да, ачы да, куанычлы да, сагышлы да Җиңү!

Авылга әкренләп исән солдатлар кайта башлый. Кемдер – таякка таянып, кемдер – буш җиңен селкеп, кемдер – аксаклап... Трактор руле артындагы кызларны инде ир-егетләр алыштыра. Сугыштан соң да яшәү җайлы гына бармаса да, ул инде башка – тыныч тормыш була. Монда инде куанычшатлыкка да урын бар. Тракторчы кыз Зөлхия дә үз авылы егете Фәйзрахман белән гаилә кора. Төп йортка килен булып төшә ул. Бер-бер артлы өч малай, өч кызлары туа – Фирдүс, Фоат, Илфат, Фәрдия, Әлфия, Равилә. Кайнанасы турында да бик җылы итеп искә ала әбием: «Әниебез Сәхипкамал белән 18 ел тату тордык. Бик яхшы кеше иде. Балаларны үстергәндә аның ярдәме әйтеп бетергесез булды. Элек бит хәзерге кебек бала тапкач өйдә утыру юк. Бер-ике айдан колхоз эшенә чыгасың. Фирдүс улымны 25 августта таптым, сентябрьдә инде колхоз басуына бәрәңге чүпләргә чыктым. Ул вакытта колхоз бәрәңге дә, чөгендер дә, суган да үстерә иде. Печәнен дә үзебез чабып, үзебез ташыдык. Йортта терлек асрап, күрше Козловкага җәяүләп сөт сатарга да бара идек әле».

Әнә шулай тормыш әкрен генә үз җаена барган мәлдә, 1982 елда гаилә башлыгы Фәйзрахман бабай вафат була. Кайгы җиле бер какса, гел кага икән шул. Иреннән соң улын югалта ул. Аннары икенчесен, өченчесен...

Каршымда өч улын җир куенына салган 94 яшьлек чал чәчле Ана утыра. Кичерешләрен, тойгыларын аңлатырлык сүзләр юк миндә. Бер нәрсәгә сокланам: булса да булыр икән кешедә түземлелек, сабырлык! Җан тынычлыгын догалардан таба ул. Күзлеген киеп ала да, һәр кич балалары, оныклары өчен дога кыла, изге теләк тели. Ә дәвамчылары күп аның. 13 оныгы, 20 турунының ак яулыклы, ягымлы йөзле, миһербанлы йөрәкле әбисе ул. Безнең маягыбыз, сабырлык мисалы. Аның үрнәгендә балалары үз балаларын үстергән булса, хәзер без – оныклары аның үрнәгендә үзебезнекеләрне тәрбиялибез. Ул авылыбызның олы хөрмәткә ия мөхтәрәм кешесе. Йорты яныннан берәү дә болай гына узып китми. Үткәнбарган хәлен белергә керә, кемдер әти-әнисе өчен сәдака кертә. Менә шулай, Аллаһның һәр биргән көненә рәхмәтле булып, килгән сынауларда сабырлык саклап гомер итә. Телендә һаман да бер сүз: «Сабырлык – җәннәт капкасы», – ди ул.

Руфия МӨХЕТДИНОВА



БАШЫҢНЫ САКЛА, БАЛАМ...



Марат КӘБИРОВ,
язучы

МИН ШУЛАЙ УЙЛЫЙМ

Яшьлек ялгышлары, мәхәббәт турында уйлауга, бер мәзәк искә төште.

Бер егет әтисе янына биш кыз ияртеп кайткан.

– Бишесе дә ничава гына, әти, бишесен дә яратам. Мәнә син дөнья күргән кеше буларак әйт әле, кайсысына өйләним икән?

Әтисе кул гына селтәгән:

– Улым, үзеңә кара. Тик бел, кайсысына өйләнсәң дә – үкенәчәксең.

Гомер үренә менеп җиткәч, һәрбер кеше артына борылып карый һәм: «Их, шул чакта нигә болай итмәдем икән?!» – дигәнрәк уйлар кичерә торгандыр. Кайчагында бу мәхәббәткә дә кагыла. Беркадәр олыгая төшкәч, безгә акыл кергән сыман тоела. Һәм шул акылны яшьрәкләргә дә өйрәтү таләбе барлыкка килә. Ике малай атасы буларак, ул тойгы миндә дә бар. Улларыма әйтер сүзләр бар. Без яшьлектә кылган хаталарны балалар кабатламасын дигән уйдан яралган шул нәрсәләрнең бер өлешен сезгә тәкъдим итәм. Кайсылары кичә әйтелгән, кайсылары бүген... Бала-чага аны тыңламый, әлбәттә. Шулай да... Кайсыларын иртәгә ишетерләр, кайсыларын соңрак...

1. Яшьлек – ялгышу, күп итеп хаталар ясау өчен бирелә. Калган гомер – шул хаталарны төзәтү өчен. Бу – табигатьнең камиллеге. Адәм баласының гамьсезлеген бүтәнчә җиңү, бүтән юл белән аны ниндидер изгелек эшләргә мәҗбүр итү мөмкин түгел.

Яшьлекнең беркайчан да узмый торган, кешене гомере буе озатып бара торган күзгә күренмәс бер өлеше бар. Ул өлеш «мәхәббәт» дип атала. Мәхәббәте исән чагында кеше беркайчан да хаталанудан туктамый. Син дә хаталанырсың. Кеше ялгышларын кабатлама, башкаларны сөендерерлек үз ялгышларың булсын. Хаталарыңнан оялма, алар өчен бүтән берәү дә түгел, ә син түләячәксең. Хаталанудан курыкма: Американы да Һиндстанны эзләгәндә тапканнар...

2. Беренче мәхәббәт дип беркайчан да өзгәләнмә. Ул бергә яшәү өчен түгел, ә тәҗрибә туплау, саф һәм сантый чакларыңны сагыну өчен бирелә. Чынында, мәхәббәт беренче дә, икенче дә булмый, ул бер генә була. Һәм ул – синең күңелең. Күңелең саф, тирән икән – мәхәббәтең дә шулай булыр. Кемне яратсаң да.

Кичә сөйгән ярың ул мәхәббәт түгел, ә истәлек. Иртәгә сөячәк ярың – өмет. Бүген сөйгән кешең – мәхәббәт. Бүгенгеңнең кадерен белеп яшә. Иртәгә иртән дә бүген баеган кояш чыгачак.

3. Бүген сөйгән кешеңне син иртәгә дә яратырга бурычлы түгелсең. Ул да. Аны синең теләсә кайсы вакытта ташлап китәргә, башкага алыштырырга хакың бар. Аның да. Әгәр аның һәрвакыт яныңда булуын, иртәгә дә яратуын телисең икән – мәхәббәт белән шөгыльлән.

4. Руста «мәхәббәт белән шөгыльләнү» дигән төшенчә җенси бәйләнешне аңлата. Мин бу сүзне татарча, аз гына башка мәгънәдә кулланам.

Мәхәббәт – халәт түгел, ул – хәрәкәт, һәрвакыт үзгәрештә. Һәм ул, көйсез бала сыман, һәрвакыт үзе белән шөгыльләнүне таләп итә. Сөйгән кешеңә игътибарлы бул, аны аңларга, хаталарын һәм гөнаһларын кичереп, яхшы сыйфатларын күрергә өйрән. Хатын-кыз ул көйсез сабый сыман.

Бүгенге кәләшең инде кичәге кәләш түгел: ул беркадәр үзгәргән, дөньяга да, үз-үзенә дә, сиңа да башкачарак карый. Һәм син аның йөрәген бүген дә яулап алырга бурычлысың. Көннән – көнгә, мизгелдән мизгелгә яңарып тормый икән, мәхәббәт үлә. Шуңа күрә мәхәббәт белән шөгыльлән, аны яңартып тор. Мәхәббәт ялкаулар һәм битарафлар өлеше түгел.

5. Башыңны сакла. Шатлык-уңыштан да, кайгыдан да, мәхәббәттән дә башыңны югалтма. Сукыр мәхәббәткә ияреп йөрсәң, үзең дә сукыраерсың. Аны үз артыңнан иярт – күзе ачылыр.

Кыз белән танышкач, аның гаиләсенә игътибар ит. Әгәр ул гаиләдә әтиләренә хөрмәт зур икән, бергә гаилә корсагыз, сиңа да шундыйрак караш булыр. Әгәр әтиләренең кадере юк икән, сине дә санламаска тырышырлар. Үзеңне санлаган, кадереңне белерлек кешене сайла. Сине санламаска тырышучылар болай да күп. Һәм ниндидер уңышка ирешкән саен, алар арта барачак. Андыйларны күңелеңә алма, алган булсаң – төшереп калдыр. Теләсә кемне төяп йөрергә синең күңел маршрут автобусы түгел...

...Моңа акыл кергән икән, бүтән бер дә хаталанмас, бер гөнаһ та кылмас дип уйлама. Болар – тормыш тәҗрибәсе. Тәҗрибә әле ул акыл дигән сүз түгел... Ә асылда, кешегә беркайчан да акыл керми. Бары тик яңадан-яңа ялгышлар ясарга рәте генә бетә.

МӘХӘББӘТТӘ ЯЛГЫЗЛАР

Их! Торам-торам да, тагын шул сүзне кабатлыйм: «Их! Язмыш аларга карата нигә дип бу кадәр усал, мәрхәмәтсез булган соң?! Нигә ул аларның юлларын кушмас өчен барысын да эшләгән?» Күкләрдә никах укылмаган булганмы? Шулайдыр... Язучы Рафаэль Сибат белән Розалия Казыйханованың бөтен бер гомергә сузылган мәхәббәт тарихы турында минем сүзем.







Гөлнур САФИУЛЛИНА

Мәхәббәттә кайчак ялгызлар без,
Мәхәббәттә кайчак юлсызлар.
(Рафаэль Сибат)

– 1967 ел. Унынчы классны тәмамладым да, районыбызның Зөбәер дигән авылында пионервожатый булып эшли башладым. Ялларга өйгә кайтып йөрим. Шимбә көн иде. Башта кино карадык, аннары, гадәттәгечә, танцылар башланды. Ул мине килеп биергә чакырды. Озын ак плащтан, чалбардан, чәчләре дә озын... Әнинең туфлиен кигән идем – зуррак булды, биергә чыга алмадым... Шул кичне ул мине озата кайтты. Авылга бәрәңге алырга килгән студентларның берсе икәнен аңлаган идем инде. Минем арттан ул көнне аның группадашы Нур Әхмәдиев тә килгән иде, күрше малае Фәрит тә, тагын бездә практика узган агроном егет тә... Рафаэль аларның барысын да берәм-берәм озатты – безнең капка төбенә җиткәндә икәү генә калдык... Икенче атнада тагын кайттым. Клубта киноны да карап бетермичә урамга чыктым. Ә ул миннән дә алда чыгып көтеп торган! Озак сөйләштек. Миннән ике яшькә олырак икән. IV курска күчкәннәр. «Киләсе атнада без инде Казанга китәбез. Озатырга кайтырсыңмы?» – дип сорады. Мин: «Әйе!» – дидем...

...Кайтырга чыга икенче атнаны Розалия. Кайтып кына җитә алмый. Язмыш аларга ул чакта беренче тапкыр аяк чала... Зөбәер белән аның туган авылы Байсар арасы – 25 чакрым. Юл читенә чыгып баскан кызны ашлама төягән бер машина утырта. Әмма шофер башта Олы Имән авылына таба борыла: бабасы шунда яши икән. Чәйләп кенә түгел, мәйләп тә алгач, ул инде олы юлга чыгарга базмый – ураулдан китә. Яңгыр сибәли башлый. Белмәгән юл куркыныч шул инде – машина чокырга төшеп китә. Розалия кырыйга сикереп кала... Олы Имән авылына кадәр кире абаланып бара ул. Иртәнгә аягы зәңгәрләнеп шешеп чыга. Сынган икән...

Кыз гипс белән өйдә ятканда Казаннан хат килеп төшә. Рафаэльдән! Шигырь юллары белән мәхәббәт аңлаткан! (Авылның бөтен буй җиткән кызы өчен зур вакыйга була ул. Кемгә шигырь юллары багышлаганнары бар әле монда?!) «Бер күрүдән кешене яратып буламыни?!» – дип җавап бирә Розалия. Җавап тагын мәхәббәт шигыре булып әйләнеп кайта... Ике арада хатлар йөри башлый. «Казанга киләсең булса, миңа белгертми калма», – дип яза егет. Шуңа да, икенче елны башкалага бухгалтерлыкка укырга җибәргәч, «Каршы ал!» – дип аңа телеграмма суга Розалия. Актаныштан ул чакта Казанга әле пароход йөри: кыз да су юлы белән килә. Әмма елга портында берәү дә каршы алмый... Язмыш бу урында икенче кат шаярта: Розалия суккан телеграмма ул чакта Рафаэльне ошатып йөргән икенче берәү кулына барып эләгә. Аның булачак хатынына. Тик бу хакта алар әле бик соң беләчәк...

– Казанда укый башладым. Туганнан туган абыйларда торам. Бу вакыт минем арттан инде кода тиешле кешебез йөри. Бер адым калмыйча... Ветеринария институтында укый иде. Лекциядән чыга да, туптуры безгә килә: кайтканымны көтеп утыра. Беркөнне чемоданымнан Рафаэльнең хатларын алып укыган. Аннан, меңгә теткәләп, кире урынына салып куйган. «Хәзер инде алар сиңа кирәкми!» – ди... Өйләнешергә гариза биреп кайттык. Ә минем тагын бер кат Рафаэльне күрәсем килә! Аңа әйтмичә кияүгә чыгу дөрес булмас шикелле... Туганнан туган абыем Илдар да филология факультетында укый иде. Хат яздым да, 502 нче группага кереп, Рафаэльгә тапшыруын сорадым. Беркөнне безне дәресләрдән соң алып калып имтихан сорауларын яздыра башладылар. Шул вакыт кемдер кабинет ишеген шакыды. Ишетеп торам: Рафаэль тавышы! Мине сорый! Тик укытучы: «Андый кеше монда укымый!» – диде... Язып бетерүгә тукталышка йөгердем. Бәлки, өлгерермен?! Ул трамвайга алгы ишектән, мин арткысыннан кердек. Кешеләрне аралап: «Исәнмесез!» – дип янына барып бастым...

Розалиянең яңалыгын ул сүзсез генә тыңлый һәм... берни әйтми кире борылып китә! Язмыш шаярта – горурлыкны атлап узарга ирек бирми... Рафаэльнең ул көнне тулай торакка кайткач үксеп елаганы турындагы хәбәр еллар үткәч кенә килеп ирешә. «Тезләнәсе калган алларыңда, / Вокзалларга каршы төшәсе...» дип язачак ул. «Нигә мин ул көнне сине туктатмадым икән?!» Бу сүзләрне ул аннары бик еш кабатлаячак. Әмма соңарып шул, соңарып...

Нәкъ җырдагыча була – сукмаклар чуала, адреслар югала...

Студент елларында ук «Казан утлары» журналында рәсеме белән шигырьләре басылган Рафаэль Сибат әдәби дөньядан да югала. Исеме күренми, ишетелми, яңгырамый.

1977 елда Розалия ире белән аерылыша. Ике баласын җитәкли дә өйдән чыгып китә. Эчкән килеш тә, аек килеш тә кул белән уйнавына түзә алмый... Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Кызыл дипломын алганда укытучылары: «Өеңә дә кайтып тормыйча, документларыңны Казанга, институтка тапшыр», – дип калалар. Остазлары сүзен аяк астына салмый... Менделеев районына селекционер итеп эшкә җибәрәләр. Ә II курстан соң институтның читтән торып уку бүлегенә методист итеп чакыралар. Тулай торактан 7 квадрат метрлы гына бүлмә бирәләр. Тормыш алып барасы, ике баланы да укытасы бар бит – урам җыештыручы булып та урнаша. Ә бер көнне студентларның контроль эшләрен җыйганда кире адреска күзе төшә: Киров өлкәсе, Югары Шөн авылы. Рафаэльнең күрше авылы гына түгелме соң?

– Мин моны күңелемә салып куйдым... Җәй көне ул егет сессиягә килгәч, җай табып сорадым. «Түбән Шөн сездән еракмы? Рафаэль Хуҗин дигән кешене белмисезме?» – дим. Әдәби псевдонимы Сибат икәненә кадәр белә икән! Сораулар яудыр-

Хәтерлимсең: сөю бөреләнде –
Чәчкәсенә аның кар аттык.
(Рафаэль Сибат)

дым: кайда эшли, хәле ничек, гаиләсе... «Ә кем сорый диярргә?» – диде ул мине бүлеп. «Актаныштан... Студент чактагы танышы диярсез, аңлар», – дим. Минем эш сәгате беткәндә бүлмәмә Рафаэль килеп керде... Казанда чагы булган икән...

Алар төне буе сөйләшеп чыгалар. Икесе дә инде ялгыз... Розалиянең тулай торактан кечкенә генә булса да үз фатирына күчеп йөргән чагы – әле адресы да юк. «Сиңа үзем хат язармын», – дип озата ул Рафаэльне. Тик ир генә Розалиянең конверт тышындагы Зур Урам дигән сүзен «Большая улица» дип «дөресләп яза»: хат каядыр Киров районына китеп югала. (Язмыш көлүе!) Горурлык икесендә дә җитәрлек: хатына җавап алмагач, Розалия аңа кабат язмый. Тагын югалтышалар...

– Ун еллап вакыт узды. Күңелдән һич чыкмый... Кызыма: «Әйдә, авылына барып кайтабыз», – дим. Киттек электричкага утырып. Өйдә әнисе генә иде. Бер ишегалдында ике өй – Рафаэль үзенә йорт салып чыккан. Кич кайткач, аптырап калды инде. «Нишләп йөрисең?» – ди. «Юкка чыктың бит», – дим... Хатыны белән озак тормаганнар алар. Аерылышкач, баланы Әлфиягә бирмәгән, үзенә алып калган. Сәбәпләре бар инде аның... Алмаз мәктәпкә дә кермәгән була әле – улын ул ялгызы үстергән. Үзе генә калгач, салгалый башлаган... Туксанынчы еллар иде бу. Малмыжда татарча газета чыга – Рафаэль шунда эшли икән. Кичен – авыллары клубында. Аннан үзе безгә килде... Эчеп килгән иде. Мин аны куып чыгардым... (Тагын язмыш «тырыштымы»?!)

Рафаэльнең апасы Мөнҗияләр авылына кызы кияүгә чыккач кына кабат аралаша башлый алар. Рафаэль аның фатирына килеп йөри. «Миңа монда язарга рәхәт», – ди. 2000 елда аның беренче китабы басылып чыга – «Ялгызак». Түбән Шөндә узган китап презентациясенә Розалия дә кайта.

– Кечкенә генә мәкаләсе басылып чыкса да, ул аны миңа күрсәтми, бирми калмый иде. Көндәлек алып бара иде ул. Аларга кайтуга иң беренче шул көндәлекне укырга утыра идем. Минем турыда да юллар байтак җыела... Бик еш булмаса да, кайтып йөрдем. Өйләрен җыям, урынҗирләрен алыштырам, тәрәзә пәрдәләрен... Алмаз бик сөенә иде кайтуыма. Армиягә киткәнче ул Кировта төзелеш техникумында укыган булган, кайткач, укуын ташлаган. Мин аны Казанда укырга урнаштырдым. Сессияләргә килгәндә бездә торды. «Өйләнешегез инде», – дия иде ул безгә... Бервакыт төш күрәм. Икәү Мөнҗия апаларына барганбыз икән. Рафаэль кире кайтырга машина таба алмый. Аннан: «Син утырып тор», – диде дә, каядыр юкка чыкты. Чыгам да карыйм – юк бу. Ул арада эшемдәгеләр килеп чыкты да: «Әйдә, утыр, китәбез. Аны көтсәң, ничек кайтасың», – диләр. Утырдым. Шулай уянып киттем. Димәк, бергә булмыйбыз икән, дидем...

Туганнарыма якынрак булыйм дип, Розалия Түбән Камага яшәргә күчкәч, очрашулар тагын сирәгәя. Соңгы кайтуында Рафаэль, гадәттәгечә, аны Түбән Шөндә озатып кала, ә Розалия Алмазларда кунарга туктала. Берничә сәгать узуга, Рафаэль аңа: «Кире кайт! Такси ал да, кире кайт!» – дип шалтырата. Иртәгә эшкә бит, дип, Розалия баш тарта. Кабат очрашмаячакларын кем белгән?!

– Авылга кайтып, кечкенә генә өй салдым. Аңа әйтмәдем. Әзер булгач: «Әйдә, яшьлегең үткән җирләрне карап кит», – дип чакырырга теләгән идем... 15 август көнне үлгән ул. Тагын биш көннән минем туган көн... Йөрәк... Нибары 57 яшь иде. Әнисеннән соң ике ел гына яшәде. Мине тапмаганнар. Энем: «Анда сине эзлиләр», – дип хәбәр итүгә килененә шалтыраттым. «Кайчан җирлисез? Мин төнлә юлга чыгам», – дим. «Бүген җидесен үткәрдек инде», – диде... Кырыгына бардым. Кабере янында берүзем озак кына утырдым. Еладым да еладым... Таныла, язганнары басыла, китаплары чыга башлагач кына шулай китеп баруы бик үкенеч. Исеме онытылмасын дип, гел шигырьләрен сөйләп йөрдем. Сәхнәдән төшкәнгә әле ике генә ел. Үләр алдыннан көндәлегенә язып куйган ике куплет шигыре дә минем хакта...

Менә шундый тарих. Калганын, язмага кермәгәнен Рафаэльнең аңа язган хатлары, көндәлекләре сөйләр. Дөресрәге – алардан өзекләр.

«Исәнме Розалия! Соңгы тапкыр очрашканга 10 еллап вакыт узса да, күңел сине барыбер онытмады, кем әйтмешли: «Ул безнең көчтәмени?!»

Үзем турында шул: улым көз армиядән кайтты, хәзер авылда өчәү (әни, мин һәм улым Алмаз) яшибез. Мин Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә (бездән 80 км) чыга торган «Дуслык» газетасында безнең Вятские Поляны буенча корреспондент һәм бүлек мөдире булып эшлим. Язгалаган кешегә яраклы һәм бата торган хезмәт. Атнага бер көн – җомга – барып кайтам редакциягә, калган көннәр өйдә һәм район буйлап йөрүдә. Иң мөһиме, эш ошый, алга таба да шул уй-хис белән яшәргә язсын. 13 январь, 90 ел.»

«Сәлам Түбән Шөннән! Казанга 14 февральләрдә килергә исәп, 15-16-17 февральләрдә Татар иҗтимагый үзәгенең II корылтае булачак, ә мин бу Үзәкнең әгъзасы саналам. Сине күрәсем килә, Розалия! Студент елларындагы минем иң көчле хис – синә иде... 06.02.90.»

«Сәлам Түбән Шөннән! Мин кайтып җиттем. Әни түшәктә, ул да грипп эләктергән, йөткерә-йөткерә ята. Кайтуга ук сине сагындым инде, карт тиле!

Хәзер генә аңладым, без тагы аерылсак та, мин сине барыбер яратачакмын. Әмма аерылмаска иде, гомер картлыкка бара. 4.01.91.»

«Р.гә

Усал язмыш кара пәрдә – чәчен
Тарап салды безнең арага.
Син бераүгә көлеп кулың бирдең –
Алып булмас инде аралап...

Синең кебек якын кеше эзләп,
Кемгә микән килеп дәшәсе?
Бер-беребезне инде күрмибез дә...
Нишләсе соң хәзер, нишләсе?!

Сине күреп сөйгән күзләрем дә
Дучар әнә шундый язмышка –
Бер-берләрен мәңге күралмыйлар,
Күралмыйлар хәтта ялгыш та...

Тезләнәсе калган алларыңда,
Вокзалларга каршы төшәсе...
Нихәл итим! Җирдә тормыш итү –
Күзем күреп сукыр яшәсе...

...Синнән башка җәе җайсыз узды,
Бигрәк моңсу үтә көзләре...
Читләр сине:
«Бәхетсез ул, кара!» – димәсеннәр –
Күрми башлар шундук күзләрем.
28.10.68.–18.02.91.»

«Сәлам Түбән Шөннән! Ни сәбәптер, Казаннан китәсе килми башлады. Электричкага утыргач та сине уйлап бардым. «Гомерем буе сагынып яшәдем мин сине!» Кинәт туган шушы уйдан соң, күңелгә шигырь юллары килде:
Мин сине сагынып яшәдем
Яшьлегем таңнары чорыннан.
Сагынып исемә төшердем
Моңланып җырлаган җырымда.

Күп еллар акса да вакыт-су,
Мин сине сагынып яшәдем.
Син булгач бу якты дөньяда,
Пар булыр ярларга дәшмәдем.

Мин сине сагынып яшәдем...
Ләззәт ул, хәсрәт ул – сагыну.
Иң зур хис, иң көчле тойгыдыр –
Сөюдә берәүгә табыну.

Менә шулай, матурым! Мин – берсөяр (однолюб) бит! Тагы... Синең белән очрашудан мин бик риза! Рәхмәт!!! 20.02.91.»

«Сәлам Түбән Шөннән! Картаела, кызый, хискә бирелүчән булып киттем әле: сине озатуга ук юксына башладым. Күңелгә моң тулды, җанга сагыш өелде.

Эшкә төшкәч, кызлар сораштырдылар. «Кайда эшли ул, интеллигент күренә. Мөлаем – симпатичный үзе. Кызы да матур!» Мин: «Институтта!» – дип җавап бирдем. Син бездә яхшы тәэсир калдырдың. Рәхмәт! Молодец! 11 март, 91 ел.»

«16.03.91. Сәлам Түбән Шөннән! Хатың буенча берничә сүз: 1. яхшы гына кайтып җитүеңә һәм күңелең кителеп китмәгәнгә сөендем 2. мин һаман да «баш төзәтеп» йөрмим – 12 марттан «ураза». 3. «Картаясы бар бит әле» турында шуны әйтергә мәҗбүрмен: соңгы биш елда мин үземне картаймам дип йөрим. Ник дисеңме? Картайганчы үлеп китәрмен дигәнгә.»

«Алмаз: «Розалия апа белән Айгөл булмагач, әллә ничек, өй күңелсез кала. Өйгә керәсе дә килми», – ди. Ул бу сүзләрне 8 Март бәйрәменнән соң да әйткән иде инде. Шулай инде, хатын-кызлы өй – ямьле өй инде ул! Сиңа гына Май бәйрәме тәтемәде, биш көн буена эш аты булдың. Гаепләмә инде, матурым. 04.05.91.»

«Исәнме, Розалия! Яңарак кына бездә булып китүеңә карамастан, хат язарга булдым әле. Аерылышуга син мине үзеңә тартасың. Сагындырыпмы, моңландырыпмы... Тукай: «өйләнү – түгел сөйләнү», дигән һәм хак әйткән. Минеке сөйләнүдән ары узмый әле. Ә мине авылда сиңа өйләнүем белән котлаучылар да бар. Аз гына көтик. Иң мөһиме – безнең үзара мөнәсәбәтләр, алар җылы икән, киләчәк өметле! Минем уемча, безнең арага беркем дә, хәтта балалар да керергә тиеш түгел! 3 июнь, 1991 ел.»

«Шөн Сабан туенда сүзгә килдек. Әйдә ачуланышмыйк әле, матурым! Туйдым инде мин дөньядагы талашлардан. Әлфия белән торганда да соңгы еллар гаугалы булды, аннан соң да тормыш тыныч булмады һәм хәзер дә... Мин бит сине тыныч, җайлы, ипле, әкрен, иркә, иркәләүчән, шул ук вакытта практик, тере, энергияле, эшчән һәм тагын сөйкемле, тәм табып сөйләүчән, матур-мөлаем Розалия буларак яратам. Син җыйган чәчәкләр һаман вазада торалар...
Син җыйган чәчәкләр вазада...
Саклана аларда аз гына –
Күңелең аһәңе – азаны,
Шулай ук кулларың назы да...
Син җыйган чәчәкләр вазада...
Кушылып бу моңым сазына,
Казанның гөлсөяр кызына,
Алардан җыр-сәлам языла...

Син җыйган чәчәкләр вазада...
Шиңәрләр – калмастыр азы да...
Тик бездә яшәсен яз гына.
Уралып сөю-гөл назына!
Синең хакта гына уйлап:
Рафаэль, 22 июнь, 91 ел.»

«Телефоннан апа белән сөйләшү. Розальне мактый. Хм-м! Лариса да Казанда аны бик яратып кайткан икән. Мөнҗия апа: «Розалия белән аерылышмагыз – кушылыгыз!» – ди. Да-а-а. Дела-а-а! Болай булгач, кушылмыйм дисәң дә кушылырсың әле. Ә кушылудан бер дә матур тормыш чыкмас шул... 11.12.91.»

«Сәлам Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү Рәфкать кызы Розалия Казыйхан оныгына! ...Розаль матурым! Искечәрәк шундый хат юлладым әле. Нигә искечә? Хисләрем искечә калганга. Дәлилгә көндәлектән берничә юл китерәм:

«Сөю дисәм, мәхәббәт дисәм –
Ул искә төшә. Ул гына... 23 март.»

«Үтереп аяк сызлый. Розаль Казанда шешне бетергәннән соң болай сызлаганы, интектергәне юк иде әле... Үлеп Розальне сагындым! Мин аны үлгәнче яратачакмын!!! Хәтта үлгәч тә... 29 март.»

«А. белән очраштык. Рәшитләргә киттек. Ә нигә Р. сагындыра? Янда – хатын-кыз, ә ул искә төшә. Ник алай? Ятратканга! 2 апрель.»
«Апрельдә сиңа багышлап берничә шигырь яздым. Берсе:
Онып, диде кемдер... Сөю шундый –
Тән, киемдәй ул да туза ди.
Хәтер исән чакта һич онытмам,
Розалия – Розаль – Розали...
Онып, диде көннәр... Аны сөю
Айлар буе тоташ җәза, ди.
Көннәр түгел, кем дә оныттырмас
Розалия – Розаль – Розали...
Онып, диләр еллар... Уза гомер,
Сагынулар булып уза да.
Еллар түгел, Үлем оныттырмас!
Розалия – Розаль – Розали...
18 апрель, 1993 ел.»

Рәсемдә: Розалиянең 1968 елда җибәргән бу фотосурәтен Рафаэль гомер буе паспорт эчендә йөрткән.



Җамалия әби җырлый-җырлый җеп эрли. Тәрәзәдән кергән кояш нурлары аның ак яулыгына, кара бөрчекләр төшерелгән ситсы күлмәгенә төшә. Еллар авырлыгыннан гәүдәсе бетерешсә дә, җитезлеген югалтмаган: җил-җил атлап идәнен дә юа, керен дә үзе ап-ак итеп агартып, өй каршындагы бауга чыгарып элә. Өе искергән, әмма тәрәзә кашагаларындагы чигүле сөлгеләр, тастымаллар күңелгә рәхәтлек бирә… Бу өйдә минем игътибарны үзенә иң тарткан әйбер – кызыл агачтан эшләнгән борынгы китап шкафы. Әбинең күз карасыдай саклый торган китаплары рәт-рәт шунда тезелешкән. Тик гарәп телендәге бу китапларга тешебез үтми – әлеге хәзинә янында без чеп-чи наданнар. Ә Җамалия әби, комган алып кулларын сабынлап юа да, бисмилласын әйтеп, берәр китапны алып көйләп кенә укый башлый…

ВӘГЪДӘ ЙӨЗЕГЕ



Фәгыйлә ШАКИРОВА

Ни өчен безне – совет мәктәбендә укучы, дискотекаларда котырынып биюче, төннәр буе мотоциклларда җил куучы егет-кызларны иске заман карчыгы үзенә тартты соң? Мөгаен, гадилеге, шәфкатьлелеге беләндер. Без аның өе каршындагы эскәмиядә төннәр буе кич утырабыз. Ә башка капка төпләрендә төн саклап кара! Ачуыннан бүртенгән хуҗа килеп чыга да, яшьләрне куып тарата. Җамалия әби алай итми! Намазга тәһарәтен алырга чыккач, комганын яшел чирәмгә куя да, җил капкасын сак кына ачып безнең янга килә.

– Ә балам, син кем кызы буласың әле? Мәһриҗан кызымы? Сөбханалла, бигрәкләр дә әбиеңнең яшь чагына охшарсың икән. Әбиең дә шулай кыңгырау зеңләгәндәй яңгыратып көләдер иде. Һай, гомер тиз уза…

Әби һәрберебез белән сөйләшеп чыга. Татлы сүзләреннән берәүне дә мәхрүм итми: Рәмзияне дә, Раушанияне дә… Безнең аның янында кунып калган чаклар да булгалады. Ялгызлыкны авыр кичергәнен белеп, әти-әниләр махсус җибәрә иде. Ярты литр яңа сауган сөт, мичтән чыккан түгәрәк ипи алып килсәң, әбекәй шатлыгыннан нишләргә белми. Утырып дога кылгач, теләкләрен тели:

– Йа Аллам, ярдәмеңнән ташлама. Мәңге бәхетле бул, балакаем. Язмыш үзеңә тиң ярыңны бирсен. Амин!

Үзе дә фәрештәдәй тоелган әби теләгән теләкләрнең кабул буласына күңел шундый ышана. Эчтән генә: «Амин, амин, амин!» – дип кабатлыйсың.

Бер кичне әни яңа савып кергән сыер сөтен савытка салды да Җамалия әби янына кертеп җибәрде. Әби ахшам намазын укый иде. Мин аны бүлдерүемнән куркып, сиртмәле тимер караватның бер читенә утырдым.

Өй кичке шәфәкъ нурында балкый. Әби көйли-көйли дога укый, аның тавышы шундый моңлы, колакны иркәли. Үзем дә сизмәстән, җанны биләп алган рәхәтлектән йокымсырап киткәнмен. Әбинең йомшак куллары чәчләремә кагылудан сискәнеп киттем.

– И балам, уяттым мәллә, чәй куйдым, – диде ул яратып.

Әбинең тәмле конфетлары белән чәй эчтек. Китәргә җыенганда әби кытыршыланган куллары белән тагын чәчләремнән сыйпап куйды.

– Аллаһы Тәгалә сиңа бәрәкәтле гомер насыйп итсен, иншаллаһ… Көчле ихтыярлы икәнеңне сизәм. Көчлеләргә яшәү авыр, балам…

Күзеннән агып чыккан яшен әби альяпкыч итәге белән сөртеп алды.

Шул вакытта әбинең йөзендә әйтеп, аңлатып бетерә алмаслык сагыш чагылды. Дүрт бала табып та, картлык көнендә караучысыз калган карчыкның хәсрәтен яшь йөрәгем барлык күзәнәге белән тойды…

Үсә барган саен, күрше әбинең язмышы белән ныграк кызыксына башладым. Аның дүрт баласы булып, өчесе үлгән икән. Ә кызы исә каядыр Ташкент якларында.

Елына берәр тапкыр авылга кайтып кунак була да, тагын китә. Ул кайту белән күңеле яшәргән әби кызының китүе белән кабат күңелсезләнә. Бер-ике көн урамга да чыкмый. Моңсу күзләре белән тәрәзәдән карап, дисбесен тарта.

Бер көнне исә Җамалия әби мине үзенә чакырды.

– Сөйләп калдырасы сүзләрем бар, балам. Дөньяга һәркем бәхетле булу өчен килә. Үз бәхетеңне ычкындырма – гомергә үкенеп, сары яфрактай саргаеп яшәрсең...

Кечкенә гәүдә тагын да бөрешкән, иңсәләре дер-дер калтырый.

Мин аны юатырга сүз тапмадым, гаҗәпләнеп, аптырап калдым. Җамалия әби нәфис итеп эшләнгән агач тартмадан көмеш йөзек алды.

– Харисымның вәгъдә бүләге – яшьлегем хатирәсе...

Әби сөйли, ә минем күз алдыма аның мәхәббәт тарихы килеп баса.

...Җамалия ишле гаиләдә төпчек кыз булган, үзенең шаянлыгы, уңганлыгы белән дан тоткан. Абыстайга йөреп, дин сабаклары өйрәнгән. Үз әбисе дә укымышлы, белемле карчык була – бар белгәнен оныгына өйрәтеп, якты дөнья белән саубуллаша.

Буй җитеп килүче кызга авылдагы байтак егетләрнең күзе төшә. Ләкин кызның йөрәгендә кавышырга өметләнгән яры бар. Менә көз генә җитсен, Харисы өен җиткезер, Җамалиясенә яучы җибәрер...

Ләкин язмыш аларга кавышулар насыйп итмәгән икән. Һич көтмәгәндә Җамалиянең апасы үлеп китә. Кан-кардәшләр арасында җыелып сөйләшүләр, киңәшләшүләр башлана. Дүрт баланың олысына – 12, кечесенә 2 яшь. Авылда кайсы хатын-кыз шул ятимнәрне үз канат астына алыр?

Җамалия – сизгер җан – бу көннәрдә күз яшенә буылып, үз-үзен кая куярга белми йөри.

– Харис җаным, өйләнешик, – ди ул, өзгәләнеп. – Күңелем хәвеф сизә, зинһар, ташлама! Әйдә, бүген үк мин сиңа ябышып чыгам.

– Җүләрем, – ди Харис. – Күңелеңдәге тиле уйларыңны чыгарып ташла. Сине миннән беркем дә тартып ала алмас. Өемне салып бетерим инде...

Егет, кесәсеннән фирүзә кашлы көмеш йөзек алып кызның бармагына кигезә.

– Вәгъдә бүләгем!

Ә туганнар үзләренчә хәл итә...

– Ятимнәрне читкә биреп булмас. Җамалия аларга әни булыр.

Кырык бишен тутырган җизни кеше исә бу тәкъдимне бик кулай күрә.

Җамалия әлеге хәбәрне иртә белән ишетә. Йөрәге өзгәләнгән, агарып каткан кыз тизрәк кич булуын, көтү кайтканын көтә. Яшь йөрәк түзми: бер-ике күлмәген, яулыгын төенчеккә төйни дә очрашу урынына – чишмә буена йөгерә. Берүзе еламсырап кара төн куенында сөйгәнен көтә. Һәрбер кыштырдауга өне алына аның. Минуты – сәгать булып, ә сәгать көн булып тоела. Ләкин... Харис килми. Җамалиянең югалганын сизеп, эзләп чыккан абыйлары кызны кыйный-кыйный таң атканда өйгә

Мин көмеш йөзекне кулыма алдым. Вәгъдә бүләге булса да, гашыйкларны кавыштыра алмаган ул.

алып кайталар. Атасы никах укытканчы кызны келәткә ябуны хуп күрә. Иртәгә мулла киләчәк – никах укытачаклар. Икенче кичкә саф – 17 яшьлек гүзәл кыз 45 яшьлек ир куенына керәчәк...

Җамалия җир тырнап елый, үрсәләнә-үрсәләнә келәт ишеген кага. Чү! Каян гармун тавышы ишетелә? Җыры таныш.

Юган керләремне элдем тышка / Сахра җилләрендә кипсен дип. / Кемнәр генә безне каргады соң, / Гомерләре аерым үтсен дип?..

Харисы! Харисы җырлый. Тик нигә Җамалиясен коткармый, нигә ишекне ватмый ул?! Кыз хәлсезләнеп җир идәнгә ава...

Җамалия әби шунда көрсенеп куйды.

– Харисым урманга барган җиреннән үз аягы белән кайта алмаган. Аягына бүрәнә төшеп, өенә күтәреп кайтканнар. Минем кияүгә чыгуымны әнкәсеннән ишеткән... Ачыргаланып елап җибәргән, мескен. Ахырдан гармуны белән безнең капка янына илтүләрен сораган.

Җамалия әбинең иңнәре калтырана.

– Гомерем буе аны сагынып, елап яшәдем. Бер ягымда – дүрт бала, түшәгемдә – карт ир... Күпме тапкыр бау алып асылынырга ниятләдем. Ятим сабыйлар хакына калдым... Ә Харис белән икебез дә, гомер буе сыкранып, Сак белән Сок күк яшәдек. Урамда күргәндә: «Әйдә, качыйк, китик авылдан», – дип ялына иде. Юк, итәгемә тагылган гөнаһсыз сабыйларымны ташлый алмадым. Үзем дә таптым... Ходай теләмәгәндер: өч баламның туган берсе үлеп барды.

Әби тынып калды. Ә мин кулына гармун тоткан Харисны күз алдына китерергә тырыштым.

– Әби, хәзер исәнме соң ул?

– Харис дөньяда юк инде, балакаем... Үлем түшәгендә ятканда аңа 30 яшь кенә иде. Өйләнмәде, бахыр. Бәхилләшергә бардым. Кулымны кыскан килеш җан бирде. «Теге дөньяда бергә булырбыз...» – соңгы сүзе шул булды. Кызым, аманәтемне сиңа әйтәм, гомерем озак калмады. Үлгәч, кәфенләгәндә ирештер: мине гүргә шул йөзек белән индерсеннәр. Китапларымны сиңа бүләк итәм. Чит кулларга бирмә. Изге, борынгы китаплар алар. Төсем итеп сакла...

Мин Казанда югары уку йортларның берсендә икенче курста укыган чагымда Җамалия әби якты дөнья белән хушлашты. Аның соңгы теләге үтәлде: Җамалия әби гүргә вәгъдә йөзеге белән җирләнде. Дөньяда кавыша алмаган Харис белән Җамалия, бәлки, ахирәттә табышканнардыр. И Ходаем, шулай булсын иде.

Әлмәт районы,
Түбән Абдул авылы.



АЛМАН ИЛЕ ЯКИ ҖАВАПСЫЗ СОРАУЛАР

Айгөл
ӘХМӘТГАЛИЕВА

Баласы читкә киткән кеше үз хәлен үзе генә беләдер... Бар да әйбәт икәнен аңласаң да, җан урынында түгел. Кызыбызга өченче курсны Германиянең Регенсбург университетында дәвам итәргә насыйп булды. Аның хәл-әхвәлен белеп, үз күзебез белән күреп кайтырбыз, берочтан сәяхәт тә итәрбез дип, ирем белән юлга кузгалдык.
Шулай итеп, төп маршрутны сызабыз: Регенсбург–Зальцбург–Братислава–Вена–Прага–Регенсбург. Моннан тыш, Мюнхенда буласы, Дахау концлагерен күрәсе килә.

Яхшы кешеләр кайда да очрый...

Интернет сайтларыннан отельләрне сайлау бик җиңел булды, немец транспорт компаниясе автобусларына билет алу да чикләвек ваткандай гына хәл ителде; телефонга төрле илләрнең картасын, истәлекле урыннарын күрсәткән махсус кушымта урнаштырып куйдык. Мәскәүдән Мюнхен аэропортына ике сәгать эчендә килеп җиттек. Кызыбыз барысын да җентекләп аңлатып, татарча да, немецча да, инглизчә дә язып җибәргән иде: таможня тикшерүен бернинди проблемасыз үттек. Аэропортның үзеннән үк Регенсбургка туп-туры поезд йөри, кызыбыз өйрәткән урыннан билет алырга дип шунда ашыгабыз. Гөнаһ шомлыгына, бүген ял көне – билетны автомат рәвештә терминалдан алырга кирәк икән. Безнең немец теле кинолардан ишетеп үскән өч-дүрт җөмләдән артмый, ул терминалны «укып-өйрәнгәнче» поезд ярты дөньяны әйләнеп чыгарга өлгерәчәк бит... Үтеп баручы полиция хезмәткәреннән вата-җимерә инглизчә ярдәм соравыбыз да уңышсыз булды: ул төймәләргә баскалап-төрткәләп карады каравын, тик аның да беркайчан бирелдән билет алганы булмаган, күрәсең: «Белмим бит», – дип, җилкәсен сикертеп, китеп барды. Дөрес, «Билетсыз утырмагыз, юкса штраф салачаклар», – дип кисәтергә дә онытмады... Поезд килергә минут ярым вакыт калган иде, ни булса шул булыр, дидек тә, Аллага тапшырып, платформа янына төшеп бастык. Шулай да җан түзми: безнең кебек үк поезд көтеп торган яшь кенә кыздан, мин – татарча, ирем – инглизчә: «Билетсыз утыра алабызмы?» – дип сораштырабыз. «Юк, алайса штраф салалар», – ди ул елмаеп. Ул арада секундка да соңармыйча, йөзеп кенә поезд да килеп туктады: кызыкай безгә карый-карый вагонга кереп китте. Бераздан кире чыгып, кул изәргә тотынды: немецча нидер сөйли. Их шул тел белмәү... Тик барыбер аң-



Дунай аша салынган Таш күпер 1135–1146 елларда төзелгән, аның янындагы музей искиткеч бай мәгълүматка ия.

Бирედә 1500 ләп йорт – Рим империясе истәлекләре, алар дәүләт тарафыннан саклана.

лаштык: безнең бәхеткә, нәкъ шул мизгелдә контролерның вагоннан билет тикшереп чыгып килүе икән. Кыз аңа безнең билетсыз икәнне аңлатты, контролер исә, елмаеп, шалт та шолт ике билет сугып, кулыбызга да тоттырды. Юлыбызда яхшы кешеләр очрау белән башланган сәяхәтебезгә сөенә-сөенә, поезд тәрәзәсеннән тирә-яктагы ят дөньяны күзәтеп барабыз...

Тар урамнар, ярсу Дунай һәм Регенсбургта татар гаиләсе

Регенсбург – Баварияда урнашкан бик борынгы шәһәр. Яшеренбатырын түгел, без Германияне күбрәк сугыш турындагы китаплар, фильмнар аша белеп, шул рәвешле үз карашы формалашкан буын. Немец халкы һәм фашизмның икесе ике төшенчә икәнен акыл аңлый анысы... Нәкъ менә Бавария авылларында безнең әсирләр (бәхетлерәкләре – бай хуҗага эләгеп, аның хуҗалыгында эшләгән, шул сәбәпле исән калган) бил бөккән... Кем белә, менә хәзер мин сокланып карап барган ап-ак стеналы йортлар, туры урамнар, кисеп ясалгандай тип-тигез бакчалар сукмагында авылдашларымның аяк эзләре ярылып калгандыр... Мондый уйлардан качарга теләп, бүгенгемә кайтам...

Кызыбыз безгә Регенсбургның Альтштат дигән урынын – үзәген, борынгы өлешен күрсәтә: безнең эрага кадәр нигез салынган, герцоглар, епископлар эзе калган бу тирәләр тере тарихның үзе кебек. Монда готика стилендәге соборларны, барокко стилендәге йортларны, роман стилендәге биналарны, гомумән, архитектураның сокланып туймаслык үрнәкләрен күрергә мөмкин.

Регенсбург зур шәһәр түгел, монда 150 мең тирәсе кеше яши. Шәһәр BMW автозаводы, Европада иң атаклыларның берсе булган Университет клиникасы, BioPark биотехнологик комплексы, университетлары белән дан тота. Әлеге уку йорты дөньядагы иң яхшы 400 университет исемлегенә кергән.

Үзенең тынычлыгы белән Регенсбург безне башта шаккаттырды, аннан сокландырды. Дунай елгасы гына шулкадәр кайнапактарылып ага, ә аның ике ягында урнашкан шәһәр иренчәк бер тынлыкта... Урамда машиналар юк диярлек – алар барысы да парковкада гына күзгә чалына. Олысыкечесе – велосипедта. Урамда бездәге шикелле халык агымы күренми: шунысына тәки ияләшеп булмады. Мин, кыбырсып, үзебездәге тормыш белән чагыштырырга маташам: ясалма керфек куйган, каш ясаткан, бизәнгән кызлар-ханымнар очратам димә – барысының да йөзләрендә табигый матурлык! Барысы да кроссовка, джинсы чалбар, гади генә футболкадан: бездәге шикелле үкчәле туфли, аллы-гөлле күлмәк-костюм киеп йөрүчеләр юк. Эчтә яки урам кафеларында дәү кружка тотып, үтә ялкау бер кыяфәттә сыра эчеп утыручылар байтак, тик исерекләр күзгә чалынмый. Хәләл кафе, хәләл кибетләр, гарәп, рус кибетләре бар. Халыкның төп өлеше ике катлы шәхси йортларда яши: апакка буялган, бернинди бизәксез, безнең күзгә барысы бертөсле,



Урамнарның берсендә Оскар Шиндлер истәлегенә куелган мемориаль тактага тап булабыз. Бу исем безгә «Список Шиндлера» фильмы аша таныш. Шиндлер – немец промышленнигы, сугыш елларында үлемгә хөкем ителгән 1200 ләп яһүдне үзендә эшләтеп, аларның гомерен коткарып кала. 1945–1950 елларда ул Регенсбургта яшәгән, әлеге тактаны ул яшәгән йортка куйганнар.

PRESSA

Юллар – күзгә кебек, өстәленә куйган чәйле стакан чайпалып түгелер дип куркасы юк.

әмма зәвыклы күренгән йортлар урам-урам тезелеп киткән. Бездәге шикелле биек тимер капкалар юк, авылдагыча, тәбәнәк, бик гади коймалар. Барган көнебездә үк берәүнең почта тартмасында яртылаш урамга багып торган газета-журналларны күреп, борчылып куйган идем: янәсе, ник чыгып алмыйлар икән, берәрсе алып китсә... Чөнки үзебезнең тартмага дыңгычлап салып куйган «Сөембикә» журналының, газеталарның ничәмә тапкыр «аякланганы» булды, авыз пешкән бит... Ни гаҗәп, китәр көнебез якынлашканда да әлеге газеталар урынында иде: хуҗалары өйдә юк иде, күрәсең...

Кызым Регенсбургта Казаннан Илшат исемле егет укуын, аның бик ярдәмчеллеген, Чаллы кызы Зиләнең үз гаиләсе белән биредә яшәвен, аралашып торуларын әйткән иде. Илшатны күрергә өлгермәсәк тә, Сөләйман белән Зиләнең кунакчыл йортында бер түгел, ике тапкыр булырга җитештек. Зилә белән әллә никадәр уртак танышларыбыз килеп чыкты, аның белән сөйләшкәннәребез үзе бер аерым әсәрлек... Ире Сөләйманның тамырлары Арча–Кукмара ягыннан, үзе Казакъстаннан. Яралы җаннарны язмыш үзе табыштырган, үзе кавыштырган. Зиләнең улы Камилгә туганда ук ДЦП диагнозы куела, яшь хатын әлеге сынау белән бераздан япа-ялгыз торып кала, гаиләсе таркала. Сөләйман аңа тәкъдим ясаганда, намаздагы бу ир-егетнең олы йөрәгенә, мәрхәмәтлелегенә ышанычы нык булгандыр. Шулай булмаса, Аллаһы Тәгалә күрсәткән юлны үзенең кыйбласы дип сайлаган, ислам динендә тынычлык тапкан Зилә, Казанны, якыннарын калдырып, күз күрмәгән алман иленә чыгып китәргә батырчылык итмәс иде. Чит телләр белән бәйле белгечлек алу да Аллаһының алдан ук күрсәткән бер могҗизасы булгандыр... Бүген гаиләдә, абыйсы Камил янында, терекөмеш кебек елгыр Азизәләре үсеп килә: бакчада, урамда яшьтәшләре белән алман телендә аралашкан кызчык өйдә барысы белән дә чип-чиста итеп татарча сөйләшә! Әнисе балаларга татарча шигырьләр, әкиятләр укый, киштәләрендә Казанга кайткан саен алып килгән татар китаплары тезелгән...

Алар яшәгән дүрт катлы йорт өч өлештән тора. Физик мөмкинлекләре чикләнгәннәр өчен дәүләтнең социаль проекты буенча махсус төзелгән. Лифт та, подъездлар да, ишегалды да, астагы гаражлар да коляска белән йөрү өчен уңайлы итеп эшләнгән, бернинди киртә юк. Гомумән, Германиядә бу яктан бөтен җирдә игътибар күзгә күренеп тора: ишекләргә орынып торасы юк – алар бар җирдә үзеннән-үзе ачыла; коляска өчен пандуслар һәр җирдә бар.



Шулкадәр тар урамнарда йөргәндә, каракаршы торган йортлардан тәрәзә ачып, кул сузып исәнләшергә мөмкиндер кебек тоела.

Үзенә дәшкән юллар, ябык кибетләр һәм башкалар

Регенсбург университетында алманнар гына түгел, дөньяның төрле иленнән килгән студентлар укый. Курсларны үзләре сайлау хокукына ия: уку расписаниесен һәркем үзе төзи, теләгән фәннәренә язылып йөри. Алман укучылары үзләре дә шул ук кагыйдәләргә буйсына. Читтән килгән кайбер студентларга, бәхет елмаеп, стипендия дә эләгергә мөмкин. Аның 150 евро чамасы семестр взносы рәвешендә тотып калына, шул хисапка студент семестр дәвамында Регенсбург эчендәге транспортта гел бушлай йөри. Биредә без «баварский билет» дигән төшенчәне бик ошаттык. Бу билет белән тәүлек эчендә Бавариянең теләсә кайсы шәһәрендә, теләсә кайсы транспортында йөрергә була: поездга да, метрога да, трамвайга да, автобуска да утыра аласың: беркайда кабат түләргә кирәкми. Аның үзенчәлеклеге менә нәрсәдә: әйтик, бер кешелек билет 27 евро тора, ике кеше бергә сәяхәт итә икән, шул ук «баварский билет»ны ике кешегә 54 түгел, ә 35 еврога алып була. Кеше саны арткан саен, һәркемнең түлисе өлеше кими бара. Ул билет белән, теләгең



■ Лагерьдагы һәр ноктаны, һәр экспонатның ни-нәрсә икәнен русча шәрехләп аңлатучы «гидыбыз»ны – трубканы колакка терибез дә кнопкага гына басабыз. «Arbeit macht frei» («Хезмәт иреклe итә») дип язылган тимер капкадан лагерь территориясенә керүгә ук эчне әллә ялкын, әллә салкын биләп ала.

булса, көн дәвамында Мюнхенга да, Нюренбергка да барып кайта аласың. Ләкин синең белән барган иптәшләрең синнән калмый гел бергә сәяхәт итәргә тиеш.

Якшәмбе көннәрендә Европа шәһәрләрендә кибетләр эшләми. Берсе дә! Сәбәбе гади: кибетче дә ял итәргә, бу көнне үз гаиләсе янында үткәрергә хокуклы! Хәстәрле халык ипи-сөт ише ризыкны алдан ук өенә алып кайтып куя. Яхшы булды әле: Венада, Прагада йөргән көннәребез ялларга туры килде. Кибетләр эшләсә, ярты көнебезне шунда уздырган булыр идек...

Илдән-илгә сәяхәт иткәндә, автобус, поезд эчләре бик уңайлы. Вай-фай булу үзе бер рәхәт! Автобуста кофе-чәй эчәм дисәң, кечкенә өстәлләр дә бар, аягыңны куйыйм дисәң, үзең теләгәнчә көйләрлек «подставкалар» да әзер. Поездда да хикмәт: тукылдаганы да, җырлаганы да ишетелми, нинди рельслардыр ул – тавышсыз сәгать шикелле үз көенә генә тәгәри. Төнлә барганда шунысына игътибар иттек: поселок-шәһәрчекләрдә ут шулкадәр саран яна! «Экономия» дип аңлаттылар. Көндез исә юл буе буйдан-буйга сузылган «кояш батареялары» озата. Алман авылларының үзенчәлегенә авыз ачып шаккатырга туры килде: ун-унбиш йорттан гына торганнарының да һәр урамында шома асфальт җәйрәп ята. Ферма дигәннәрендә хастаханәдәге кебек аклык, чисталык күзгә ташлана. Юлдан ерак түгел берүзе генә балкып утырган замок ише йортларда тормыш кайнаганын күреп тә аптырадык: күршекүләнсез ничек гомер итәләрдер...

Дахау – кансызлыкка тере һәйкәл

Дахау концлагере мәктәп елларыннан ук миңа шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй крематорийда яндырылган урын буларак хәтеремә уелган. Әлеге урынны үз күзләребез белән күрү фашизмның ни дәрәҗәдә шайтани асыл икәненә тагын бер кат инанырга мәҗбүр итте. Биредә кайсы телдә тыңларга телисең – шул телдә сөйләүче гид-телефонны алырга була. Бик уңай! Кайчандыр бараклар тезелеп киткән урыннарда инде яңартылып, туристлар өчен төзелгән үрнәк кенә тора. Чәнечкеле тимер чыбык белән уратылган үр янында – элек пулеметчылар басып торган вышкалар. Җәзалау бүлмәләре. Тоткыннардан алынган сәгать, фотография, документ ише әйберләр тезелгән киштәләр. Әсирләрнең буй-буй киемнәре, котелок-кашыклары. Бихисап фотолар...

Лагерь башта әсир яһүдләр өчен дип төзелгән. Яһүдләр эшче көч буларак та, медицина тәҗрибәләре өчен «чимал» буларак та файдаланылган. Сугыш елларында – меңләгән әсирләр өчен соңгы тукталыш... Кинозалга кереп утырып документаль фильм карыйбыз. Русчасы соңрак буласы иде, көтеп тормыйча, француз телендә тыңлыйбыз. Монда тел белү-белмәү мөһим түгел. Фильм коточкыч чынбарлык турында. Скелетка калган кешеләрнең шәүлә булып хәрәкәт итәргә маташулары. Мәеткә әверелгән ул скелетларның әрдәнә-әрдәнә итеп өелгән гәүдәләре. Америка солдатлары килеп коткарганда, ул мәетләрне күргәч, акылдан шашкандай экранда катып калган күзләре, укшып читкә тайпылулары... Җан әчтән тетрәнә, елый, бу кадәр мәрхәмәтсезлеккә кеше диган затны нәрсә этәрә диган сорауга җавап эзләп бәргәләнә... Система корбаны булу, буйсыну, зомбилаштыру нәтиҗәсеме?..

Крематорийны тасвирларга сүзләр җитми. Бүген дә шомлы бер һәйкәл булып утырган бу корылма да әсирләрнең чишенү бүлмәсеннән үтәбез, газ җибәрү өчен кулланылган кнопкага текәләбез, утын яккандай, кеше гәүдәләрен үз авызына озаткан мичләргә телсез калып төбәләбез... Янәшәдә генә күз яшьләредәй чиста булып күренгән тар инеш. Кемнәрнең генә гомерләре, каннары, тән һәм җаннары юылмагандыр бу инештә...

Дахаудан соң юлыбыз Мюнхен шәһәренә иде. Гаҗәеп архитектурасы, кояшы белән каршы алса да, яшермим, мин ул матурлыкка соклана алмадым. Җанымнан кояш урланган кебек иде: зур шәһәрнең туристлар белән тулган урамнарын, мең төсмергә кереп балкыган соборларын, бизәкләрен матурлык итеп кабул итәргә шул тойгы комачаулады...

Җиңелгән илдән мең төрле, каршылыклы уйлар ияреп кайтты безгә. Һәм... мең төрле җавапсыз сораулар кайтты...



Баласы эче авыртудан зарланган әни-әниләр, гадәттә, аппендицит булу ихтималын уйлап, хафага калучан. Ашыгыч ярдәм чакырткан очракта да табиблар иң элек аппендицит булу-булмавын ачыкларга керешә. Еш очраучы әлеге диагноз турында Республика балалар клиник хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире, югары категорияле табиб, балалар хирургы Ринат ЯФЯСОВ белән сөйләшәбез.

БАЛАДА АППЕНДИЦИТ

Мөгаен, күпләр хәбәрдардыр: аппендицит ул – сукыр эчәк үсентесенең ялкынсынуы. Әлеге ялкынсынуны нинди дә булса билгеле бер микроорганизмнар түгел, ә эчәклектә яшәүче шартлы-патоген бактерияләр китереп чыгара. Аппендицитның кискен һәм хроник формасы бар дип саналса да, табиблар арасында әлегәчә бердәм фикер юк. Беренче очракта чирнең тиз арада көчәеп, кеше гомере өчен куркыныч тудыруы күзәтелә. Ә икенчесе турында медицинада бүген дә бәхәсләр тынмый.

Кискен аппендицитның да гади (катараль), үлекле (флегмоз) һәм таркала башлаган (гангреноз) төрләре очрый. Алай да хирурглар флегмоз аппендицит белән ешрак очраша. Бу инде әти-әниләрнең табибка соң мөрәҗәгать итүе турында сөйли. Соңгы биш елда Республика балалар клиник хастаханәсендә дәваланучыларның 50 процентына кагыла бу.

Һәр очракта да эч авыртуы аппендицит дигән сүз түгел, билгеле. Әмма авырту алты сәгатьтән артык дәвам итсә, ашыгыч ярдәм чакырырга кирәк. 3 яшькә кадәрге сабыйлар үзләрен нәрсә борчуын елап һәм көйсезләнеп белдерә. Баланың ашаудан баш тартуы шулай ук игътибарга алынырга тиеш. Аппендицит яңа туган балаларда сирәк очрый. Аның белән 9–10 яшьлекләр ешрак авырый. Аппендицит үзеннән-үзе генә узучы чир түгел. Бездә ул консерватив чаралар белән дәваланмый. Ләкин 2000 нче еллардан башлап кискен аппендицитны операциясез дәвалау очраклары турында яза башладылар. Катлауланган аппендицит билгеләре булмаганда һәм табиб күзәтүе астында гына консерватив дәва методлары кулланылырга мөмкин.



Сәбәпләре:
- сукыр эчәк үсентесенең тыгылуы. Моңа бала йоткан вак-төяк чүп тә, вак суалчаннар, тәрәт ташы да сәбәпче булырга мөмкин. Үсентенең лайлалы катламы шешенү дә буш аралыкның йомылуына китерә ала;
- сукыр эчәк үсентесенең кан әйләнеше бозылу.

Табиб килгәнче:
- баланы ашату тыела, су эчерергә мөмкин;
- авыртуны баса торган препаратлар бирергә ярамый, спазмнарны басучы препаратлар рөхсәт ителә;
- баланың эченә җылы кую тыела, ә менә салкын куярга ярый.





Билгеләре:
- эч авырту: еш кына ашказаны тирәсендә башланып, тора-бара уң якка, касыккарак күчә;
- баланың аппетиты булмау;
- тән температурасы күтәрелү;
- йөрәк тибеше ешаю (тахикардия);
- эчәклекнең эшчәнлеге бозылу (эч кибәргә яки, киресенчә, сыекланырга мөмкин);
- күңел болгану, костыру.

Табиб киңәш итә: аппендицитка операция кичергән пациентларны гадәттә икенче көнгә үк урыннан торгызалар. Әмма баланың туклану рационы бер ай дәвамында җиңелчә генә ризыклардан торырга тиеш. Шулай ук ике ай дәвамында аны авыр көч килүдән сакларга кирәк. Гадәттә, аппендицитка ясалган операция бала организмына әллә ни зур йогынты ясамый, тернәкләнү өчен күп вакыт һәм махсус чаралар таләп ителми.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зәһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Бөер – кеше организмындагы иң мөһим органнарның берсе. Алар бәвел ясалышында төп рольне башкара, тәүлегенә 1500 литр канны чистартып, калдык матдәләрдән, тозлардан арындыра. Бөерләр эшчәнлегендәге кечкенә генә чатаклык та кешенең тормыш сыйфатына бик зур йогынты ясый. Республика клиник хастаханәсе поликлиникасы нефрологы, югары категорияле табиб Елена МИТРОФАНОВА белән бөерләр ялкынсынуы хакында сөйләшәбез.

БӨЕРЛӘР ЯЛКЫНСЫНУЫ

Бөерләрнең инфекцион ялкынсынуы медицина телендә пиелонефрит дип атала. Пиелонефрит белән ир-атлар да, хатын-кызлар да авырый, әмма хатын-кызларда ул ешрак күзәтелә. Моның сәбәбе – безнең анатомик үзенчәлегебездә. Хатын-кызларның бәвел юллары киңрәк һәм кыскарак, шуңа да төрле инфекцияләр бөерләргә тизрәк үтеп керә. Хатын-кызларның өч төркеме әлеге чиргә ныграк бирешүчән. Болар: кыз балалар, авырлы ханымнар һәм өлкән яшьтәгеләр. Кызларда ул туры эчәк һәм аналык җиңсәсенең бәвел юлына якын урнашуы белән бәйле. Авырлы ханымнарда пиелонефрит гормональ үзгәрешләр аркасында килеп чыгарга мөмкин. Өлкән ханымнарда исә бәвел юлларының лайлалы тышчасы атрофиясе сәбәпче. Әлеге тышчаның юкаруы төрле инфекцияләргә җиңел үтеп керү өчен юл ача.

Пиелонефрит еш кына бәвел юлы ялкынсынуы – цистит белән башлана. Аны вакытында һәм ахырынача дәваламасаң, инфекция бөерләрне дә зарарлый. Авырлы ханымнарда пиелонефрит симптомнарсыз да булырга мөмкин. Бәвелдә лейкоцитлар артса, авырлы ханымнар пиелонефриттан дәва курсы узып, табиб күзәтүендә торырга тиеш. Гомумән, хәзерге вакытта медицинада хроник пиелонефрит дигән диагноз юк. Һәр эпизод кискен ялкынсыну кебек, вакытында һәм ахыргача дәваланырга тиеш. Ахыргача дәваланмаган очракта ул үлекле төргә әверелергә мөмкин. Бүгенге медицинада пиелонефритны тиз һәм катлаулануларсыз дәвалау ысуллары күп. Дәва чаралары һәр пациентка аерым билгеләнә. Һәркем өчен дә бердәй туры килерлек дәва схемасы юк.

Диагностика өчен баштагы мәлдә гомуми бәвел анализы, бөерләргә УЗИ һәм канда креатинин микъдарын күрсәтүче анализ кирәк. Калганнарын табиб үзе билгели. Кискен пиелонефрит вакытында кичекмәстән дәва курсын башлау таләп ителә, чөнки еш кына пациентның хәле кискенләшә.

Билгеләре:
- кече йомышка еш кысталу;
- бәвел бүленеп чыкканнан соң авырту, әчетү;
- югары температура (кайчак 40 ка җитәргә мөмкин);
- бил авырту (йөргәндә ул тагын да көчәя);
- бәвелдә лейкоцитлар артуы;
- бәвелдә кан күренергә мөмкин.

Пиелонефритка китерүче факторлар:
- бәвел юлларының чирләре;
- бөерләрдә таш булу;
- диабет;
- бөердә поликистоз;
- җенес органнары ялкынсынуы;
- гормональ дисбаланс.



Табиб киңәш итә:
- пиелонефриттан иң беренче профилактика чарасы – җылы киенеп йөрү, үтәли җилдән, туңудан саклану;
- хатын-кыз чирләрен вакытында дәвалау;
- дөрес туклану – эчәклекнең дөрес эшләвенә ирешү, эч кибүне булдырмау;
- бөер ялкынсынуын дәвалаганда фиточәйләрнең дә шифасы бар. Төп дәва чаралары белән беррәттән, укроп орлыгы, петрушка, толокнянка төнәтмәләре кулланырга мөмкин. Нарат һәм мүк җиләге морслары да чирне тизрәк җиңәргә булыша.
- бөер ялкынсынуы еш күзәтелгән кешеләргә минераль сулар белән дәвалаучы санаторийларның уңай нәтиҗәсе бар. Бу очракта бәвелнең әчелегенә игътибар итәргә кирәк. Бәвелнең әчелеген белмәүчеләр нейтраль минераль су белән дәвалаучы санаторийны сайлый ала.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

Өй – хуҗаның күңел чагылышы

дигән бер акыл иясе. Һәр хуҗабикә үз өендә мәхәббәт һәм бәхет иҗат итәргә тырыша, дип җөплик бу фикерне. Өйдә уңайлы һәм рәхәт булсын өчен һәр әйбернең, җиһазның дөрес урнашуы мөһим. Әлеге сәхифәбездә йорт-җирләрне матурлау, өйдә җылы атмосфера тудыру серләре белән бүлешәсебез килә. Бу өлкәдә эшләүче белгечләр безгә киңәшләр бирер, файдалы мәгълүмат белән бүлешер.

Театр – кием элгеченнән, ә безнең өебез алгы бүлмәдән (прихожая) башлана. Өйгә килеп керүчеләрнең кәефенә дә иң элек алгы бүлмәдәге халәт тәэсир итә икән. Бу бүлмәне ничек матурларга, заман таләпләренә туры килерлек итеп ничек ясарга?! Интерьер дизайнеры Ландыш ХӘСӘНҖАНОВА фатирыбызның (йортыбызның) әлеге мәйданын дөрес планлаштырырга өйрәтер. Куюки бистәсендәге гади генә ике бүлмәле фатир мисалында алгы бүлмәне дөрес итеп оештыру мисалларын күрербез.



Ишектән кергән өлешне үзгәртергә яки ремонт ясарга уйласагыз, иң беренче эш итеп кулга кәгазь, карандаш алырга һәм барысын да шунда язып-сызып планлаштырырга киңәш итәм.

Шкаф яки гардероб бүлмәсе

Әгәр алгы як бүлмәсенең мәйданы шактый зур икән, бу очракта гардероб бүлмәсе ясау отышлы булачак. Барлык өс-баш, аяк киемнәрен, спорт кирәк-яракларын, төрле тартмаларны, чемоданнарны бу бүлмәдә саклау җайлы. Бары тик киштәләрне генә дөрес урнаштыру мөһим. Урын азрак булганда, түшәмнән идәнгә кадәр (встроенный) шкаф ясатырга киңәш итәр идем. Ә менә шкаф-купелар турында онытыгыз, визуаль яктан карaганда алар бүлмәне тутырып, артык йөк кебек торачак.

Мөһим сораулар

Өйнең әлеге өлешен планлаштырганда үзегез өчен менә шушы сорауларга алдан җавап табып куярга тиешсез:

- Фатир ишеге кай якка ачыла, ул бернәрсәгә дә комачауламыймы?
- Фатирга кергәч тә сумка-пакетларны кая куярсыз?
- Ачкыч кую урыны бармы? (Ачкычлар өчен махсус савыт, стенага беркетелгән тартма эшне шактый җиңеләйтә, ачкыч эзләп интегүләр булмас!)
- Башка бүлмәләрнең ишеге кайсы якка ачылачак, биредәге өй җиһазына комачау итмәсме?

Көзге

Ишектән кергән өлешкә мөмкин кадәр зур көзге куярга киңәш ителә. Ул бу мәйданны зуррак итеп күрсәтәчәк. Киенгәндә, кершәннең дөрес ягылганын карар өчен дә кирәк ул хатын-кызга!

Җиһазлар

Аяк киеме кигәндә уңайлы булсын, сумка куеп торыр урын табылсын дисәгез, алгы бүлмәдә берәр утыргыч яки пуфик торсын. Шкаф турында әйттек инде. Аяк киеме киштәсе турында да истән чыгармагыз. Һәм бик зур булмаган кием элгече. Яңгырлы, карлы көнне чыланып кайткач өс киемен салып киптерер өчен. Кулчатыр куяр өчен дә җайлы булыр ул. Тик барысы да мөмкин кадәр аз урын алсын – минимум булсын, бу зонаны артык әйбер белән тутырырга кирәкми!

Идән

Ишектән атлап керүгә җылы идәннән атлавы рәхәт. Шуңа плитәләр астына җылыүткәргеч җайланмасы «җибәрерсез», бәлки?! Ишек төбендә салып калдырган аяк киемнәренә дә кибәргә уңайлы булыр. Кергән өлешкә плитка салып, идәннең дәвамын башка материалдан да җәяргә мөмкин.

Яктылык

Алгы бүлмәдә яктылыкны экономияләргә ярамый! «Көндезге ут» функциясен үтәүче лампочкалар куясызмы, саргылт төс бирә торган яктылык чыганаклары урнаштырасызмы – стенадагы обойларга карап хәл итегез. Холл кечкенә булганда аны якты төсле обойлар яки буяулар белән бизәргә кирәк дигән фикер дөрес түгел. Барысын да стенадагы, түшәмдәге ут чыганаклары хәл итә! Розетка, ут кабызу урыннарын алдан планлаштырып эшләү – үзегезнең уңайлылыкны алдан кайгырту дигән сүз.

Алгы бүлмә безне һәр көнне озатып кала һәм каршы ала. Өебезнең иң нурлы, якты урынына әйләндерик без аны!

Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.

Ышанулар

- Ишек каршындагы мәйдан һәрвакыт чиста-пөхтә булырга тиеш. Чөнки шул өлештән безнең өйгә уңай энергия керә, ди фен-шуй белгечләре.

- Акча энергиясенең юлы да бу мәйдан аша уза икән әле! Шуңа күрә бүлмәнең почмаклары чиста булырга тиеш!

- Көзгене ишеккә каршы куярга ярамый! Кергән уңайга энергия көзгедә чагылып, кире чыгып китәргә дә мөмкин икән!

- Ишек төбендә пычракны үзенә сеңдерүче кара төстәге келәм ятарга тиеш.

- Элек-электән кешеләр үзләре яшәгән урынны начар көчләрдән сакларга тырышкан. Кайбер халыкларда ишек төбенә кыңгырау элү гадәте бар. Шулай ук шәмаил, артыш таягын куючылар да бар, ишек өстенә эленгән ат дагасы бәхет китерә дигән ырым да яши.












Фото: Анна Арахамия

Чәшкедәге «торт»



Капкейкны Америкада уйлап тапканнар. Икенче төрле «чынаяктагы торт» дип атап йөртәләр аны, гәрчә бернинди чәшкедә әзерләнмәсә дә. Гади кекстан аермасы – җиләк-җимеш, шоколад кисәкләре белән бизәлгән кремлы «эшләпәсе» бар аның. Татлы капкейкны хәзер безнең уңган татар кызлары да пешерә белә! Нарат җиләге белән бизәлгән әчкелтем тәмдәге капкейкларны «Сөембикә» укучылары өчен аш-су остасы Гөлия ВӘЛИУЛЛОВА әзерләп күрсәтте.

Кирәк

Камыр өчен:

- 2 йомырка;
- 120 г он;
- 100 г шикәр комы;
- 80 г шикәр пудрасы;
- ярты бал кашыгы камыр көпшәкләндергеч (разрыхлитель);
- ¼ бал кашыгы сода;
- 120 г эремчекле йомшак сыр;
- 100 г атланмай;
- ванилин.

Әчлек өчен:

- 100–150 г нарат җиләге;
- 1 аш кашыгы крахмал;
- 3 аш кашыгы шикәр.

Крем:

- 200 мл 33% сөт өсте;
- 200 г йомшак сыр («Маскарпоне»);
- 1 стакан шикәр пудрасы.





Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Капкейкларга джемны кичтән үк әзерләп куярга кирәк. Аның өчен савытка шикәр комы, крахмал, нарат җиләге һәм 3 аш кашыгы кайнаган су өстәп, утка куябыз. Нарат җиләген утта килеш төябез. Куерганчы болгатып торабыз һәм кайнап чыккач сүндерәбез.

■ Сөзгеч аша кесәлен чыгарабыз. Шуннан джем барлыкка килсен өчен, суыткычка 10–12 сәгатькә куябыз.

■ Камыр әзерләү өчен шикәр комы, шикәр пудрасы һәм йомырканы бергә кушып, миксер белән өч-дүрт минут туглыйбыз.

■ Шуңа эретелгән атланмай кушып, өч-дүрт минут туглыйбыз, суыткычтан гына алынган йомшак сырны да салып, туглауны дәвам итәбез.

■ Иләнгән әзер онга сода, камыр көпшәкләндергеч һәм ванилин кушабыз, аннан акрын гына майлы массага салып, ике-өч минут дәвамында болгатабыз. Шулай итеп, безгә кирәкле камыр әзер.

■ Капкейк өчен ясалган тимер савытка кәгазь формалар куеп чыгабыз.

■ Формаларга тулы бер кашык камыр салып чыгабыз һәм 25–30 минутка 180 градуска кадәр кызган мичкә пешерергә куябыз.

■ Ул арада крем әзерли торабыз.

■ Суыткычтан гына алынган сөт өстен (салкын булуы мөһим!) шикәр пудрасы кушып, миксер ярдәмендә куерганчы туглыйбыз. Аннан салкын йомшак сыр кушып, тагын әйбәтләп туглыйбыз.

■ Мичтән капкейкларны алып, суынганын көтәбез.

■ Суынгач, пычак очы белән сак кына 1,5 см тирәнлектә һәрберсенең уртасын алабыз.

■ Шул кечкенә чокырларга джем салып чыгабыз.

■ Джем салынган капкейкларның өстен крем белән бизибез.

■ Крем өстенә нарат җиләкләре тезәбез. Бизәк итеп алар янына яшел яфраклар да куеп чыгарга була! Капкейклы чәйләрегез тәмле булсын!



Чит илдә яшәүче дус кызым кайчандыр ясмык токмачы – паста турында сөйләгән иде. Кызганыч, якын-тирә кибетләрдән мин аны таба алмадым. Димәк, бу пастаны үзебезгә әзерләргә кала.



Камилә
ДИМӨХӘММӘТОВА

Ясмык пастасы

Ясмык нерв системасын ныгыта, холестеринны киметергә ярдәм итә, гемоглобинны арттыра, кан басымын көйләргә булыша. Болардан тыш, ясмыкның ашкайнату эшчәнлегенә уңай йогынтысы бар, һәм ул эчәклек яман шешен булдырмас өчен яхшы профилактика ролен башкара.

Кузаклылар семьялыгына керүче бу культура аксым чыганагы да. Аны ябыгырга теләүчеләр дә бик рәхәтләнеп үз рационнарына кертә ала.

Ясмыкны ашка кушалар, аерым гына да пешерәләр, котлетын кыздыралар... Ә без аннан паста әзерләрбез. Моның өчен берничә мөһим ингредиент һәм бик аз гына вакыт кирәк. Токмач дигәч, аның составында бодай оны да булырга тиеш кебек. Ә бодайда глютен бар. Без әзерләгәне исә глютенсыз булачак, димәк, бу пастаны глютенны үзләштерә алмаучылар да куллана ала.

Кирәк: ясмык, дөге оны, карабодай оны, җитен (яисә бер йомырка).

Эш барышы: башта җитеннән «йомырка» әзерлибез. (Әгәр дә чын йомырка кулланырга теләсәгез, бу пунктны уздырыгыз). Моның өчен 2 аш кашыгы җитен орлыгына 6 аш кашыгы су кушып, 15 минут тотабыз. Бу вакытта җитен орлыгы бүртеп, җилемләнә.

1 стакан ясмыкны блендер, кухня комбайны яки кофетарткыч аша он хәленә килгәнче ваклыйбыз. Вакланган ясмыкны иләк аша илибез, эре бөртекләр күп калса, тагын бер кат ваклатып алырга була.

Ясмык онына 0,5 стакан дөге оны белән 0,5 стакан карабодай оны һәм бер чеметем тоз кушабыз. (Аларны да үзегез ясый аласыз.)

Өч төрле онны бергә катнаштырып, 1 аш кашыгы зәйтүн мае өстибез һәм җитен «йомыркасы»н кушабыз. (Аның урынына 2 йомырка кулланырга мөмкин.)

Пастаны әзерләр өчен якынча 3/4 стакан күләмендә су кирәк. Суны камырга азлап-азлап куша барсаң, яхшырак. Иң элек 8 аш кашыгы гына су кушып, камырны туглыйбыз. Баштагы мәлдә ул уалучан була, тора-бара үзләнә. Тагын бераз су кушып, камыр басуны дәвам итәбез. Камырны кунага күчереп, тыгызланганчы, үзләнгәнче тагын бераз басабыз да, 10 минутка өстен каплап «ял иттерәбез».

Камырның яртысын карабодай оны сибелгән кунада уклау белән җәябез. Артыгын юкартырга кирәкми, камыр ертылырлык булмасын.

Җәемнең читләрен кисеп, турыпочмак ясыйбыз һәм шуны 1,5 см киңлегендәге тасмаларга кисәбез. Икенче яртысын да шулай ук җәеп кисәбез.

Пастаны кайнап торган тозлы суга салып, 5-6 минут пешерәбез.

Ясмык токмачын табынга яшелчәләр яки берәр соус белән бирәбез.

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН

Һәр йөзенче кешедә глютенны үзләштерә алмау күзәтелә. Эч күбү, ашказаны эшләмәү, ябыгу (яисә, киресенчә, артык авырлык җыю), анемия, тиз йончу – әлеге симптомнар глютенның үзләштерелмәвенә ишарә булырга мөмкин.

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Кучкар. Авыр йөк булып торган бурычлардан, күптән инде эшләнмичә яткан эшегездән арыну җаен тапсагыз – киләчәктә уңыш елмаер, үзегезгә дә җиңелрәк булып китәр. Айның икенче яртысында карьерада үсеш көтелә.

Үгезбозау. Тормышыгызга яңа борылышлар, үзгәрешләр килә. Бурычын онытучылар бурычларын кайтарыр. Үзегезгә ял ясагыз, сәламәтлегегезне кайгыртырга онытмагыз. Якын кешегезнең киңәшләренә колак салу да мөһим.

Игезәкләр. Иҗади планнарыгызны чынга ашырырга җайлы вакыт. Күп көч һәм энергия сорый торган эшләрне иртәгәгә калдырмагыз. Ай ахырында көтелмәгән уңыш елмаер, финанс хәлегез яхшырыр.

Кысла. Сездән нindидер зур эш көтелә. Бу айда һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга туры килер. Шуңа күрә гардеробыгызны яңарту да ярап куяр. Гаиләгез, якыннарыгыз турында да истән чыгармагыз!

Арыслан. Тормышка анализ ясый торган чор. Кирәкмәгән конфликтлардан сакланыгыз. Күңел халәтегезне кайгыртыгыз, музей, күргәзмәләргә барып кайту җаен тапсагыз, дөньяны киңрәк, матуррак итеп күрә башларсыз.

Кыз. Маҗараларга бай чор көтә сезне! Башкалар белән уртак тел табарга мин-минлегегез генә комачауламасын. Эмоцияләрне контрольдә тотарга тырышыгыз. Сәяхәтләр планлаштырырга уңай вакыт.

Үлчәү. Үзгәрешләр көтеп яшәгән күңелегезгә ноябрьнең көтелмәгән яңа вакыйгалары бик шәп дәва булыр. Фикерегезне якларга, кыю итеп үз сүзегезне әйтә белергә кирәк. Ял итәргә дә вакыт табыгыз.

Чаян. Айның беренче яртысы катлаулы булса да, икенче яртысында үз дигәнегезгә ирешерсез. Бизнес-план төзү, яңа проектларны чынга ашыру вакыты. Ялларны гаилә белән планлаштыру хәерле.

Укчы. Тормышта сезнең өчен иң мөһиме нәрсә? Шул сорауга җавап табып, тормыш курсын, фикерләүне үзгәртергә вакыт. Башкаларга карап түгел, үзегезгә уңайлы булганча яшәргә өйрәнү – бәхетнең нигезе икәнен аңларсыз.

Кәҗәмөгез. Эшкә күмелеп, яраткан кешегезнең күңелен күрергә дә онытмагыз. Мәхәббәт – кешене бизи, көч бирә! Бу чорга ял алырга телисез икән, һичшиксез, күңелле сәяхәт планлаштыру әйбәт булыр.

Сукояр. Айның беренче яртысында аз гына түзәргә, сабыр итәргә кирәк. Аннан соң инде үзегезне тормышыгызның хуҗасы, тирә-юнь өчен иң кирәкле кеше итеп тоярсыз. Үзегезне беркайчан да тәнкыйтьләмәгез!

Балык. Яңа танышулар чоры. Гашыйк булып куюыгыз да бар! Финанс мәсьәләсендә эш урынында уңыш көтелә. Төгәл максатлар билгеләп, тормышыгызны алдан планлаштырып куярга өйрәнегез.

СЕЗ НИНДИ САТЫП АЛУЧЫ?

тест

Кибеттә алдан төзелгән исемлек белән генә йөрисезме?
А. Бары исемлек буенча гына – 2 балл.
Б. Кайчан ничек – 1 балл.
В. Хәтеремә ышанам – 0 балл.

Сатып алган әйберләрегезне кая куясыз?
А. Көпчәкле зур арба алам – 0 балл.
Б. Кәрзин алам – 1 балл.

Кибеткә балалар белән йөрисезме?
А. Үзем белән алырга туры килә – 0 балл.
Б. Кибеткә балаларсыз килергә тырышам – 3 балл.

Сөт алырга булдыгыз ди. Нинди марканы сайлыйсыз?
А. Мин һәрвакыт тикшерелгән марканы сайлыйм – 1 балл.
Б. Киштәләрне карап, уртача бәядәгесен сайлыйм – 0 балл.
В. Иң арзанлысын алам – 2 балл.

Ипи алырга кергәндә тәм-том, җиләк-җимеш бүлегеннән узарга кирәк, ди. Тукталасызмы яки туры барасызмы?
А. Башка бүлекләрне дә күзәтеп узам – 0 балл.
Б. Кәефемә карап – 1 балл.
В. Бернигә дә карамаска тырышам – 2 балл.

Сезгә кирәкле товарның башка җирдә арзанрак торганын беләсез. Әмма ул менә бу кибеттә очрады. Бу очракта нәрсә эшлисез?
А. Арзан җиргә барып алырга иренмим – 2 балл.
Б. Кергән җирдән алам, вакытым кадерлерәк – 0 балл.

Бәясеннән кала, товарның тагын нинди сыйфатларына игътибар итәсез?
А. Маркасына һәм кабының уңайлылыгына – 0 балл.
Б. Ингредиентларына – 1 балл.
В. Саклану вакытына – 2 балл.

Агарта торган порошок белән юсаң, ак киемне һәр көнне кияргә була дигән рекламага ышанасызмы?
А. Әйе – 0 балл.
Б. Мин агарта торган порошок кулланмыйм – 2 балл.
В. Юк, рекламага ышанмыйм – 1 балл.
Г. Белмим – 1 балл.

Үзебездә җитештерелгән арзанлы чистарту-юу чараларын аласызмы, әллә чит илдә җитештерелгән кыйбатрагынмы?
А. Үзебезнекен алам – 1 балл.
Б. Чит илнекен сайлыйм – 0 балл.

Кассага чират җиткәч, балагызга татлы әйбер алмаганыгыз искә төшә...
А. Тәм-том сатыла торган бүлеккә йөгерәм – 2 балл.
Б. Касса янындагы шоколад-конфетны сайлыйм – 0 балл.

Нәтиҗәләр:

0–5 балл. Планлаштырганга караганда, кибеттә ике тапкыр күбрәк акча калдырасыз бугай. Акчагыз гына түгел, өйдә кулланылмыйча тузан җыеп яткан әйберләр дә кызганыч. Сәүдә үзәгендә үзегезне контрольдә тотарга, исемлек буенча гына сатып алырга тырышыгыз.

6–15 балл. Кибеттә 10–20 процент артык акча калдыручылар рәтенә кертергә була. Ел буе тотыла торган артык чыгымнарны санап карагач, шактый җыела. Кирәкле әйберләрне алдан планлаштырып куйсагыз, экономияләү җайлырак булыр.

16 балл һәм күбрәк. Кибеттә акчаны бик төгәл тотасыз. Экономияләү җаен да әйбәт беләсез. Кайвакыт сезне саранлыкта гаепләсәләр дә, исегез китмәсен. Бай кешеләр – акчаны санап тота белүчеләр ул!

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен
Раилә ХӘЯЛИЕВА,
Лилия ГӘРӘЕВА
әзерләде.







КЫРЫМ БИЗӘКЛӘРЕ

Кырым бизәкләре тоныкланмый! Чөнки алар һәр көн керамик савыт-сабаларда кабатлана. Бу «Осталар иле»нең хуҗасы – талантлы рәссам, исеме бар дөньяга билгеле керамика остасы Рөстәм Скибин!

Ул 1976 елда Үзбәкстанда туа. А. Абдурасулов исемендәге Сәмәрканд сәнгать училищесында белем ала. 1996 елны әти-әнисе белән бергә Кырымга күчеп кайта һәм Симферопольдәге «Таврика» керамика предприятиесенең баш рәссамы булып эшли башлый. Нәселендә аның нинди генә милләт вәкилләре юк, ә менә үзен ул Кырым татары дип саный.

2000 елда Кырым татарлары мәдәниятен барлауга зур өлеш керткән рәссам, сәнгать белгече Мамут Чурлу белән дуслашканнан бирле, Рөстәм Скибин әсәрләрен бизәүдә кабатланмас үз ысулын булдыра. Керамик әйберләренең композицияләрен үз милләтенең борынгы орнаментларына, катлаулы бизәкләргә таянып төзи башлый. Аларда кабатланучы хәят агачы, анар җимеше, бәдам чикләвеге төше, кипарис агачы, лалә чәчәге сурәтләре – һәрберсе әсәрләрнең символик телен аңлатучы тамгалар.

Симферополь районының Акрополис бистәсендә «EL CHEBER» («Осталар иле») дип аталган иҗат остаханәсен ачуы, сәләтле яшьләргә керамист һөнәрен өйрәнүгә мөмкинлекләр тудыруы аеруча мактауга лаек! «Бер рәссамның икенчесенә традицияләр тапшыруы – теләсә нинди мәдәниятне тотып торучы иң мөһим шарт ул. Борынгы милли әйберләрне кулга алып, аларның ничек аталышын белмисең икән, димәк, үз барлыгыңның бер өлешен югалтасың, башка мәдәният казанында эрисең. Әмма да ләкин без бер табылдык аша гына да үз тарихыбызның тулы бер катламын кире торгыза алабыз», – ди рәссам.

Аның декоратив тәлинкәләре дөньяның иң йогынтылы җитәкчеләре, сәясәтчеләре, сәнгать кешеләре тупланмаларын, төрле музейларны бизи, алар кайда да югары дәрәҗәдәге сәнгать әсәре кебек кабул ителә. Гарәп каллиграфиясен кертеп бизәлгәннәре аеруча затлы күренә! Ул башка рәссамнар белән берлектә төрле материаллардан төрле әсәрләр дә ясый, алар барысы да кырымтатар сәнгате стилендә. Урам сәнгате ысулындагы рәсемнәре дә Украина шәһәрләренең архитектурасын яңарткан.

Әтисе – агач уючы, әнисе – филолог, дәү әтисе – сәгать төзәтү остасы, әнисенең абыйсы – тарихчы һәм сәнгать белгече булган нәселдә туган баланың рәссам һөнәрен сайлап алуы гаҗәп тә түгел. «Әсәрләрем аша үз милләтемнең куәтен, тырышлыгын, хезмәт сөючәнлеген һәм югары эстетик зәвыгын күрсәтергә омтылам. Иҗатымда тамгаларны һәм символларны еш кулланам. Алар – уңышка, бәрәкәткә илтүче милли кодлар. Күңелем бар мәдәниятләр өчен дә ачык, мин моңа сәнгать аша килəм. Без телебезне, динебезне, аңыбызны формалаштыручы мохит тәэсирендә... Кешеләрдә үз милли мәдәниятен тирәнтен аңлау теләге көчле булганда, алар инде башкалар йогынтысына һич тә бирешми», – ди иҗатчы.

«Үзле балчык – ул үз холкына ия булган җанлы җисем. Моны гел истә тотарга кирәк. Һәрбер эш бары изге, игелекле уйлардан башланырга тиеш, шуңа күрә дә иҗатка керешер алдыннан Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп догалар кылам». Бу сүзләрне әйтүче рәссамның йөзендә – һәрчак нур, һәм бу нур аның әсәрләре аша башкалар күңеленә дә үтеп керә. Шуңа күрә Кырым киңлекләрендәге үзле балчык, догалы осталар кулында гаҗәеп керамика әсәрләренә әверелеп, гел яхшылыкка өндәячәк, ә талантлы рәссам-керамист Рөстәм Скибин иҗатындагы Кырым чәчәкләре, Кырым бизәкләре яңадан-яңа төсмерләр белән балкыячак!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА








рөстәм скибин





2021 елның беренче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды

«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:
ярты елга – П2204
бер елга – П8299

Татарстаннан читтә яшәүчеләр
«Роспечать» каталогы (индекс – 73002)
һәм
ПАП рәсми каталогы буенча
(индекс – П0279) языла алалар:

Сайт: www.syuyumbike.ru
ВКонтакте: vk.com/suumbike
Фейсбук: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграм: www.instagram.com/suyumbike_journal
Telegram: t.me/suumbike

Журналыбызга онлайн режимда :
http://www.tatmedia.ru/podpiska/
язылырга мөмкин



Яңа санның электрон вариантын, «Pressa.ru» сайтында язылып,
компьютерда, планшетларда
һәм башка мобиль җайланмаларда
PDF форматта укый аласыз.

РЕКЛАМА 16+